# ТАТАР ӘДӘБИЯТЫ

**8** нче сыйныф

МЕТОДИК ӘСБАП

Рус телендә төп гомуми белем бирү оешмаларында
(татар телен өйрәнүче укучылар белән)
эшләүче укытучылар өчен

КАЗАН
«МӘГАРИФ — ВАКЫТ» НӘШРИЯТЫ
2015

УДК 373.167.1:821.512.145*01
ББК 84(2Рос=Тат)я71
М85

Авторлар
Ә.Р. Мотыйгуллина, Р.Г. Ханнанов,
Р.Һ. Вәлиуллина, А.Г. Гарәфетдинова

**Мотыйгуллина, Ә.Р.**

М85 Татар әдәбияты : рус телендә төп гомуми белем бирү оешмаларында (татар телен өйрәнүче укучылар белән) эшләүче укытучылар өчен методик әсбап. 8 нче с-ф. / Ә.Р. Мотыйгуллина, Р.Г. Ханнанов, Р.Һ. Вәлиуллина, А.Г. Гарәфетдинова. — Казан : «Мәгариф — Вакыт» нәшр., 2015. — 263 б.

© «Мәгариф — Вакыт» нәшрияты, 2015
© Ә.Р. Мотыйгуллина, Р.Г. Ханнанов,
Р.Һ. Вәлиуллина, А.Г. Гарәфетдинова, 2015

# КЕРЕШ

Төрле милләтләрнең әдәби-мәдәни казанышларын, традицияләрен, милли асылын өйрәнү әдәбият дәресләрендә алып барыла. Әдәбият дәресләре үз халкыңның яки башка халыкларның әдәбиятын өйрәнү юнәлешендә булырга мөмкин. Ә күпмилләтле мохиттә татар әдәбиятын укыту махсус методик эзләнүләр таләп итә. Аның нигезләрен рус телле аудиториядә татар теле һәм әдәбиятын укытуның милли, дидактик, психологик, әдәби, культурологик, лингвистик үзенчәлекләрен өйрәнү тәшкил итә.

Әлеге дәреслекләр нигезендә татар әдәбияты дәресләре К.С.Фәтхуллова., Р.З.Хәйдәрова, Р.Р.Нигъмәтуллина тарафыннан төзелгән татар теле дәреслекләре белән параллель рәвештә укытыла. Шуңа күрә татар әдәбиятын укыту өчен татар теле дәресләрендәге грамматик минимумны, телнең лексик-синтаксик составын белү таләп ителә.

Рус телле аудиториянең аерым үзенчәлекле якларына да тукталу сорала. Бу төркем балалар белән эшләү барышында әдәбият белемендә моңа кадәр чагыштырма-типологик анализның нигезе булып торган, шактый тирән өйрәнелгән компаративистика теориясенә таяну әһәмиятле. Гомумилек төрле милләт халыкларында очрый торган сәнгатьчә образлар, әдәби детальләрдә чагылыш таба. Шуларны табу, барлау, чагыштырма планда өйрәнү күпмилләтле мохиттә татар әдәбияты дәресләрендә тормышка ашырылырга мөмкин. Һәрбер халык үз милли бизәкләренә өстенлек бирә. Аларны тел чаралары ярдәмендә, төрле калыпларга салып, буыннан-буынга тапшырып килә. Татар әдәбияты дәреслекләрен төзү барышында күптөрле халыкларның милли табышлары, халыкчан образлары ачыкланды, аларны чагыштырма планда өйрәнү өчен нигез салынды.

Күпмилләтле мохиттә төрле халыкларның әдәби, мәдәни казанышларын чагыштырма-типологик нигездә өйрәнүнең берничә юнәлешен ачыклап узыйк: а) төрле халыкларның авыз иҗаты җәүһәрләрен чагыштырып өйрәнү (татар-башкорт, татар-рус, татар-чуваш һ.б.); ә) әдәби әсәрләрдән һәм фольклордан мәдәният-сәнгать, төрле халыкларның яшәү рәвеше турындагы өзекләрне сайлап алу һәм бәяләү; б) әдәби әсәрләрнең теленә бәя бирү аша халыкларның милли-мәдәни байлыгын чагыштыру. Күреп үткәнебезчә, әдәби белем бирү системасы мәдәният белән тыгыз бәйләнештә яши.

Әдәбият фәне мәдәниятнең нигезен тәшкил иткән сәнгатьнең бер төре булып торуын да истә тотсак, әдәби әсәрне культурологик аспектта бәяләү, шәрехләү үзен аклый. Күпмилләтле мохиттә әдәбият укытуның дидактик нигезләре Федераль дәүләт стандартларына нигезләнеп төзелгән татар әдәбияты дәреслекләре барлык фәннәрне өйрәнү барышындагы фундаменталь төшкә (фундаментальное ядро), универсаль уку гамәлләренә нигезләнә, укучыларның яшь һәм әдәби үсеш дәрәҗәсен исәпкә ала. Укыту һәм тәрбиянең гомуми нәтиҗәләре иҗтимагый, шәхси, танып-белү һәм коммуникатив үсешне тәэмин итеп, укучыларның белемнәрен, күнекмәләрен үстереп, дөньяны танып белүгә әзерләп, хезмәттәшлеккә, үзлегеннән белем алуга, камиллеккә омтылучы шәхес тәрбияләүгә барып тоташа.

Аерым алганда, уку-укытуга системалы-гамәли якын килү нәтиҗәсендә, укучыларның иҗтимагый үсешенә (халыкның рухи кыйммәтләрен аңлаучы, үстерүче Россия гражданины тәрбияләү); шәхси үсешенә (иҗади яктан сәләтле, компетентлы, үзаңы үскән, үзлегеннән белем алырга, үзенең гражданлык карашларын ачыктан-ачык белдерергә сәләтле, үз-үзенә тәнкыйди карашта булган, тормыш авырлыкларына каршы торырлык шәхес тәрбияләү); танып белү эшчәнлеген үстерүгә (фәнни дөнья сурәтен аңлаучы, үзенең танып белү һәм интеллектуаль эшчәнлеге белән идарә итә ала торган, уку, белем алу чараларын күзаллый торган, репрезентатив, символик, логик, иҗади фикерләү сәләте үскән, рефлексиягә сәләтле укучы тәрбияләү); коммуникатив үсешкә (аралашу компетенциясе үскән, тыңлый һәм диалогта, гомуми сөйләшүдә катнаша алырлык, туган телен, рус телен, чит телне камил белүенә) басым ясалды. Шул гамәлләрне тормышка ашыру барышында яшүсмерләрнең яшь үзенчәлекләре дә игътибарга алынды.

Күпмилләтле мохиттә гомуми әдәби белем бирү барышында универсаль уку гамәлләре (алга таба — УУГ) дүрт блокка бүлеп каралды. Алар арасында **шәхси УУГ** — тормышчан, шәхескә юнәлтелгән, һөнәри юнәлештә үз юлын табуга, кешенең эчке потенциалын рациональ файдалана белүенә бәйле блок. **Регулятив уку гамәлләре** шәхес тәрбияләүдә планлаштырырга өйрәтү, фаразлау, коррекция, бәяләү кебек якларны үзәккә ала. **Танып белү гамәлен** алгы планга чыгарган блокта логик, проблеманы кую һәм чишүгә юнәлтелгән, тамга-символик якны иңләгән гомумуку гамәлләренә игътибар ителә. **Коммуникатив УУГ** кешеләр яз-

мышына битараф булмауны, ярдәмчеллек сыйфатларын тәрбияләүне, иҗтимагый компетентлыкны үз эченә ала. Универсаль уку гамәлләрен рус телле балаларга татар әдәбиятын укыту барышында куллану нәтиҗәсендә, укучыларны мөстәкыйль эшләргә өйрәтү юнәлеше көчәйде (мәсәлән, өй эше бирү — берничә вариантта). Шул рәвешле, татар әдәбиятын өйрәнүнең максаты да ачыкланды: туган халкының һәм җирле халыкның телен, мәдәниятен, әдәбиятын яхшы белгән, һәрьяктан камил, милли горурлык хисләре үскән шәхес (гражданин) тәрбияләү.

Әлеге максатны тормышка ашыру өчен, түбәндәге бурычлар билгеләнде:

• Татарстан төбәгендә яшәп, җирле халык белән аралашкан укучыларны төбәкнең әдәби-мәдәни байлыгы белән якыннан таныштыру;

• татар әдәбияты турындагы мәгълүматларны төрле халык фольклоры, әдәбияты, мәдәнияте, милли образлары белән чагыштырма-типологик аспектта бирү;

• татар халык авыз иҗаты турында тулы күзаллау булдыру, аны баланың үз туган халкының рухи җәүһәрләре белән чагыштырырга күнектерү;

• татар әдипләре, сәнгать әһелләре турында күзаллау булдыру, аларны танырга, иҗатларын аңларга, башка халыкларның сүз сәнгатен, культурасын үстерүчеләр белән чагыштырма планда бәяләргә өйрәтү;

• татар, рус, Россиядә яшәүче башка халыклар, бөтендөнья әдәбияты белеме казанышларының уртак нигезен аңлау, аларны үстерү һәм киңәйтү.

Әлеге максат һәм бурычларга ирешү өчен, без түбәндәге принципларны истә тотарга тиеш. Рус телендә сөйләшүче балаларга татар әдәбиятының асылын төшендерү өчен, укытучының сүз сәнгате серләрен яхшы белүе, иҗади эшләү күнекмәләре булуы таләп ителә. Мәктәп укучысына сүз сәнгатенең серләрен ачуда эстетик принцип (укытучының матурлыкны күрә алуы һәм башкаларны да күрергә өйрәтә алуы), эзлеклелек (укучы алган белемнең тулыланып, баеп баруы), әдәбиятны сүз сәнгате буларак өйрәнү (татар телендә язылган әсәрләрдә әдәби образларны ачу үзенчәлекләрен, татар теленең матурлыгын күрергә өйрәтү), күләме ягыннан кечкенә булган әсәрләргә шәхси мөнәсәбәт булдыру, ягъни психологик принцип (мәктәп баласының яшь үзенчәлекләрен, әдәби әзерлек дәрәҗәсен исәпкә алып эш итү)

ярдәмгә килә. Аерым игътибар коммуникативлык принцибына бирелә. Бу принципның өстенлеге рус телендә сөйләшүче укучыларның әдәби әсәр аша татар теленең серләренә тирәнрәк төшенүләре, матур әдәбият әсәре хакында сорауларга нигезләнеп сөйли алулары, үз фикерләрен ачык әйтә алулары, әдәби әсәрнең аралашу чарасына әверелүе белән дә бәйле. Укучыларның әдәби әсәрне кабул итү һәм, әдәби үсеш үзенчәлекләрен исәпкә алып, дифференциацияләү (аерым төркемнәргә аерып, бүлеп эшләү) һәм интеграцияләү (татар теле һәм рус әдәбияты дәресләрендә алынган теоретик белемнәрне һәм гамәли эш күнекмәләрен файдалану) дә үзәккә алына.

## 8 нче сыйныф өчен «Татар әдәбияты» фәненнән укыту-методик комплект (УМК)

Төп мәктәп уку-укыту системасында 8 нче сыйныф әдәби белем бирүдә әһәмиятле урын алып тора. Бу сыйныф балаларының яшь һәм әдәби үсеш үзенчәлекләрен исәпкә алып төзелгән УМК үз эченә дәреслекне, электрон дәреслекне, укытучылар өчен методик әсбапны ала. Дәреслек ике кисәктән тора. Укучыларның белем-күнекмәләрен бәяләп бару өчен, һәр кисәк аерым модульләргә бүлеп төзелгән. Һәр модуль бөтен кисәкнең өлешләрен хәтерләтә. Модульгә салынган мәгълүмат та, дәреслек үзе дә хронологик нигезгә корыла. Шул ук вакытта модульләр эчендә тематик-хронологик принцип та саклана. Һәр модуль укучыларның әдәбияттан мәгълүматлылык дәрәҗәсен үстерүне дә, эрудициясен киңәйтүне дә, әдәбиятны сәнгатьнең башка төрләре белән бәйләп баруны да, теоретик төшенчәләрне үзләштерүне дә, сораубиремнәрне үтәгәндә файдалана алуны да күздә тотып урнаштырылган. Дәреслектә модульләр арасындагы бәйләнешләр сораубиремнәр һәм контроль тестлар аша гамәлгә куела. Шулай итеп, дәреслекне әдәби-теоретик төшенчәләр сүзлекчәсе, фразеологик сүзлекчә кебек белешмәләр төгәлләп куя. Дәреслеккә салынган әдәби әсәрләрнең нигезен «Үрнәк программа»да күрсәтелгән (төзүчеләре: Ф.Х.Җәүһәрова, К.С.Фәтхуллова) әдәби әсәрләр минимумы (7 әсәр) тәшкил итә. Алар түбәндәгеләр:

1) Г.Тукайның. «Пар ат» шигыре;
2) Ш.Камалның. «Буранда» новелласы;
3) С.Хәкимнең. «Җырларымда телим» шигыре;
4) Г.Афзалның. «Юл газабы» хикәясе;

5) Ф.Садриевнең. «Таң җиле» романы (өзек);
6) Р.Харисның. «Ике гөл» шигыре;
7) Т.Миңнуллинның. «Моңлы бер җыр» драмасы (өзек).

Дәреслек, күпмилләтле мохиттә татар әдәбиятын укыту юнәлешендә «Үрнәк программа»га һәм «Әдәбият укыту программасы»на (авторлык) таянып, беренче тапкыр төзелде. Аның нигезендә татар әдәбияты, мәдәнияте һәм татар халык фольклоры үреп бирелә, әдәби-теоретик төшенчәләр тәкъдим ителә. Шулай ук, татар әдәбиятын рус һәм Россиянең башка халыклары әдәбияты һәм мәдәнияте яссылыгында өйрәнү өчен, аларның да фольклор үрнәкләре һәм идея-эстетик яктан камил тәрҗемә әсәрләре салынды.

Дәреслек, 5—7 нче сыйныфлардагы структураны дәвам итеп, халык авыз иҗатын өйрәнүдән башлана. Аның 8 нче сыйныфта риваять һәм легенда жанрлары өйрәнелә. Риваятьләрне топонимик һәм тарихи төрләргә бүлеп карыйбыз. Аларны «Сихерче кыз», «Утсыз кайный торган казан», «Казан кайда корылган?», «Гали тугае» һәм Урта гасыр Европа халыклары арасында таралган «Моргана» риваяте мисалында өйрәнү планлаштырыла. Легенда жанрын үзләштерү өчен, «Зөһрә кыз» һәм шотланд халкының «Местер Стуруорм» легендалары тәкъдим ителә. Риваятьләр, легендаларга салынган мәгълүмат язма әдәбият белән бәйләп бирелә. Фикерне дәлилләү максатыннан, Ф.Яхинның «Һомай кошы», Ә.Еникинең «Курай» әсәрләреннән өзек, Ф.Яруллинның «Моңлы курай» әсәрләре тәкъдим ителә. Шул рәвешле халык авыз иҗатының риваять, легенда жанрындагы үрнәкләрен үзләштергәннән соң, аерым әдәби әсәрләр өйрәнелә башлый.

Дәреслектә әдәби-мәдәни юнәлеш тагын да көчәйтелә. Ике кисәктә дә балаларны сәнгать казанышлары белән таныштыру эше алып барыла. Дәреслекнең беренче кисәгендә дүрт блок урнаштырылган. Фольклор турындагы белемнәрне киңәйтеп килгән икенче блокта «халык әдәбияты»ндагы ачыш-табышларны өйрәнү әдәби әсәрләргә бәйләп дәвам иттерелә.

Дәреслекнең беренче кисәгендә әдәбиятны сәнгать белән бәйли торган ике юнәлеш бирелә. Беренчедән, төрле халыкларда киң кулланылышта йөргән музыкаль уен кораллары турындагы мәгълүмат халыкның үткән һәм бүгенге көн мәдәни тормышын, көнкүрешен, хыял-теләкләрен, традициясен ачу чарасы булып тора. Сәнгать юнәлешен үстерү рәссам Бакый Урманче эшчәнлеген өйрәнү, күзәтү, бәяләү белән кушылып китә. Шулай ук танылган җырчы Илһам Шакиров, режиссёр Марсель

Сәлимҗанов, театр артисты Ринат Таҗетдиновның иҗаты белән танышу мөмкинлеге дә туа.

Икенчедән, дәреслектә укучылар игътибарына тарих пәрдәсе ачыла башлый. Гарәп иленнән килгән илче Ибне Фадлан язмалары, Фатих Кәриминең «Аурупага сәяхәтнамәсе», Миргазиян Юнысның «Су» язмасы, Ә.Баяновның «Хыялда туган калам» әсәренә тоташып китеп, укучыларга җиткергәндә, дәрес формаларын төрләндерү мөмкинлеге тудыра. Әдәби башлангыч белән публицистиканың кушылып китүенә нигезләнгән язмаларны уку һәм анализлауның да яңа алымнарына тукталу сорала. Мондый язмаларны өйрәнү барышында укучыларның күзаллавы киңәя, алар тарихи мәгълүматларны башка дәресләрдәге материал белән чагыштыра, бәяли ала башлыйлар. Дәрес формаларының традицион булмаган төрләренә дәрес-сәяхәт, дәрес-эврика (ачыш), дәрес-ярыш, дәрес-турнир, дәрес-уен (В.С.Кукушин төркемләве) мөрәҗәгать итү дә үзен аклый. Әдәбиятта публицистик башламны өйрәнү Гариф Ахуновның «Замандашлар портреты», Рафаэль Мостафинның «Йөз ундүрт адым», Муса Җәлилнең кызына язган хаты белән танышу вакытында дәвам иттерелә.

Ә.Баяновның «Хыялда туган калам» дигән, Казан шәһәренә багышланган әсәре янәшәсендә данлыклы Казан Кремле тыюлыгы турында мәгълүмат бирү республиканың иң биек һәм бөек урыны турында сөйләшүгә нигез була ала.

Дәреслекнең икенче кисәгендә әдәби-мәдәни юнәлеш үстерелә: композитор Луиза Батыр-Болгари, режиссёр һәм артист Габдулла Кариев иҗаты яктыртыла. Татар театр һәм җыр сәнгатен үстерүгә зур өлеш керткән Галия Кайбицкая турындагы биографик белешмә Фирдәвес Әһлиянең «Актриса» әсәре белән тулыландырыла. Дөньякүләм танылган биюче Рудольф Нуриев турында укучылар Рабит Батулланың «Бию җене кагылган егет» әсәренең өзеген укып күзаллый алалар. Рәссам язмышы турында әдәби әсәрдән өзек тәкъдим ителә. Аның белән Зиннур Хөсниярның «Рәссам язмышы» («Терсәк сугышы» романыннан өзек) герое язмышы аша танышып була.

Дәреслекне төзү барышында мәдәният учагы булган музейлар турында мәгълүмат урнаштыру УМКның бер үзенчәлеге булып тора. Әлеге уку елында да укучылар Б.Урманче, Г.Кариев музейлары, Казанда Муса Җәлил һәйкәле һәм җәлилчеләргә куелган барельефлар белән танышуны дәвам итәчәкләр. Шулай итеп, укучыларга, Ф.Кәримигә ияреп, музейларга сәяхәт турында үз

язмаларын укучылар өчен чыга торган «Ялкын» журналына җибәрү мөмкинлеге дә туа.

Моннан тыш 8 нче сыйныф дәреслегеннән белем алучы балалар, туган ил, туган җир, аның кадерен белү, саклау турында язылган әсәрләр белән таныша. Шулар исәбендә Габдулла Тукайның «Пар ат», Фатих Кәримнең «Ант», «Кыңгыраулы яшел гармун», Илдар Юзеевның «Һаман көтә», Туфан Миңнуллинның «Моңлы бер җыр», Мостай Кәримнең «Билгесез солдат», Чыңгыз Айтматовның «Анам кыры», Клара Булатованың «Башым иям», Мансур Шиһаповның «Җиңү көне җиңел бирелмәде», Нур Әхмәдиевнең «Җиңү көне», Факил Сафинның «Тулганай», Разил Вәлиевның «Ватаным», Айдар Хәлимнең «Өч аяклы ат», Гәрәфи Хәсәновның «Беренче күк күкрәү» әсәрләре бар.

Иң кадерле кешеләребез — әниләргә багышланган бүлектә Шәриф Камал, Ибраһим Салахов, Сибгат Хәким, Роберт Миңнуллин, Марсель Галиев, Шәриф Хөсәенов, Фоат Садриев әсәрләре белән танышып, ана образын әдәбиятта гәүдәләндергән әсәрләрне белү мөмкинлеге туачак.

Татар әдәбияты үсешендәге көчле юнәлеш булган сатираны өйрәнү дәреслекнең икенче кисәгендә беренче сатирик журналлар белән таныштырудан башлана. Галиәсгар Камалның «Банкрот» комедиясен, Фатих Әмирханның «Фәтхулла хәзрәт» повестен, Нәкый Исәнбәтнең «Хуҗа Насретдин» комедиясен, Гамил Афзалның шигырьләрен, Зыя Мансурның «Таңсылу әкияте»н, Зәки Нуриның пародия һәм эпиграммаларын өйрәнү күздә тотыла.

8 нче сыйныф укучылары әдәбиятның сүз сәнгате икәнлеген аңлый. Шуңа күрә төрле әдипләр иҗатындагы бу процессны күзаллап кына калмыйлар (Ренат Харисның «Гармунчы», «Ике гөл»; Зөлфәтнең «Шигырем — ачык!», «Шундый чагы әле җанымның» шигырьләре; Гамил Афзалның «Юл газабы» (мәкаләсе һәм шигыре)), сәнгатьнең башка төрләрендә иҗади юнәлешнең (Рабит Батулланың «Бию» («Бию җене кагылган егет» әсәреннән өзек), Зиннур Хөсниярның «Рәссам язмышы» («Терсәк сугышы» романыннан өзек) көчле булуын да күрәләр.

Дәреслекне үзләштерү барышында укучыларның әдәбият белеме белән бәйле теоретик белеме дә үстерелә. Бу сыйныфта әдәби әсәрнең жанрына, әдәби эшләнешенә караган 22 әдәби-теоретик төшенчә үзләштерү күздә тотыла.

Рус мәктәбендә белем алучы рус телле балаларның сүзлек байлыгы аз булуны истә тотып, алар белән эшләгәндә, әдәби

әсәр текстларын ятлап истә калдыруны үзәккә алу әһәмиятле. Шуңа күрә дәреслекне үзләштергәндә, ятлау өчен әсәрләр дә тәкъдим ителә.

Гомумән алганда, рус телендә сөйләшүче балалар татар әдәбияты дәресләрендә үзләре яшәгән җирлектәге милли-төбәк компоненты белән якыннан танышачаклар, чит ил һәм рус әдәбияты белән бердәй дәрәҗәдә үскән татар әдәбияты барлыгына да инаначаклар. Бу исә үз чиратында тел өйрәнүнең дәрәҗәсен күтәрүгә, әдәбият хәзинәләребезне башка халыклар арасында таратуга юл ачачак һәм балаларны рухи яктан баетуга ярдәм итәчәк.

Гомумән, һәр блокның атамасы аның эчтәлегенә тәңгәл килә. Блок системасы төзек: ул үз эчендә я фольклор материалы белән әдәби әсәрне бергә бәйләүгә, я әдәби әсәрнең сәнгатьнең берәр төре белән бәйләнешенә игътибар итүгә йөз тота. Шул ук материалларга нигезләнеп, әдәби-теоретик төшенчәләр дә урын ала.

Шулай итеп, программага салынган мәгълүмат, минимакс принцибын исәпкә алып (материал озак үзләштерүче укучыга да, көчле укучыга да җитәрлек), 70 сәгатькә исәпләнгән. Әгәр әдәбият дәресләре атнага бер сәгать кенә укытылса, материалны укытучы үзе сайлап ала. Әдәби әсәрләрне үзләштерү ике юнәлештә бара: төп уку өчен һәм сыйныфтан тыш уку өчен тәкъдим ителгән әсәрләр. Төп уку өчен бирелгән әсәрләр укучы тарафыннан үзләштерелергә, сорау һәм биремнәр, теоретик төшенчә белән бәйләп хәтердә калдырылырга тиеш. 8 нче сыйныф дәреслеге белән эшләү өчен, укытучыларга әлеге методик әсбап тәкъдим ителә. Ул керештән, максат-бурычлардан (шәхси, метапредмет, предмет), җиһазлаудан, уку мәсьәләсен кую, уку мәсьәләсен чишүдән, көтелгән нәтиҗәләр дә урын алган үрнәк дәрес эшкәртмәләре салынган төп өлештән, «Календарь-тематик план»нан, укучыларның белем-күнекмәләрен бәяләү өчен, ике варианттагы тест биремнәреннән тора.

Сыйныфтан тыш уку (өстәмә әдәбият) өчен урнаштырылган әсәрләр, җыр текстлары, картиналар укытучы эшен җиңеләйтү өчен бирелә. Аларны вакыт иркен чакта яки укучыларның мөмкинлекләре югары булганда файдаланырга мөмкин. Шул ук вакытта аларны каникул вакытында укырга бирергә дә була.

Әлеге УМКны төзү барышында, рус телендә сөйләшүче балалар үзләштерә алырлык дип исәпләнгән, татар әдәбиятындагы иң гүзәл, бала күңеленә матурлык орлыклары сала торган әдәби әсәр үрнәкләре сайлау белән беррәттән, бала фантази-

ясе, аны әйләндереп алган дөнья белән бәйләнешле текстлар сайланды. Укучы әдәби әсәрне укып, эчтәлеген сөйләп, андагы җөмлә конструкцияләрен хәтерендә калдырып кына бармас, ул әдәби әсәрнең төзелешен аңларга, сәнгатьчә матурлык тудыру чараларының кайберләрен күреп таный белергә дә өйрәнер дип ышанабыз.

### УМК эчтәлеген үзләштерү өчен методик киңәшләр

Әлеге методик әсбап татар әдәбияты укытучысына методик ярдәм күрсәтү максатыннан язылды. Рус телле балаларга махсус төзелгән дәреслекләр белән эшләү вакытында әдәбият укыту алымнары, чаралары, ысуллары, технологияләре дә үзгәреш кичерә. Рус балаларына татар әдәбиятын укыту барышында файдаланылган методлар арасында өстенлек иҗади уку (сәнгатьле уку), репродуктив (Н.И.Кудряшев классификациясе) методларга бирелә. Бу ысулларга таяну нәтиҗәсендә, укучыларның әдәби әсәр текстын дөрес интонация белән укуы, сәнгатьле уку күнекмәләре булдыруы, укытучы укыганны аңлавы, татар мәдәнияте, сәнгате, әдәбияты турында укытучы җиткергән мәгълүматларны тиешле дәрәҗәдә үзләштереп баруы күздә тотыла. Балаларның үзләштерү дәрәҗәсен тикшерү өчен, эзләнү методыннан файдалану уңышлы. Төрле ысулларга мөрәҗәгать итү нәтиҗәсендә, әдәбият дәресләрендә киң кулланылышта йөрергә тиешле алымнарны да ачыклый алабыз.

Рус телле аудиториядә киң файдаланыла торган түбәндәге алымнарны күрсәтик: укытучы сүзе (сөйләве), сәнгатьле уку, портрет белән эшләү, укучы сөйләве, кыскача эчтәлек сөйләү, бер әсәрне икенче әсәр белән чагыштыру, әдәби әсәрдәге вакыйгаларны тормыш-көнкүреш белән бәйләү һ.б. Шуның белән беррәттән метод һәм алымнарны төрләндерү, укучыларның яшь үзенчәлекләрен исәпкә алу, аларның әдәби үсеш үзенчәлекләренә таяну, башка халыклар әдәбиятын кабул итәргә һәм чагыштырырга өйрәтү әдәбият дәресләренең нәтиҗәлелеген күтәрүгә хезмәт итә.

### Рус телле балаларга әдәби әсәрне укыту, өйрәтү юллары

**1. Әсәрне уку**

PIRLS һәм PISA дип аталган халыкара тикшеренүләр нәтиҗәләренә караганда, башлангыч мәктәпне тәмамлаган Россия ба-

лалары — укуда югары нәтиҗәләр, ә төп урта белемне алган укучылар түбән нәтиҗәләр күрсәтә. Чөнки 5 нче сыйныфтан башлап, уку техникасына да, укучы укуына да игътибар кими. Укуны башлангыч мәктәп программасы материалы гына дип исәпләп, бары тик анализ эшенә генә күчелә. Шул рәвешле, уку гамәленә аерым игътибар кими барып, бөтенләй юкка чыга, бала бирелгән өзекләрне бернинди мөнәсәбәтсез генә укып чыга һәм берни дә аңламый.

Уку проблемасына физиологлар да игътибар итә башлады. Алар начар укуны, аның нәтиҗәсезлеге белән бәйләп, текстка салынган мәгънәне аңламауга, андагы төп фикерне аерып чыгармауга, эчтәлек сөйләүнең уңышлы алым түгеллегенә, эзлекле булмавына, тексттагы фикерне шәхси фикер белән бәйли алмауга игътибар иттеләр. Академик М.М.Безруких җитәкчелегендәге тикшеренүчеләр, күзәтүләренә һәм экспериментларына нигезләнеп, уку күнекмәсе формалаштыру этапларын аерып чыгарып, түбәндәге нәтиҗәләрне тәкъдим иттеләр:

| **Уку күнекмәсе барлыкка килүнең дәрәҗәләре** | **Күнекмәләр ситемасы** |
|---|---|
| Элементар уку дәрәҗәсе (уку техникасы) | — Билгеләрне һәм аларның тезмәсен хатасыз уку<br>— Сүзләрне хатасыз уку<br>— Сүзләрнең мәгънәсен аңлау<br>— Җөмлә эчендәге сүзләр бәйләнешен һәм җөмләне аңлау |
| Кычкырып грамоталы уку дәрәҗәсе | — Текстның гомуми эчтәлеген аңлау<br>— Текстагы төп фикерне аерып чыгара алу<br>— Текстагы вакыйгаларның эзлеклелеген аңлау (текстның логикасы)<br>— Тексттан соралган мәгълүматны таба белү<br>— Текстның төп эчтәлеген сөйли белү |
| Үзлектән грамоталы уку дәрәҗәсе | — Текстның гомуми эчтәлеген аңлау<br>— Текстагы төп фикерне аерып чыгара алу |

| | |
|---|---|
| | — Текстагы вакыйгаларның эзлеклелеген аңлау (текстның логикасы)<br>— Тексттан соралган мәгълүматны таба алу<br>— Текстның төп эчтәлеген сөйли белү<br>— Мәгълүматның эзлеклелеген аңлау, шәрехли алу<br>— Текстның эчтәлеген рефлекцияләү<br>— Текстның формасын рефлекцияләү<br>— Аңлау һәм текстның кыскача эчтәлеген сөйләү (шәхси күзаллау, фикерләү) |

Рус телле балаларга татар теле чит тел булуын исәпкә алып, әдәби әсәрләрне укыганда, танышу өчен уку *(ознакомительное чтение),* кирәкле мәгълүматны табу өчен уку *(просмотровое чтение)* төрләре беренче урында тора. Бу вакытта зур күләмле әсәрләрне сүзгә-сүз тәрҗемә итү кирәк түгел, укучылар күп материал арасыннан иң мөһимен аңларга, аерып алырга өйрәнәләр. Шулай ук әдәби әсәрнең матурлыгын күрергә, эчтәлекне аңларга ярдәм итә торган түбәндәге уку төрләрен аерып чыгарырга мөмкин:

— рациональ һәм эмоциональ;
— функциональ һәм эстетик;
— репродуктив һәм иҗади;
— эш вакытындагы һәм ял итү вакытындагы (ирекле, гедонистик);
— тиз һәм акрын;
— кычкырып уку яки эчтән, ярымтавыш белән уку;
— үзе генә яки чылбыр буенча, рольләргә бүлеп;
— төрле интонация төсмерләре өстәп уку (бер үк шигырьне, истә калдыру өчен, күп тапкыр уку ялыктырмасынга).

Әйтелгәннәргә өстәп, укучыларның еш мөрәҗәгать итә торган уку төре — экраннан укуга игътибар итү дә мөһим. Экраннан укуның түбәндәге факторларын аерып чыгарырга була: 1) укучы үзе дә текстны язарга мөмкин; 2) экранның йөрешен программа белән көйләргә була; 3) электрон текстның төзелеше гипертекст рәвешендә бирелгән, ул укучыга уку эзлеклелеген сайлау мөмкинлеге тудыра; 4) экрандагы текст хәрефләр, авазлар символы ярдәмендә генә тәкъдим ителми, ә башка билгеләр

(символ, иллюстрация, видеоклип һ.б.) ярдәмендә дә булырга мөмкин.

Әсәрне аңлауны тикшерү традицион укытуда еш кына эчтәлек сөйләүгә кайтып кала. Рус телле балаларга татар әдәбиятын укытканда, бу мәсьәләгә башкача караш булырга тиеш. Күләмле әдәби әсәрнең эчтәлеген сөйләү укучының бу әсәр турында гади җөмләләр белән төзелгән үз фикере формасында булу мөһим. Моңа ирешү өчен, дәреслектә гади җөмләләрне текст эчтәлеге белән чагыштыру, дөрес тәртиптә кую, фикернең кайсы геройныкы булуын белү, әсәрне өлешләргә бүлү, план төзү кебек биремнәр бар.

Шундый ук гади җөмләләр белән анализ элементларын кулланып әсәрне тикшергәч, укучыларга бу әсәр турында үз сүзләре белән кыскача фикер әйтү авыр булмас дип уйланылды.

**2. Әдәби-теоретик төшенчәләр белән эшләү**

Рус мәктәбендә укучылар рус әдәбияты дәресләрендә тирән белем ала, адаптацияләнгән әдәби әсәрләр белән таныша һәм аларны анализларга, бәяләргә өйрәнә. Укучылар рус әдәбияты дәресләрендә алган теоретик белемнәрне татар әдәбияты дәресләрендә дә уңышлы гына файдалана алалар. Шул үзенчәлекне истә тотып, һәр сыйныфта рус әдәбияты дәресендәге теоретик төшенчәләр кабатланып барыла. Әдәби-теоретик төшенчәләрне бирүнең эчтәлеге дә үзгәрә: төшенчәнең татарча аталышы гына истә калдырыла, ә аңлатма рус әдәбияты дәресендә бирелгәнчә саклана. Балалар телне тирәнрәк үзләштергән очракта, укытучы бу теоретик үзенчәлекләрнең әсәрдә барлыгына игътибарны юнәлтә яки аны яхшы әзерлекле балаларга өстәмә эш итеп тәкъдим итә.

**3. Язучыларның һәм сәнгать әһелләренең биографиясен өйрәнү**

Әдәбият дәресләрендә рус телендә сөйләшүче балаларга татар әдипләре турында мәгълүмат бирелә. Әдипләрнең тормыш һәм иҗат сәхифәләре белән таныштыруны түбәндәге дүрт төргә бүлеп карый алабыз:

1) тормыш юлы һәм иҗатын өйрәнгәндә, әдип үткән гомер юлы турында сөйләнелә һәм иҗатының барлык якларын иңләгән мәгълүмат бирелә, ләкин укучылардан бу мәгълүматны тулысынча истә калдыру, сөйләү таләп ителми;

2) биографик белешмәне күз уңында тотканда, әдипнең тормыш һәм иҗат юлындагы аерым сәхифәләре белән таныштырыла. Әдипкә бәя бирү истәлекләргә таянуга, иҗатның аерым якларына бәя бирүгә юнәлтелергә мөмкин;

3) язучы яки шагыйрьнең язмышы дигән вакытта, иҗат эшчәнлегенә бик кыска гына бәя бирелә, ә аның ил күләмендә һәм әдәбият-сәнгать тарихында тоткан урынын ачыклау алгы планга чыга;

4) әдипнең иҗатының бер генә юнәлешенә игътибар итү очраклары да бар. Алар, мәсәлән, «Фәнис Яруллин — прозаик» рәвешендә тәкъдим ителә. Шуңа күрә әдип эшчәнлегенең бары тик бер ягын гына аерып чыгарып өйрәнү күздә тотыла.

Әдәбият дәресләренең төп максаты — балаларны әдәби әсәр укырга тарту, аның турында фикер әйтергә өйрәтү икәнлеген исәпкә алып, әдәби текстны сайлау принципларына һәм аларның дәреслекләрдә бирелү рәвешенә дә тукталыйк. Рус телендә сөйләшүче балалар өчен татар телендә язылган матур әдәбият әсәрләрен үзләштерү эшенең авыр булуын исәпкә алып, әдәби әсәрләрдән (хәтта шигырьләрдән дә) өзекләр тәкъдим итү уңышлы. Ләкин дәреслек төзегән вакытта әдәби әсәр турында тулы мәгълүмат (аңлатма рәвешендә генә булса да) биреп бару күздә тотыла.

**4. Әдәби әсәрне анализлау**

Рус телендә сөйләшүче балаларның тел белү дәрәҗәсе түбән булу сәбәпле, әдәби әсәрне анализлау эше дә катлаулы булачак. Шуны истә тотып, дәреслек төзегән вакытта, баланың әсәргә шәхси мөнәсәбәтен ачарлык, аның хисләренә йогынты ясаган якларны күрсәтерлек сорау һәм биремнәр тәкъдим ителде. Бу биремнәр ярдәмендә, әдәби анализ элементлары кертеп, эчтәлек буенча фикер алышу оештырыла. Бу вакытта авырсынган укучылар фикерләрен рус телендә әйтергә мөмкин, ләкин укытучы ул фикерне татарчага тәрҗемә иттерә.

**5. Язма сөйләм**

Әдәбият дәресләрендә балаларны текст укырга, аны сөйләүгә генә тарту җитми. Һәр дәрестә язу эшенә игътибар итәргә кирәк. Бу бигрәк тә сөйләм үстерү дәресләренең дәвамы булып торса яхшы. Балаларның эзлекле фикерли белүе күбрәк язма эшләр башкарганда ачыла.

**6. Иҗади эш**

Рус мәктәбендә укучы рус телле балаларга татар әдәбияты укыту барышында иҗади эшчәнлек төрләренә аерым игътибар итү сорала. Аларның берничә шартын ачыклап китү кирәк: беренчедән, укучылар татар теленнән һәм әдәбияттан БДИ биргән вакытта әсәрдән алынган өзек белән очрашалар, икенчедән, укытучы үзе дә мөстәкыйль әсәр өзекләре сайлый, аларны укучыларга тәкъдим итә, өченчедән, төрле дәрәҗәдә уза торган конкурслар, конференцияләр, олимпиадаларда да шушы юнәлеш алгы планга куела.

Бу юнәлештә дәреслектә котлау, хат язу, үзләре, туганнары турында язу, әдәби геройга киңәшләр бирү, текстны үзгәртү кебек биремнәр белән бергә проект эшләре дә тәкъдим ителә.

## Әдәбият дәресләренең материаль-техник яктан тәэмин ителеше

Рус телле балалар татар әдәбиятын үзләштерү барышында түбәндәге техник чараларга игътибар итәргә тиеш:

- мультимедиа чаралары;
- Интернет-ресурслар;
- махсус сайтлар.

## 8 нче сыйныф укучыларының әзерлек дәрәҗәсенә таләпләр:

- әдәби әсәрләрне, сүзләрен дөрес әйтеп, йөгерек уку;
- авторның әйтергә теләгән фикерен аңлау, үз мөнәсәбәтен белдерү, әсәрне өлешләргә бүлә һәм планын төзи белү;
- әдәби-теоретик төшенчәләрне рус әдәбияты белеме белән тәңгәлләштерү;
- татар әдәбиятының һәм тарихи мәгълүматларның дөнья культурасында тоткан урынын аңлау;
- авторларның тормыш юлы һәм иҗаты турында кыскача күзаллау;
- 11—12 татар, рус, чит ил язучы-шагыйрьләренең исемнәрен һәм алар язган әсәрләрне белү;
- 5—6 сәнгать әһеленең тормышы, иҗаты турында мәгълүматлы булу;

• Казан һәм Татарстан төбәгендәге мәдәният учаклары (музей, театр, тыюлык, концерт залы һ.б.), балалар матбугаты турында белү;

• төрле халыкларның фольклор үрнәкләрен татар халык авыз иҗаты белән чагыштыру;

• 7 мәкаль, 7 әйтемне русча эквивалентлары белән истә калдыру;

• төрле авторларның 3—4 шигырен яттан сөйли белү;

• сүзлекләр, энциклопедияләр, Интернет-ресурслардан файдаланып, үзенә кирәкле материалны табу;

• төрле темаларга проект эше яклау;

• әдәби әсәрне тормыш белән бәйләп, үз гамәлләренә бәя бирү.

## 8 НЧЕ СЫЙНЫФ ӨЧЕН

| Дәрес № | Дәрес темасы | Дәрес саны | Төп эчтәлек | Көтелгән нәтиҗә | | |
|---|---|---|---|---|---|---|
| | | | | метапредмет | предмет | |
| **Тарих китабында безнең өчен бик күп хатирәләр саклана...** | | | | | | |
| 1 | Ачыла тарихның пәрдәсе. | 1 | Халык авыз иҗаты, риваять жанрына гомуми күзаллау булдыру. «Сихерче кыз» риваятен уку. | Риваять жанры турында теоретик төшенчәне бирү, халкыбыз тарихы белән бәйләү. | Халык авыз иҗаты турындагы белемнәрне гомумиләштерү, риваять турында белешмә бирү, татар халкының «Сихерче кыз» риваяте белән танышу. | |
| 2 | Сезгә — ялган, миңа — чын. | 1 | «Гали тугае», «Моргана» риваятьләрен уку. | Укучыларга халкыбызның тарихы турында белем бирү. | Риваять турында алган белемнәрне ныгыту, татар халык риваятьләре белән танышуны дәвам итү. | |
| 3 | Дәрес-проект «Халыкныкы халыкта саклана». | 1 | Укучыларның бәйләнешле сөйләм телен үстерү. Риваять темасын гомумиләштереп кабатлау. | Укучыларга халкыбызның тарихы турында белем бирү, шәһәр, авыл, елга исемнәренең килеп чыгышын аңлату. | Риваять турында алган белемнәрне ныгыту. | |
| 4 | Сезгә — ялган, миңа — чын. | 1 | Легенда жанрына гомуми күзаллау булдыру. | Легенда жанры турында теоретик төшенчә бирү. | Татар халык авыз иҗаты жанрлары белән танышуны дәвам итү, легенда жанрын өйрәнү, «Зөһрә кыз» легендасын уку. | |

## КАЛЕНДАРЬ-ТЕМАТИК ПЛАН

| | | Укучылар эшчәнлеге төрләре | Контроль эш төрләре | Үткәрү вакыты план / факт |
|---|---|---|---|---|
| | шәхескә кагылышлы | | | |
| | | | | |
| | Укучыларда үткәнебезгә, тарихыбызга карата игътибар тәрбияләү. | Дәреслектә биремнәр, риваять белән әкиятнең уртак якларын табу, нәтиҗәләр чыгару. «Сихерче кыз» әкиятен уку. | | |
| | Балаларда татар халкы һәм башка халыклар риваятьләренә, халыкларның үткәненә кызыксыну тәрбияләү. | Риваятьләр уку, сорауларга җавап бирү, биремнәр үтәү. Проект эшенә әзерләнү. | | |
| | Балаларда татар халык риваятьләренә, үткәненә, атамаларның килеп чыгышына кызыксыну тәрбияләү, дөрес бәяләү күнекмәләре булдыру. | Проект тәкъдим итү, яклау. | | |
| | Балаларда татар халык легендаларына, башка халык легендаларына, халыкларның үткәненә кызыксыну тәрбияләү. | Әсәрне уку, сорауларга җавап бирү. Легенда белән риваятьләр арасында аермалы якларны билгеләү, таблица белән эшләү. | Тест | |

| | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|
| 5 | Моңы барның йөрәгеннән һәрвакыт җылы чыгар. | 1 | Милли уен кораллары белән танышу. | Эстетик тәрбия бирү. | Халык авыз иҗаты турындагы белемнәрне гомумиләштерү, халык музыка уен коралла-ры турында белешмә бирү, танышу, проект эшен яклау. | |
| **Без тарихта эзлебез** | | | | | | |
| 6 | Тарих — тормыш остазы. | 1 | Ибне Фадлан һәм аның 921 — 922 нче елларда Болгар дәүләтенә сәфәре вакытында язылган сәяхәтнамәсе белән танышу. | Болгар дәүләтенең ил тарихындагы ролен ачыклау, сәяхәтнамәләр һәм елъязмалар жанры турында теоретик төшенчә формалаштыру. | Гарәп сәяхәтчесе Ибне Фадлан турында белешмә бирү. Ибне Фадланның 921 — 922 нче елларда Болгар дәүләтенә сәфәре вакытында язылган сәяхәтнамәсен өйрәнү. | |
| 7 | Гыйлемсез кеше — канатсыз кош. | 1 | Фатих Кәрими иҗаты. «Аурупа сәяхәтнамәсе» белән танышу. | Мәдәният учакларына тарихи күзәтү. | Фатих Кәриминең тормыш юлы һәм иҗатын, «Аурупа сәяхәтнамәсе»н өйрәнү. | |
| 8 | Энҗе табучы әдип. | 1 | Миргазиян Юныс иҗаты. «Су» хикәясен уку. | Язучы яшәгән чорга бәя бирү, тарихны аңлау. | Миргазиян Юнысның тормыш юлы һәм иҗатын, «Су» хикәясен өйрәнү. | |

| | | | | |
|---|---|---|---|---|
| | Балаларда татар халык музыка уен коралларына, халыкларның үткәненә кызыксыну тәрбияләү. | Бәйләнешле сөйләм үстерү, табышмакларның җавабын табу, шигырь уку, сорау-җавап формасында шигырьгә анализ ясау. | Проект | |
| | | | | |
| | Мәдәниятебезгә, тарихыбызга горурлык хисе тәрбияләү. | Өзекне уку, сорауларга җавап бирү, сүзлек эше, диалог, Л.Фәттаховның картинасы, дәреслектәге биремнәр белән эш. | | |
| | Сәнгать җәүһәрләренә, халкыбыз мирасына, белем алуга омтылыш тәрбияләү. | Өзекне уку, сораулар төзү, җавап бирү, нәтиҗә ясау, тәрҗемә, өзекне өлешләргә бүлү, төркемнәрдә эшләү, анализ. | тест | |
| | Туган илне сагыну, Ватанга, туган җиргә, табигатькә мәхәббәт хисләре тәрбияләү. | Фронталь әңгәмә, язучы турында презентация карау, сәнгатьле уку, сорауларга җавап, анализ, тәрҗемә, сүзлек белән эш, биремнәр эшләү. | тест | |

| | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|
| 9 | Җиктереп пар ат, Казанга! | 1 | Габдулла Тукай иҗаты. «Пар ат» шигырен өйрәнү | Габдулла Тукай яшәгән чор турында тарихи белешмә бирү. | Габдулла Тукайның тормыш юлы һәм иҗаты турында өстәмә мәгълүмат, «Пар ат» шигырен уку. | |
| 10 | Монда хикмәт, мәгърифәт һәм монда гыйрфан, монда нур... | 1 | «Пар ат» шигыренә анализ. | Тема буенча теоретик төшенчәләрне бирү. Әдәбитеоретик күнекмәләр булдыру. | Габдулла Тукайның «Пар ат» шигырен өйрәнү. Лирик әсәрне аңларга, андагы хискичерешләрне тоярга, аларның үсү-үзгәрүен яки алмашынуын күрергә әзерләү. | |
| 11 | Милли мәдәниятебезне үстерүдә Бакый Урманче иҗаты. | 1 | Бакый Урманче иҗаты белән танышу. | Рәсем сәнгатенә карата кызыксыну уяту. «Триптих» сәнгать төшенчәсен аңлату. | Бакый Урманченың тормыш юлы һәм иҗатын өйрәнү. | |
| 12 | Нажар Нәҗми — Тукай шәкерте. | 1 | Нажар Нәҗми иҗаты, «Агыйделдә — ак пароход» әсәре. | «Тел», «халык», «тарих» төшенчәләрен аңлауга ирешү. | Нажар Нәҗминең тормыш юлы һәм иҗаты турында белешмә бирү, «Агыйделдә — ак пароход» әсәрен өйрәнү. | |

| | | | | |
|---|---|---|---|---|
| | Татар халкының бөек әдипләре иҗатын өйрәнү аша тормышка караш тәрбияләү. | Сәнгатьле уку, видеоязма карау, шигырьне язмада тыңлау, сүзлек эше, сорауларга җавап, төркемнәрдә эзләнү, тикшерү, фикер алышу, нәтиҗә чыгару. | тест | |
| | Туган җиргә, Ватанга мәхәббәт тәрбияләү. | Сәнгатьле уку, «Пар ат» җыры видеоязмасын карау, шигырьдәге строфа арты строфаны күзәтү, алардагы хисне һәм аны тудырган сәбәпне ачыклау, хисләр көчешен тою, шул көчешкә салынган мәгънәне аңлау, биремнәр эшләү. | | |
| | Татар халкының бөек шәхесләренә, аларның иҗатына кызыксыну уяту; сирәк очрый торган талантка ия булган сынчы иҗаты белән горурлану хисләре тәрбияләү. Әхлак тәрбиясе бирү. | Әңгәмә, өзекне уку, виртуаль экскурсия, презентация, «Туган тел» җыры, диалог төзү, сорауларга җавап, картина буенча эш, сүзлек эше. | тест | |
| | Милли үзаң тәрбияләү, туган телгә, милли тарихка ихтирам хисе уяту. | Һәр абзацны уку, эчтәлекне аңлаганны тикшерү өчен, гади сораулар бирү, сүзлек өстендә эш, тәрҗемә эше. | | |

| | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|
| 13 | Үзенең үткәнен оныткан халыкның киләчәге юк. | 1 | Укылган әсәрләрне, теоретик төшенчәләрне кабатлау. | Өйрәнелгән материалны искә төшереп, гомумиләштереп куллана белү. | Укылган әсәрләрне, теоретик төшенчәләрне истә калдыру. | |
| **Онытылмас еллар** | | | | | | |
| 14 | Билгесез биеклектә. | 1 | Рәссам Виктор Куделькин иҗаты. Гариф Ахуновның «Замандашлар портреты»н уку. | Бөек Ватан сугышы чоры турында белемнәрне яңарту. | Рәссам Виктор Куделькинның тормышы, иҗаты турында мәгълүмат бирү. Гариф Ахуновның «Замандашлар портреты»н уку. | |
| 15 | Тырышса да дошман, шагыйрьләрне аералмый җырдан, халыктан. | 1 | Роберт Әхмәтҗановның «Солдатлар» һәм татар халык җыры «Герман көе» белән танышу. | Музыка сәнгатенең матур әдәбият белән тыгыз бәйләнештә булуын һәм бер-берсенә йогынты ясауларын күзәтү. | Бөек Ватан сугышына багышланган җырлар турында белешмә бирү. Татар халык җыры «Герман көе» һәм Роберт Әхмәтҗановның «Солдатлар» җырларын өйрәнү. | |
| 16 | Патриот-шагыйрь. | 1 | Фатих Кәрим иҗаты. «Ант» шигырен өйрәнү. | Бөек Ватан сугышында катнашкан әдипләр турында тарихи мәгълүматлар бирү. | Фатих Кәримнең тормыш юлы һәм иҗаты белән таныштыру, шигырьләре турында фикер йөртә белергә өйрәтү, аның туган иленә тугрылыклы патриот-шагыйрь булуына басым ясау. | |

| | | | | |
|---|---|---|---|---|
| | Туган җирне ярату, туган як кадере, милләт язмышы, чит илләрдәге милләттәшләребез турында аңлап калу; туган җиргә, милләттәшләребезгә ихтирам хисләре тәрбияләү. | Бәйләнешле сөйләм үстерү, проектлар яклау, әңгәмә, сорауларга җавап, викторина, ярыш, тәрҗемә, сүзлек белән эш. | | |
| | | | | |
| | Сугыш авырлыгын үз җилкәләрендә күтәргән яшь буынга, шул чор кешеләренә ихтирам тәрбияләү. | Сәнгатьле уку, эчтәлек буенча төркемнәрдә фикер алышу, әсәргә җиңелчә әдәби анализ ясау, сораулар һәм биремнәргә җавап табу, әсәрне өлешләргә бүлү, план төзү, картина белән эш, җыр тыңлау, тәрҗемә эше. | | |
| | Гражданлык һәм патриотик хисләр, туган җиргә, милләткә карата мәрхәмәтлелек, горурлык хисләре тәрбияләү. | Сәнгатьле уку, җырларны тыңлау һәм өйрәнү, сорауларга җавап, сүзлек өстендә эш, биремнәр эшләү, яңа сүзләрне өйрәнү, шигырьгә анализ ясау, нәтиҗә. | | |
| | Кыюлык, батырлык, туган илгә бирелгәнлек, аны саклый белү сыйфатлары тәрбияләү. | Презентация карау, шигырьне тыңлау, сүзгә-сүз тәрҗемә итү, ярымтавыш белән уку, сәнгатьле уку, җыр тыңлау, анализ, нәтиҗә. | | |

| | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|
| 17—18 | Үлем турында уйлама, илең турында уйла. | 2 | Фатих Кәримнең «Кыңгыраулы яшел гарун» поэмасын уку. | Сәнгатебезгә, халык уен коралларына мәхәббәт тәрбияләү. | «Кыңгыраулы яшел гармун» поэмасының төп фикерен ачыклый һәм аңлата белергә өйрәтү; «образлар системасы» төшенчәсен аңлату. | |
| 19—20 | Исемең калды моңлы бер җыр булып… | 2 | Туфан Миңнуллин иҗаты. «Моңлы бер җыр» драмасы. | Бөек Ватан сугышында катнашкан геройлар тарихы. | Туфан Миңнуллинның тормыш юлы, иҗаты белән таныштыру, «Моңлы бер җыр» драмасын уку һәм нәтиҗә ясау. | |
| 21 | Һәйкәлләргә килик, гөлләр куйыйк, һәйкәлләрне тыңлыйк тын гына. | 1 | Казанда Муса Җәлил һәйкәле һәм җәлилчеләргә куелган барельефлар. | Мәркәзебезнең истәлекле урыннары белән танышу. «Барельеф» төшенчәсен аңлауга ирешү. | Шагыйрь Муса Җәлилнең тормыш юлы һәм иҗаты буенча белемнәрне ныгыту; Марсель Сәлимҗанов һәм Ринат Таҗетдинов эшчәнлеге белән танышу. | |
| 22 | Каз канаты каурый-каурый, хатлар язарга ярый. | 1 | Хат үрнәкләре белән танышу, Бөек Ватан сугышы батырларының фронт хатларын уку. | Эпистоляр жанр турында төшенчә бирү. | Фронт хатларын уку. Хат язу үзенчәлекләрен өйрәнү. | |

| | | | | |
|---|---|---|---|---|
| | Кешелеклелек сыйфатлары, җаваплылык хисе тәрбияләү. | Сәнгатьле уку, Интернет челтәреннән табып тыңлау, өлешләргә бүлү, сорауларга җавап, биремнәр эшләү, образларга характеристика. | | |
| | Туган ил өчен көрәшү, туган илне яклау изге бурыч булуына төшендерү, көчле рухлы булырга өндәү. | Сорауларга җавап эзләү, ишетеп аңлау, рольләргә бүлеп уку, әсәрдә автор әйтергә теләгән фикерне табу, драма әсәре турында фикер алышу, Интернеттан табып өзек карау. Теоретик төшенчәләр (символик образ, диалог, ремарка) белән эш. | | |
| | Ихтыяр көче, рухи ныклык сыйфатлары тәрбияләү, бәйләнешле сөйләм теле үстерү. | Фронталь әңгәмә, сәнгатьле уку, җыр тыңлау, төркемнәрдә эш, дәреслектәге сорауларга җавап бирү, өзекне ике өлешкә бүлү, исем кую, тәрҗемә итү, эпиграфны аңлату,план төзеп сөйләү, нәтиҗә чыгару. | | |
| | Гражданлык һәм патриотик хисләр, туган җиргә, милләткә карата мәрхәмәтлелек, горурлык хисләре тәрбияләү. | Хатларның төрләре, аны язу нормалары, этикеты, бөек кешеләрнең хат үрнәкләре буенча әңгәмә оештыру, аңлатмалы сүзлек белән эш, хатның эчтәлеген сөйләү; сүзлек өстендә эш; иҗатка бәйле сораулар төзү. | | |

| | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|
| 23 | Син күрсәткән батырлыкны, солдат, халкым сөйли мактап бүген дә. | 1 | Мостай Кәрим иҗаты. «Билгесез солдат» шигыре. | Рәсем сәнгате аша Бөек Ватан сугышы турында тарихи мәгълүмат бирү. | Мостай Кәримнең тормыш юлы һәм иҗаты турында белешмә бирү, «Билгесез солдат» шигырен өйрәнү. | |
| 24 | Дөньяда бары тик яхшылык кына үлми. | 1 | Чыңгыз Айтматов иҗаты. «Анам кыры» әсәре. | Бөек Ватан сугышы кырларында илебезнең азатлыгы өчен кан коелуның мәгънәсен укучыларга аңлату. | Чыңгыз Айтматовның тормыш юлы һәм иҗаты турында белешмә бирү, «Анам кыры» әсәрен өйрәнү. | |
| 25 | Без азатлык алып биргән көннәр, хәтерләми икән кем генә! | 1 | «Онытылмас еллар» бүлегендә өйрәнгән материалны кабатлау. | Өйрәнелгән материалны искә төшереп, гомумиләштереп куллана белү. | Әдәбиятта сугыш сурәтләнешен бәяләү. | |
| **Әтинең зур бүреге иртә киелде...** | | | | | | |
| 26 | Җиңүне якынайткан җыр. | 1 | Клара Булатова иҗаты. «Башым иям» шигыре белән танышу. | Сугыш, аның гади халык, балалар җилкәсенә алып килгән авырлыгын аңлау. | Клара Булатованың тормыш юлы һәм иҗаты белән танышу, «Башым иям» шигырен уку. | |

| | | | | |
|---|---|---|---|---|
| | Туган илгә мәхәббәт, белем алуга омтылыш тәрбияләү. | Шагыйрәнең тормыш юлы белән танышып, хронологик таблица тутыру, шигырьне тыңлау, ярымтавыш белән уку, чылбыр буенча уку, сайлап уку, яңа сүзләрне өйрәнү, парлап эшләү, сүзлек белән эш, анализ. | | |
| | Туган илгә, халкыбыз батырлыгына мәхәббәт хисләре тәрбияләү. | Яңа сүзләрне уку, язу, эчтәлек буенча төркемнәрдә фикер алышу, әсәргә җиңелчә әдәби анализ ясау, сораулар һәм биремнәргә җавап табу, әсәрне өлешләргә бүлү, план төзү, өзекне рольләргә бүлеп уку, сүзлекләр белән эш. | | |
| | Патриотик тәрбия бирү, туган илне, туган җирне яратырга өйрәтү. | Бәйләнешле сөйләм үстерү, анализ, гомумиләштерү, нәтиҗә ясау, әңгәмәдә катнаша алу, нәтиҗә ясый белү, үз мөнәсәбәтеңне белдерә алу. | Проект | |
| | | | | |
| | Якыннарыңа, туганнарыңа карата ихтирам, мәрхәмәтлелек хисләре тәрбияләү. | Фронталь әңгәмә, язучы турында презентация карау, шигырьне тыңлап аңлау, сәнгатьле уку, анализ ясау, дәреслектәге сорауларга җавап бирү. | | |

| | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|
| 27—28 | Тынычлыкның туган көнен бәйрәм итә бүген илем. | 2 | Нур Әхмәдиев иҗаты. «Җиңү көне» шигыре, «Минем туган көнем» хикәясе. | Бөек Ватан сугышы, аның гади халыкка китергән авырлыклары турында тарихи мәгълүмат бирү. | Нур Әхмәдиевнең тормыш юлын һәм иҗатын, «Җиңү көне» шигырен, «Минем туган көнем» хикәясен өйрәнү. | |
| 29—30 | Шәфкатьлелек бизи кешене! | 2 | Факил Сафин иҗаты. «Тулганай» әсәре. | Текст белән эшләү, иң әһәмиятлесен таба белергә өйрәнү. | Факил Сафинның тормышын һәм иҗатын, «Тулганай» әсәрен өйрәнү. | |
| 31 | Таң булып нур сибә Ватаным. | 1 | Рәзил Вәлиев иҗаты. «Ватаным» шигыре. | Сугыш, аның гади халык, балалар җилкәсенә алып килгән авырлыгын аңлау. | Разил Вәлиевның тормыш юлын һәм иҗатын, «Ватаным» шигырен өйрәнү. | |
| 32 | Җиңү көне җиңел бирелмәде. | 1 | «Вакыт сынавы аша». Проектлар яклау. | Өйрәнелгән материалны искә төшереп, гомумиләштереп куллана белү. | Әлеге бүлектә өйрәнгән материалны кабатлау, үзләштерү дәрәҗәсен билгеләү. | |
| **Ана — изге, Ана — бөек, аңа — дан!** | | | | | | |
| 33 | Бәхет эзләгәндә. | 1 | Шәриф Камал иҗаты. «Буранда» хикәясен уку. | Тарихи вакыйгаларга нигезләнеп, әсәр геройлары яшәгән чорга характеристика бирү. | Шәриф Камалның тормышы һәм иҗаты белән танышу, «Буранда» хикәясен уку. | |

| | | | | |
|---|---|---|---|---|
| | Якыннарына, туганнарына карата ихтирам, мәрхәмәтлелек хисләре тәрбияләү. | Биографияне укып, сорауларга җавап эзләү, шигырьне сәнгатьле уку, сайлап уку, яңа сүзләрне өйрәнү, шигырьгә анализ ясау. | | |
| | Әниләргә карата ихтирам тәрбияләү. | Сүзлекчә белән эшләү, яңа материалның таныш әсәрләр белән бәйләнешен табу, әсәргә сорау-җавап формасында анализ ясау, образларга характеристика бирү, таблица белән эшләү. | | |
| | Туган ил белән горурлану, аның тарихына кызыксыну, туган җиргә мәхәббәт хисе тәрбияләү. | Презентация карау, шигырьне тыңлау, сүзгә-сүз тәрҗемә итү, ярымтавыш белән уку, сәнгатьле уку, анализ. | Тест | |
| | Патриотик тәрбия бирү, туган илне, туган җирне яратырга өйрәтү. | Бәйләнешле сөйләм үстерү, проектларны яклау. | Проект | |
| | | | | |
| | Геройларның яшәү кыйбласы аша нәтиҗәләр ясау һәм укучыларда әниләргә карата шәфкатьлелек, миһербанлылык хисләре тәрбияләү. | Сәнгатьле уку, беренче өлешкә план төзү, сорауларга җавап бирү, биремнәрне эшләү, сүзлек белән эш, хронологик таблица, образларга характеристика. | Тест | |

| | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|
| 34 | Исән чакта белү кирәк икән эти-әниләрнең кадерен. | 1 | Шәриф Камалның «Буранда» хикәясен өйрәнү. | Укыган әсәрне бүгенгә көн, көндәлек тормыш белән бәйләнештә күзаллый белү. Әдәби деталь турында теоретик төшенчә бирү. | Шәриф Камалның «Буранда» хикәясен өйрәнү. | |
| 35 | Тайгак кичүләрне кичкән шагыйрь. | 1 | Ибраһим Салахов иҗаты. «Колыма хикәяләре» циклыннан «Ана тавышы» өзеге. | Тарихи вакыйгаларга нигезләнеп, әсәр геройлары яшәгән чорга характеристика бирү. | Ибраһим Салаховның тормышын һәм иҗатын, «Ана тавышы» өзеген өйрәнү. | |
| 36 | Тетрәндергеч еллар авазы. | 1 | Ибраһим Салаховның «Колыма хикәяләре» циклыннан «Ана тавышы» өзеге. | Язучының «Колыма хикәяләре» циклыннан «Ана тавышы» өзегендә сурәтләнгән вакыйгалар аша шәхес культының тирән фаҗигасен тоемлау. | Ибраһим Салаховның Колыма хикәяләре циклыннан «Ана тавышы» өзегенә анализ. | |
| 37 | Ана күңеле — балада. | 1 | Сибгат Хәким иҗаты, «Әнкәй» шигыре. | Укыганнардан нәтиҗә ясап, тормышта куллану. | Сибгат Хәкимнең тормышы һәм иҗатын, «Әнкәй» шигырен өйрәнү. | |

| | | | | |
|---|---|---|---|---|
| | Укучыларда өлкән буынга, әниләргә караша кече яшьтән үк шәфкатьлелек, миһербанлылык хисләре тәрбияләү. | Икенче, өченче өлешләрне уку, план төзү, сорауларга җавап, сүзлек өстендә эш, анализ, образга характеристика, схема белән эш, табигатьтәге буран белән Мостафаның эчке дөньясындагы халәтне чагыштыру, нәтиҗә ясый белү. | | |
| | Укучыларда үткәнебезгә, тарихыбызга карата игътибар тәрбияләү. Чорга дөрес бәя бирә белергә өйрәтү. | Уку, сорауларга җавап, сүзлек өстендә эш, автор идеясен билгеләү, дәреслектәге биремнәрне эшләү. | | |
| | Әхлак тәрбиясе бирү; аналарга тирән мәхәббәт, кешелеклелек, кече күңеллелек, миһербанлылык хисләре тәрбияләргә омтылу. | Әңгәмә, уку, анализ, үз фикереңне әйтә белергә өйрәнү, образларга характеристика, өзек буенча сораулар төзү. | | |
| | Өлкән буынга мәрхәмәтлелек хисләре тәрбияләү. | Шигырьләрне укып, сораулар буенча анализлау, сүзлек белән эш, рифмалашкан сүзләрне табу, тема буенча мәкальәйтемнәрне аңлауга ирешү. | | |

| | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|
| 38 | Җырла-рымда телим... | 1 | Сибгат Хәкимнең «Җырла-рымда телим...» шигыре. | Эколо-гик тәрбия идеяләре ту-рында фикер алышу. | Сибгат Хәкимнең «Җырларымда телим...» шигы-рен уку. | |
| 39 | Әнкәйләр-дән күргән игелек. | 1 | Роберт Миңнуллин иҗаты, «Әнкәй» ши-гыре. | Гаилә кыйммәте төшенчәсен формалашты-ру. | Роберт Миңнуллинның тормышы һәм иҗатын, «Әнкәй» шигы-рен өйрәнү. | |
| 40 | Туган җирләр әнкәй белән бергә... | 1 | Марсель Галиев иҗаты. «Су буеннан әнкәй кайтып килә» шигы-ре. | Марсель Галиев шигъ-рияты турын-да мәгълүмат бирү. | Марсель Галиевның тормышы һәм иҗаты, «Су буеннан әнкәй кайтып килә» шигыре белән танышу. | |
| 41 | Кабатлан-мас әкият. | 1 | Марсель Галиевның «Кабатлан-мас әкият» шигыре. | Халкыбызның тормыш-көнкүреше, элеккеге авыл тормы-шы турында мәгълүмат бирү. | Марсель Галиевның «Кабатланмас әкият» шигы-рен өйрәнү. | |
| 42 — 43 | Ата-анага бурычны бары тик Кеше бу-лып кына түләп була. | 2 | Шәриф Хөсәенов иҗаты, «Әни килде» дра-масын уку. | Драма әсәренә анализ ясау күнекмәләрен ныгыту, эчке конфликт төшенчәсен формалашты-ру. | Шәриф Хөсәеновның тормышын һәм иҗатын, «Әни килде» драма-сын өйрәнү. | |

| | | | | |
|---|---|---|---|---|
| | Туган якка, табигатькә ихтирам тәрбияләү, өлкән буын кешеләренең фикерләрен тыңларга өйрәнү. | Сәнгатьле уку, сүзлек белән эш, анализ, лирик геройга бәя бирү, дәреслектәге биремнәрне эшләү, сораулар төзү, үз фикереңне әйтә һәм нәтиҗә ясый белү. | | |
| | Гаилә, кеше кадере, әти-әни кадерен белергә өйрәтү. | Сәнгатьле уку, тәрҗемә эше, сорауларга җавап бирү, анализ, нәтиҗә ясый белү, җыр тыңлау. | | |
| | Туган җиргә, әниләргә мәхәббәт, белем алуга омтылыш тәрбияләү. | Сәнгатьле уку, җыр тыңлау, сүзлек өстендә эшләү, дәреслектәге биремнәрне эшләү, әсәрнең теленә игътибар итү, лирик геройга бәя бирү, анализ, нәтиҗә чыгару. | | |
| | Укучыларда туган илгә мәхәббәт, белем алуга омтылыш тәрбияләү. | Сәнгатьле уку, образларны табу, аларга характеристика, анализ, тәрҗемә эше, дәреслектәге сорауларга җавап бирү, сораулар төзү, нәтиҗә ясау. | | |
| | Югары әхлакый сыйфатлар тәрбияләү. | Рольләргә бүлеп уку, спектакльне карау, сүзлекләр белән эш, сорауларга җавап, план төзү, эчтәлек сөйләү, образларга характеристика, анализ, нәтиҗә ясау. | | |

| | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|
| 44 | Әти-әни кадере. | 1 | Фоат Садриевның тормышы һәм иҗаты белән танышу, «Таң җиле» романыннан өзекләр уку. | Язучы яшәгән чорга тарихи күзәтү ясау. | Фоат Садриевның тормышы һәм иҗаты белән танышу, «Таң җиле» романыннан өзекләр уку. | |
| 45 — 46 | Ана — бөек исем. | 2 | Фоат Садриев иҗаты. «Таң җиле» әсәре. | Медицина терминнары турында мәгълүмат бирү. | Фоат Садриевның тормышын һәм иҗатын, «Таң җиле» әсәрен өйрәнү. | |
| 47 | Кая барсам — әнкәй күңелдә. | 1 | Әлеге бүлекне гомумиләштереп кабатлау, бәйләнешле сөйләм үстерү. | Команда белән эшләү, проект эше башкарырга өйрәнү. | Укыганны гомумиләштереп кабатлау. Дәреслектә өстәмә уку өчен бирелгән Роберт Миңнуллинның «Әнкәйнең ак чәчләре» шигырен уку. | |
| **Көлсәң — көл, еласаң — ела!** | | | | | | |
| 48 | Күңелсездән көлке чыкмас. | 1 | Сатирик журналлар, Галиәсгар Камал иҗаты. | Сатира жанры турында теоретик төшенчә бирү. | Беренче сатирик журналлар турында мәгълүмат бирү. Галиәсгар Камалның тормышын, иҗатын өйрәнү. | |

| | | | | |
|---|---|---|---|---|
| | Әти-әнигә карата мәххәббәт тәрбияләү. | Язучы биографиясен һәм иҗатын укып истә калдыру, Интернет челтәреннән Фоат Садриев чыгышын тыңлау, әсәрнең беренче өлешен уку. | | |
| | Балаларда бәхетнең кадерен белеп яшәү хисләрен тәрбияләү. | Әсәрне өлешләргә бүлү, эчтәлекнең идеясен таба белү, анализлау, сүзлек өстендә эш, биремнәр эшләү, сорауларга җавап бирү, хронологик таблица төзү, нәтиҗә. | | |
| | Ата-анага җәбер-золым иткән имансыз балаларның дөньяда игелек күрмәүләре, ата-ана каргышы төшү турында тормыштан мисаллар китереп сөйләү. | Бәйләнешле сөйләм үстерү, проект яклау, нәтиҗәләр чыгару, анализ ясау, белемнәрне тикшерү, командалап эшләү, эшне аудиториягә тәкъдим итү, җыр тыңлау. | Тест | |
| | | | | |
| | Әхлак (кешелеклелек, юмартлык) хисләре тәрбияләү. | Беренче сатирик журналлар турында әңгәмә оештыру, сорауларга җавап, дәреслектәге биремнәрне эшләү. Язучының тормыш юлы, иҗаты белән танышу, презентация карау, хронологик таблица тутыру, парларда эшләү, ишетеп аңлау, драматургның тормышы турында сораулар төзү, җавап бирү, сүзлекчә белән эшләү. | | |

| | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|
| 49—50 | Хәйләсез дөнья — файдасыз. | 2 | Галиәсгар Камалның «Банкрот» комедиясе. | Театр сәнгате аша эстетик зәвык тәрбияләү. | Галиәсгар Камалның «Банкрот» комедиясен өйрәнү. Сарказм турында теоретик төшенчәне аңлату. | |
| 51 | Һәр заманның үз герое була. | 1 | Гамил Афзал иҗаты. «Юл газабы» хикәясе. | Язучы яшәгән чорга бәя бирү, тарихны аңлау. | Гамил Афзалның тормышын, иҗатын һәм «Юл газабы» хикәясен өйрәнү. | |
| 52 | Сүз күңелдә очкын булып көйри. | 1 | Гамил Афзалның «Тәвәккәл әби» шигыре. | Сатирик шигырь, ирония турында теоретик төшенчә бирү. | Гамил Афзалны юмор остасы буларак өйрәнү, «Тәвәккәл әби» шигырен аңлап уку, юмор аша язучы теләгән фикерне табарга өйрәнү | |
| 53 | Озын сүзнең кыскасы. | 1 | Зәки Нури иҗаты, пародия, эпиграммалар. | «Пародия», «эпиграмма» төшенчәсе турында белем бирү һәм аларны тормыш белән бәйләү. | Зәки Нури тормышы, иҗаты белән таныштыру, пародияләрен һәм эпиграммаларын укып нәтиҗә ясау, бүлекне йомгаклау. | |

| | | | | |
|---|---|---|---|---|
| | Хезмәткә мәхәббәт, үз эшең белән горурлану хисләрен үстерү. Акча артыннан куу юлындагы кешелексезлек һәм түбәнлек сыйфатларын аңлату. | Рольләргә бүлеп уку, образларга характеристика, сүзлекчә белән эшләү, вакыйгаларга бәя бирү, сорауларга җавап бирү, Интернет челтәреннән спектакльне табып карау, Николай Островскийның «Үз кешеләр — килешербез» («Свои люди — сочтёмся») комедиясе белән чагыштыру, анализ. | | |
| | Китап укуга, белем алуга омтылыш тәрбияләү. Язучы һөнәренә мәхәббәт тәрбияләү. | Презентация ярдәмендә язучы тормышы белән танышу, төркемнәрдә фикер алышу, ишетеп аңлау, сүзлекчә белән эш, укыганны тәрҗемә итү, сораулар, биремнәр үтәү, хронологик таблица тутыру, тест, төркемнәрдә эшләү, сорауларга җавап бирү, өлешләргә бүлү, план төзү, план буенча кыскача эчтәлекне сөйләү. | | |
| | Әхлак тәрбиясе бирү. | Сәнгатьле уку, теоретик төшенчәләрне аңлату, шигырьне өлешләргә бүлү, исем кую, автор идеясен билгеләү, сүзлек өстендә эш, шигырьне тыңлау, ярымтавыш белән уку, чылбыр буенча уку, сайлап уку, яңа сүзләрне өйрәнү. | | |
| | Дөреслекне аңлау, аны яклау һәм дөреслек белән яшәү мәгънәсен аңлату. | Сәнгатьле уку, теоретик төшенчәләрне аңлату, сүзлек өстендә эш, фикер алышу, парлап сөйләшү, сорауларга җавап бирү, | | |

| | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|
| 54. | Көлке дисәң дә көлке! | 1 | «Көлсәң — көл, еласаң — ела!» бүлеген гомумиләштереп кабатлау. | Укыганны гомумиләштерә, нәтиҗә ясый, иң мөһим мәгълүматны аерып ала белү. | «Көлсәң — көл, еласаң — ела!» бүлегендә өйрәнгән материалны кабатлау, үзләштерү дәрәҗәсен билгеләү. | |
| **Даһи гомере — халкы хәтерендә!** | | | | | | |
| 55 | Көйләрдән тезмәләр тездем. | 1 | Ренат Харис иҗаты. «Гармунчы» поэмасы. | Укучыларда эстетик зәвык тәрбияләү. | Ренат Харисның тормышы, иҗаты һәм «Гармунчы» поэмасын өйрәнү. | |
| 56 | Минем тирәмдә Кояш үзе әйләнә. | 1 | Ренат Харисның «Ике гөл» шигыре. | Укучыларга экологик тәрбия бирү. | Ренат Харисның «Ике гөл» шигырен уку. | |
| 57 | Шигырем — ачык! | 1 | Зөлфәт иҗаты. «Шигырем — ачык!» шигыре. | Татар шигъриятенә кызыксыну уяту. | Зөлфәтнең тормышын, иҗатын һәм «Шигырем — ачык!» шигырен өйрәнү. | |
| 58 | Ерактагы моңлы бер көй булып… | 1 | Зөлфәтнең «Шундый чагы әле җанымның» шигыре. | Иҗат процессына мәхәббәт тәрбияләү. | Зөлфәтнең «Шундый чагы әле җанымның» шигырен уку. | |
| 59 | Ил җыр белән яши. | 1 | Галия Кайбицкая иҗаты. | Опера сәнгате аша эстетик тәрбия бирү. | Галия Кайбицкая иҗатын өйрәнү. | |

| | | | | |
|---|---|---|---|---|
| | Әйләнә-тирәдәге вакыйгалардан, кешеләрнең гамәлләреннән гыйбрәт ала белүнең табигате, тәртибе турында фикер алышу. | Бәйләнешле сөйләм үстерү, укыганнарны искә төшереп, гомумиләштереп кабатлау. Тексттан мисаллар китереп, теорияне искә төшерү, белемнәрне тикшерү. | Тест | |
| | | | | |
| | Гармунчы һөнәренә мәхәббәт тәрбияләү. | Шагыйрьнең тормыш юлы, иҗаты белән танышу, презентация карау, хронологик таблица тутыру, поэманы тыңлау, ярымтавыш белән уку, чылбыр буенча уку, сайлап уку, яңа сүзләрне өйрәнү, парлап сөйләшү. | | |
| | Табигатькә карата күзәтүчәнлек тәрбияләү. | Сәнгатьле уку, сораулар буенча анализлау, мәсәлгә хас үзенчәлекләрне табу, монолог уку, диалог төзү, образларны чагыштыру, мәкальләр уку, мәгънәләрен ачыклау, нәтиҗәләр ясау. | | |
| | Язучы һөнәренә мәхәббәт тәрбияләү. | Язучы иҗатына күзәтү ясау, сәнгатьле уку, анализ, сүзлек эше, сорауларга җавап, биремнәр эшләү, нәтиҗә. | | |
| | Балаларны бәхетнең кадерен белеп яшәргә өйрәтү. | Сәнгатьле уку, төп фикерне аерып чыгара белү, сүзлек өстендә эш, биремнәр эшләү, сораулар буенча анализлау, нәтиҗәләр ясау. | | |
| | Музыка әсәрләре аша туган илгә, туган җиргә мәхәббәт һәм ихтирам уяту. | Галия Кайбицкаяның тормыш юлы, иҗатын өйрәнү, хронологик таблица, сораулар төзү, опера тыңлау, биремнәрне эшләү, нәтиҗәләр ясау. | | |

| | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|
| 60 — 61 | Сәхнә хуҗасы. | 2 | Рабит Батулла иҗаты. «Бию» өзеге. («Бию җене кагылган егет» кыйссасыннан). | Бию сәнгате аша эстетик тәрбия бирү. | Рабит Батулланың тормышы һәм иҗаты турында белешмә бирү, «Бию җене кагылган егет» кыйссасыннан өзекне уку. | |
| 62 | Иҗат — ул яшәү рәвеше. | 1 | Иҗат процессы бүлеген гомумиләштереп кабатлау. | Укыганны гомумиләштерә, нәтиҗә ясый, иң мөһим мәгълүматны аерып ала белү. | Укучыларда иҗатка омтылыш тәрбияләү | |
| **Табигатьнең дә җаны, рухы бар** | | | | | | |
| 63 | Батыр җайдак. | 1 | Айдар Хәлим иҗаты. «Өч аяклы ат» повесте. | Тарихка, халкыбыз язмышына хөрмәт хисләре тәрбияләү. | Айдар Хәлим тормышын һәм иҗатын, «Өч аяклы ат» повестенең төп фикерен ачыклый һәм аңлата белергә өйрәнү. | |
| 64 | Фронттан кайткан ат. | 1 | Айдар Хәлимнең «Өч аяклы ат» повесте. | «Шәҗәрә» төшенчәсенә аңлатма бирү. Шәҗәрәне белү зарурилыгының сәбәпләрен ачыклау. | Айдар Хәлимнең «Өч аяклы ат» әсәрен өйрәнү. | |
| 65 | Авырлык җебе өзелде. | 1 | Айдар Хәлимнең «Өч аяклы ат» повесте. | Укыганны гомумиләштерә, нәтиҗә ясый, иң мөһим мәгълүматны аерып ала белү. | Айдар Хәлимнең «Өч аяклы ат» әсәрен өйрәнүне дәвам итү. | |

| | | | | |
|---|---|---|---|---|
| | Сәхнә кешесенә ихтирам тәрбияләү. | Язучы иҗатына күзәтү, эчтәлек белән танышу, әсәрнең төп фикерен аңлату, биремнәр эшләү, диалогларга бүлеп уку, Интернет челтәреннән Рудольф Нуриев башкарусында бию карау, образга характеристика, анализ, нәтиҗә ясау. | | |
| | Укучыларда иҗат процессына, хезмәткә мәхәббәт, үз эшең белән горурлану хисләрен үстерү. | Бәйләнешле сөләм үстерү, проектлар яклау, үз фикереңне әйтә, нәтиҗә ясый белү, тест. | Тест | |
| | | | | |
| | Укучыларда кешелеклелек сыйфатлары, җаваплылык хисе тәрбияләү. Туганлык мөнәсәбәтләренең нык булырга тиешлеген күзаллау. | Язучының тормыш юлы, иҗаты белән танышу, презентация карау, хронологик таблица тутыру, беренче өлешне уку, образлар белән танышу, сүзлек өстендә эш, сорауларга җавап бирү, биремнәрне эшләү, «Өч аяклы ат» повесте буенча фильмнан өзек карау. | | |
| | Хайваннарга карата мәхәббәт, миһербанлылык хисләре тәрбияләү. | Икенче һәм өченче бүлекләрне уку, план төзү, диа-логны рольләргә бүлеп уку, тәрҗемә эше, образга характеристика, сорауларга җавап, биремнәрне эшләү, малайның нәселләре өчен горурлануын өзектән табып уку, нәтиҗә ясау. | | |
| | Хайваннарны яратырга өйрәтү. | Дүртенче өлешне уку, исем кую, тәрҗемә эше, Галимҗан Ибраһимовның «Алмачуар» хикәясе белән чагыштыру, диалогны рольләргә бүлеп уку, сорауларга җавап бирү, вакыйганы аерып чыгара белү, эчтәлеген сөйләү, биремнәр өстендә эш, нәтиҗә ясау. | | |

| | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|
| 66—67 | Табигатьнең чәчәк аткан чагы. | 2 | Гарәфи Хәсәнов иҗаты, «Беренче күк күкрәү» хикәясе. | Табигатьнең үзенчәлеклелеге, уникальлелеге турында яңа фикерләр тудыру. | Гарәфи Хәсәновның тормыш юлы, иҗаты турында белем бирү, «Беренче күк күкрәү» хикәясен уку һәм нәтиҗә ясау. | |
| 68 | Ямьле сабан туйлары. | 1 | Камил Каримов иҗаты, «Тимергали бабай хикәяте». | Халкыбыз бәйрәмнәре аша эстетик тәрбия бирү. | Камил Кәримовның тормышын, иҗатын һәм «Тимергали бабай хикәяте»н өйрәнү. | |
| 69 | «Ялкын» журналына сәяхәт. | 1 | «Ялкын» журналы. «Табигатьнең дә җаны, рухы бар» бүлеген гомумиләштереп кабатлау. | Укыганны гомумиләштерә, нәтиҗә ясый, иң мөһим мәгълүматны аерып ала белү. | «Ялкын» журналы белән танышу. | |
| 70 | Күңелемә уелып калган әсәрләр<br><br>«Әдәбият» дигән олы диңгез... | 1 | Ел буена үтелгәннәрне гомумиләштереп кабатлау. | Өйрәнгән теоретик төшенчәләрне кабатлау, истә калдыру. | Ел буе өйрәнгәннәрне гомумиләштереп кабатлау. | |

| | | | | |
|---|---|---|---|---|
| | Әйләнә-тирә мохиткә хөрмәт хисе булдыру, табигатьне яратырга өйрәтү. | Язучының тормыш юлы, иҗаты белән танышу, презентация карау, хронологик таблица тутыру; хикәяне уку, төп эчтәлекне аңлау, фикер алышу, парлап сөйләшү, төп геройны сурәтләү, план төзү, план буенча сөйләү. | | |
| | Тарихи үткәнебезгә ихтирам, туган җиргә, хезмәткә мәхәббәт тәрбияләү. | Презентация ярдәмендә язучы тормышы белән танышу, төркемнәрдә фикер алышу, ишетеп аңлау, сүзлекчә белән эш, укыганны тәрҗемә итү, сораулар, биремнәр үтәү, хронологик таблица тутыру, план төзү. | | |
| | «Ялкын» журналына, белем алуга омтылыш тәрбияләү. | Бәйләнешле сөйләм үстерү, проект эшен яклап, төркемнәрнең чыгыш ясавы. | Проект | |
| | Әдәбиятның тәрбия бирү, тормышка әзерләү дәресе булуын аңлату. | Портретлар, төрле иллюстрацияләр, презентацияләр белән укылган әсәрләрне кабатлау, тестлар, гомумиләштерү, сорауларга җавап бирү. | Тест | |

## ДӘРЕС ЭШКӘРТМӘЛӘРЕ

### 1 нче дәрес

**Тема:** Ачыла тарихның пәрдәсе.

**Планлаштырылган нәтиҗәләр:**

М е т а п р е д м е т — укучыларга халкыбыз тарихы турында белем бирү.

П р е д м е т — халык авыз иҗаты турындагы белемнәрне гомумиләштерү, риваять турында белешмә бирү, татар халкының «Сихерче кыз» риваяте белән танышу.

Ш ә х е с к ә к а г ы л ы ш л ы — балаларда татар халык риваятьләренә, башка халык риваятьләренә, халыкларның үткәненә кызыксыну тәрбияләү.

**Материал:** дәреслек (1 нче кисәк, 9—12 нче битләр).

**Җиһазлау:** мультимедиа проекторы, экран (такта), слайдлар, «Татар халык риваятьләре» китабы.

### Дәрес барышы:

**I. Мотивлаштыру-ориентлаштыру**

***1. Дәресне оештыру***

1. Дәресне башлау. Укучыларның хәлләрен сорашу. Уңай психологик халәт тудыру.

2. Укучыларның дәрескә әзерлеген тикшерү.

***2. Актуальләштерү***

1) Җәйге яллар турында фикер алышу. Җәй айларында укыган китаплар турында әңгәмә кору.

2) Әдәбият дәреслеге белән танышу.

3) Юнәлдерүче сораулар биреп, укучыларның халык авыз иҗаты турында алган белемнәрен искә төшерү:

— Нәрсә ул халык авыз иҗаты? Халык авыз иҗаты әсәрләренә нәрсәләр керә? Алдагы сыйныфларда нинди халык авыз иҗаты әсәрләрен өйрәндек? Ул әсәрләр ничек барлыкка килгән, һәм безнең көннәргә аларны кемнәр китереп җиткергән?

***3. Уку мәсьәләсен кую***

Дәрестә халык авыз иҗатының нәрсә икәнен искә төшерергә кирәк. Укытучы дәрестә фольклорның риваять жанры белән танышачакларын әйтә.

**II. Уку мәсьәләсен өлешләп чишү**

1. Халык авыз иҗаты жанрлары турында алдагы сыйныфларда алган белемнәрне ныгыту, үстерү:

1) барлык жанрларны искә төшереп, атап чыгу, русчага тәрҗемә итү;

2) 7 нче сыйныфта өйрәнгән йола, бәетләргә мисаллар китерү.

2. Дәреслектән халык авыз иҗаты, фольклорның риваять жанры турындагы теоретик төшенчә белән, аның төрләре белән танышу, төп үзенчәлекләренә игътибар итү.

Укытучы халык авыз иҗаты, аеруча риваятьләрне өйрәнүче галимнәр турында мәгълүмат бирә.

3. Дәреслектәге сорауларга (10 нчы бит) җавап бирү. Укучылар схема буенча риваятьләрнең төрләре турында сөйлиләр, үзләре укыган риваятьләрдән мисаллар китерәләр.

4. Татар халкының «Сихерче кыз» риваятен уку:

1) сүзлек эше;

2) «Сихерче кыз» риваяте текстын чылбыр буенча уку;

3) риваятьне тәрҗемә итү;

4) дәреслектәге сорауларга (12 нче бит) җавап бирү.

5. Әкият белән риваять арасындагы уртак якларны әйтү.

6. Укучылар «Сихерче кыз» риваяте текстыннан әкияткә хас алымнарны эзлиләр, шул урыннарны кычкырып укыйлар.

**III. Рефлексив бәяләү**

1. Дәрестә алган белемнәрне тикшерү максатында, укучыларга бирем тәкъдим ителә: риваять жанрының төрләрен искә төшереп, «Сихерче кыз» риваятенең төрен билгеләү, дәлилләү.

2. Дәрескә гомуми бәя. Һәр укучының үз эшчәнлеген бәяләве.

— Дәрескә нинди уку мәсьәләсе куйган идек? Максатка ирештекме?

3. Өй эше:

а) «Сихерче кыз» риваятен сәнгатьле укырга;

ә) дәреслекнең 12 — 17 нче битләрендәге риваятьләр белән танышырга;

б) Казанның барлыкка килүе турындагы үзләре белгән яки өстәмә укуга бирелгән бер кыска риваятьне сөйләргә әзерләнергә.

4. Алдагы дәрескә проблема кую:

— Икенче дәрескә нинди эшләр планлаштырырбыз? Бу теманы дәвам итеп, тагын ниләр өйрәнербез?

### Укытучы өчен өстәмә материал

**Риваять** — халык фольклорына карый торган прозаик һәм эпик характердагы жанр. Риваятьләр — реаль тарихи шәхесләргә һәм тор-

мышта чыннан да булган хәлләргә барып тоташучы, борынгы заман истәлекләрен саклаучы хикәятләр.

Әлеге жанр үзләре күргән, белгән, шаһит булган вакыйгаларда үзләре катнашкан кешеләр сөйләве җирлегендә барлыкка килгән. Риваятьләр телдән-телгә күчкәндә, гомумиләштерүгә, сәнгатьчә эшкәртүгә дучар булганнар.

Риваятьләр кыйммәтле чыганак булып исәпләнә, чөнки алар гасырлар тирәнлегеннән килә торган мәгълүмат белән сугарылган. Аларның төп вазифасы — борынгы мөһим вакыйгалар һәм шәхесләр турында халыкның хәтерен — истәлекләрен саклау һәм алдагы буыннарга җиткерү, аларга тарихи-эстетик бәя бирү. Риваятьләрне тел-авыз иҗаты рәвешендә сакланып калган халык елъязмасы дип тә атыйлар.

Вакыт узу белән, риваять телдән-телгә күчеп үзгәрә, соңрак хәтта бөтенләй онытылырга да мөмкин. Аларның халык хәтерендә саклану чорын тикшеренүчеләр 200 — 500 ел белән чиклиләр.

**Риваятьләрне җыючы, өйрәнүче, тикшерүче галимнәр.** Борынгы риваятьләр һәм легендаларны җыеп бастыручы һәм үзенең тарихи этнографик хезмәтләрендә файдаланучы галимнәрнең берсе — Каюм Насыйри. Соңрак риваятьләр Марсель Бакиров, Сәлим Гыйләҗетдинов һ.б. галимнәр тарафыннан өйрәнелә. Татар халкының бай иҗади мирасында үзенчәлекле урын алып торган риваятьләр, легендалар һәм мифологик хикәятләрне өйрәнеп, бергә туплап чыгару өчен күп көч куйган галим Сәлим Гыйләҗетдиновның 1987 нче елда «Татар халык риваятьләре һәм легендалары» китабы дөнья күрә.

## 2 нче дәрес

**Тема:** Сезгә — ялган, миңа — чын.

**Планлаштырылган нәтиҗәләр:**

М е т а п р е д м е т — укучыларга халкыбызның тарихы турында белем бирү.

П р е д м е т — риваять турында алган белемнәрне ныгыту, татар халык риваятьләре белән танышуны дәвам итү.

Ш ә х е с к ә к а г ы л ы ш л ы — балаларда татар халык һәм башка халык риваятьләренә, халыкларның үткәненә кызыксыну тәрбияләү.

**Материал:** дәреслек (1 нче кисәк, 18—21 нче битләр).

**Җиһазлау:** мультимедиа проекторы, экран (такта), слайдлар, «Татар халык риваятьләре» китабы.

### Дәрес барышы:

**I. Мотивлаштыру-ориентлаштыру**

***1. Дәресне оештыру***

Дәресне башлау. Уңай психологик халәт тудыру.

***2. Актуальләштерү***

Юнәлдерүче сораулар биреп, риваятькә билгеләмә бирү.

— Риваятьләр ничек барлыкка килгән?

— Риваятьләр нинди төркемнәргә бүленә?

***3. Уку мәсьәләсен кую***

Укытучы бүген дәрестә риваять жанрын өйрәнүне дәвам итәчәкләрен һәм татар халкының риваятьләре белән танышачакларын әйтә.

**II. Уку мәсьәләсен өлешләп чишү**

1. Сүзлек белән эш.

2. «Гали тугае» риваяте белән танышу.

1) Текстны чылбыр буенча уку.

2) Әсәрне өлешләргә бүлү. Һәрберсенә исем бирү.

3) Укытучы сораулар бирә:

— Гали тугае турында нәрсәләр белдегез? Сөйләгез.

— Гали кем ул? (Образга характеристика бирү.)

— Ни өчен Гали башка көрәшмәскә ант итә?

— Гали үзе башлаган изге эшне ахырына җиткерә аламы?

— Сез ничек уйлыйсыз: ялгышлык, хәйлә белән җиңелгән Гали дөрес юл сайлаганмы? Ни өчен?

— Әсәрнең исеме нәрсә белән бәйле?

3. Сабантуй бәйрәмен искә төшерү.

— Анда нинди уеннар уйнала?

4. Урта гасыр Европа халкының «Моргана» риваяте белән танышу:

1) текстны чылбыр буенча уку;

2) әсәрне өлешләргә бүлү;

3) 20—21 нче биттәге сорауларга җавап;

4) дәреслектән 4 нче биремне үтәү;

5) укучылар риваятьне рус теленә тәрҗемә итеп сөйлиләр.

3. Топонимик риваятьләргә билгеләмә бирү.

4. Проект эшенә әзерләнү:

— Шәһәр, авыл, тау һәм елга атамаларын искә төшерү;

— Укучыларны проект эшләү тәртибе белән таныштыру, алдагы сыйныфта өйрәнгәннәрен искә төшерү.

**Атамалар турында проект эше башкаруның тәртибе:**

1. Шәһәр, авыл, тау һәм елга атамаларын барлау.

2. Әлеге атамаларның килеп чыгышы, тарихы турында мәгълүмат җыю.

3. Проектның 1 нче, 2 нче ... битләрендә нәрсә турында сөйләргә була?

4. Бергәләп текст төзү.

5. Материалны дәреслектән, башка китаплардан һәм Интернеттан эзләү.

6. Дәрестә чыгыш ясарга әзерләнү.

7. Башка төркемнәрне игътибар белән тыңлау, сораулар бирү.

**III. Рефлексив бәяләү**

1. Укучыларга риваять жанрын гомумиләштерү буенча сораулар бирелә:

— Сез укыган риваятьләрдә нәрсәләр турында сөйләнелә? Алар риваятьнең кайсы төренә карый?

— Укыган текстлардан риваятькә хас үзенчәлекләрне табыгыз.

2. Бәяләү. Укучыларга дәрестәге активлыклары өчен билгеләр куела.

3. Өй эше: а) дәреслектәге текстларны сәнгатьле укырга өйрәнергә;

ә) риваятьләрнең төрләрен белергә, дәреслектәге риваятьләрне төркемнәргә аерып язарга;

б) Шәһәр, авыл, тау һәм елга атамаларының килеп чыгышы турында проект эше әзерләргә.

## 3 нче дәрес

## Проект-дәрес

**Тема:** Халыкныкы халыкта саклана.

**Планлаштырылган нәтиҗәләр:**

Метапредмет — укучыларга халкыбызның тарихы турында белем бирү, шәһәр, авыл, елга исемнәренең килеп чыгышын белү.

Предмет — риваять турында алган белемнәрне ныгыту.

Ш ә х е с к ә  к а г ы л ы ш л ы — балаларда татар халык риваятьләренә, атамаларның килеп чыгышына кызыксыну тәрбияләү, дөрес бәяләү күнекмәләре булдыру.

**Материал:** дәреслек (1 нче кисәк, 9—10, 18 нче битләр), «Татар энциклопедия сүзлеге», төрле шәһәр, авыл, елга атамаларының килеп чыгышы турындагы китаплар, Интернет челтәреннән алынган материаллар.

**Җиһазлау:** мультимедиа проекторы, экран (такта), слайдлар, «Татар халык риваятьләре» китабы.

3 төркемгә бүленеп әзерләгән укучылар дәрестә проектларын тәкъдим итәләр. I төркем үзләре сайлаган шәһәр исемнәре, II төркем — авыл исемнәре, III төркем елга, диңгез исемнәренең килеп чыгышы (ономастикасы) турында сөйли. Куелган бурыч, максатларга ирешү-ирешмәүне ачыклап, эшләрне бәяләү. Уңышлы проект эше дип билгеләнгәннәрен, кызыклы дип табылган мәгълүматларны тагын да үстереп, һәртөрле конкурсларда катнашу максаты кую.

## 4 нче дәрес

**Тема:** Сезгә — ялган, миңа — чын.

**Планлаштырылган нәтиҗәләр:**

М е т а п р е д м е т — укучыларга халкыбызның тарихы турында белем бирү.

П р е д м е т — татар халык авыз иҗаты жанрлары белән танышуны дәвам итү, легенда жанрын өйрәнү, «Зөһрә кыз» легендасын уку.

Ш ә х е с к ә  к а г ы л ы ш л ы — балаларда татар халык легендаларына, башка халык легендаларына, халыкларның үткәненә кызыксыну тәрбияләү.

**Материал:** дәреслек (1 нче кисәк, 21—22, 24—25 нче битләр).

**Җиһазлау:** мультимедиа проекторы, экран (такта), слайдлар, «Татар халык легендалары» китабы.

### Д ә р е с  б а р ы ш ы:

**I. Мотивлаштыру-ориентлаштыру**

***1. Дәресне оештыру***

Дәресне башлау. Уңай психологик халәт тудыру.

***2. Актуальләштерү***

1) Юнәлдерүче сораулар биреп, риваятькә билгеләмә бирү.

— Риваятьләр ничек барлыкка килгән?

— Риваятьләр нинди төркемнәргә бүленә?

2) Алда алган белемнәрен, рус әдәбиятын искә төшереп, риваять жанры белән янәшә йөри торган халык авыз иҗаты әсәрләренең тагын бер жанрын атау.

***3. Уку мәсьәләсен кую***

Укытучы бүген дәрестә халык авыз иҗатының легенда жанры һәм аның үрнәкләре белән танышачакларын әйтә.

**II. Уку мәсьәләсен өлешләп чишү**

1. Дәреслектән халык авыз иҗаты фольклорның легенда жанры турындагы теоретик төшенчә, аның төрләре белән танышу, төп үзенчәлекләренә игътибар итү.

2. Укытучы легенданы өйрәнүче галимнәр турында мәгълүмат бирә.

3. Дәреслектәге (22 нче бит) сорауларга җавап бирү.

4. Легенда белән риваятьләр арасында аермалы якларны билгеләү.

5. Укучыларга түбәндәге таблица тәкъдим ителә.

**Риваять һәм легенданың аермалы яклары**

| Риваять | Легенда |
|---|---|
| — реаль тарихи шәхесләргә һәм тормышта чыннан да булган хәлләргә барып тоташа | — могҗизалылыкка, фантастик күзаллауга нигезләнә;<br>— әкияти алымнарга бай |

6. Татар халкының «Зөһрә кыз» легендасы белән танышу:

1) сүзлек белән эш;

2) текстны чылбыр буенча уку;

3) әсәрне өлешләргә бүлү;

4) сорау — җавап формасында әсәргә анализ ясау (25 нче биттәге сорауларга җавап бирү).

7. Укучылар легенданы рус теленә тәрҗемә итеп сөйлиләр, легенданың төрен билгелиләр.

8. Әкият һәм легендаларның уртак якларын билгеләү.

9. Фатих Әмирханның «Ай өстендә Зөһрә кыз» әсәрен искә төшереп, «Зөһрә кыз» легендасы белән уртак якларны табу.

**III. Рефлексив бәяләү**

1. Рефлексив кабатлау.

Укучыларга бүгенге дәрестә нинди яңа белемнәр алулары турында сораулар бирелә:

— Легенда нәрсә ул? Легенданың риваятьтән аермалы ягын атагыз.

— «Зөһрә кыз» легендасы нәрсә турында?

Укучылар легендага билгеләмә бирергә, аның классификациясен белергә, легенданың төп үзенчәлекләрен билгеләп, риваятьләрдән аера белергә тиеш.

— Дәрескә куелган уку мәсьәләсе чишелдеме?

— Сез нәрсәләр белдегез?

2. Бәяләү. Укучыларга, дәрестә катнашканнары бәяләнеп, дөрес җаваплар бирүләре истә тотылып, билгеләр куела.

3. Өй эше: а) «Зөһрә кыз» легендасы текстын сөйләргә өйрәнергә;

ә) легендаларның төрләрен белергә;

б) риваять һәм легендаларның аермалы якларын күрсәтә белергә.

## 5 нче дәрес

**Тема:** Моңы барның йөрәгеннән
Һәрвакыт җылы чыгар. *(М.Әгъләмов)*

**Планлаштырылган нәтиҗәләр:**

Метапредмет — эстетик тәрбия бирү.

Предмет — халык авыз иҗаты турындагы белемнәрне гомумиләштерү, халык музыка уен кораллары турында белешмә бирү, танышу, проект эшен яклау.

Шәхескә кагылышлы — балаларда татар халык музыка уен коралларына, халыкларның үткәненә кызыксыну тәрбияләү.

**Материал:** дәреслек (1 нче кисәк, 33—36 нчы битләр).

**Җиһазлау:** мультимедиа проекторы, экран (такта), слайдлар, татар халык музыка уен коралларының рәсемнәре.

### Дәрес барышы:

**I. Мотивлаштыру-ориентлаштыру**

***1. Дәресне оештыру***

1) Дәресне башлау. Укучыларның хәлләрен сорашу. Уңай

психологик халәт тудыру.

2) Укучыларның дәрескә әзерлеген тикшерү.

***2. Актуальләштерү***

Өй эшен тикшерү: укучылар өстәмә уку өчен бирелгән әсәрләрдән үзләренә ошаган өзекләрнең кыскача эчтәлеген сөйлиләр.

***3. Уку мәсьәләсен кую***

Табышмаклар чишү һәм дәреснең темасын ачыклау.

(Экранда — слайд, музыка кораллары турында табышмаклар.)

* Кечкенә генә өй,
Эче тулы көй. (Радиоалгыч)

* Сары сандык сатып алдым, —
Үзе нәни генә,
Төрле тавышка җырлый белә. (Скрипка)

* Телләре бик күп булса да,
Һәркем аңлый, үз итә.
Елата да, җырлата да,
Кирәк икән — биетә. (Гармун)

* Эче буп-буш,
Тавышы дөньяга сыймый. (Барабан)

* Тартма өстендә — таяк,
Таякта — җиде җеп,
Җиде җептә — җитмеш сайрар кош. (Гитара)

* Үзе кыллы, үзе телле,
Идәндә басып тора.
Уйнарга теләгән кеше
Иң беренче — утыра. (Пианино)

— Димәк, дәрестә сүз нәрсә турында барачак? (Музыка турында.)

Бүгенге дәрестә музыка уен кораллары белән танышу турында әйтелә.

**II. Уку мәсьәләсен өлешләп чишү**

1. «Моңлы курай» шигыре белән танышу:

1) сүзлек белән эш;

2) шигырьне сәнгатьле уку;

3) сорау-җавап формасында шигырьгә анализ ясау (34 нче биттәге сорауларга җавап бирү).

2. — Сез тагын нинди уен кораллары беләсез?

3. Музыка уен коралларының тарихы белән танышу:

1) сүзлек белән эш;

2) укытучы, Интернет челтәре материалларын файдаланып, презентация аша уен кораллары белән таныштыра.

**III. Рефлексив бәяләү**

1. — Дәрескә куелган уку мәсьәләсе чишелдеме? Музыка уен кораллары турында нәрсәләр әйтә аласыз?

2. Дәрескә гомуми бәя. Үзбәя. Укучыларга билге кую.

3. Өй эше: а) «Моңлы курай» шигырен яттан сөйләргә өйрәнергә;

ә) татар халкының музыкаль уен коралları турында сөйләргә өйрәнергә;

б) рәсемнәрдә сурәтләнгән бер уен коралы турында мәгълүмат тупларга һәм проект эше әзерләргә.

**Укытучы өчен өстәмә материал**

**Думбра** — ике яки өч кыллы традицион татар музыка уен коралы, шулай ук казахлар һәм башкортларда да таралыш алган. Озынлыгы 90—110 см. Өчпочмаклы корпусы чыршы яки нарат агачының тоташ кисәген чоку юлы белән ясала. Муены һәм көрәксыман башы өрәңге яисә каен агачыннан эшләнә, муены нык итеп корпуска тоташтырыла. Өске декасы юка чыршы яисә нарат тактадан ясала. Традицион думбра җирлегендә яңа үрнәктәге уен кораллары эшләнә. Думбраның төп төрләре: прима, секунда, альт, тенор, бас. Аларда кварта төзелешле кыллар, хроматик тавыш рәтләре бар.

**Курай** — татар халык тынлы милли музыка коралы. Татарларда курай элек-электән үк киң таралган уен коралы булган. Курайларның тавыш югарылыгы, ягъни музыкаль регистрның көйләнеш югарылыгы, төрле булырга мөмкин, һәм ул курайчының (гадәттә, курайчылар коралларын үзләре ясаган) теләге, аның тавыш көпшәсе үлчәмнәрен (озынлыгын, юанлыгын) нинди итеп сайлаганлыгы белән бәйле. Гадәттә, курайларның озынлыгын тотам белән үлчиләр. Шуннан чыгып, курайлар җиде, сигез, тугыз яисә ун тотам озынлыкта булалар. Курай озынлыгы, төренә карап, төрлечә була — 120—180 мм дан алып, 450—1000 мм га хәтле.

Курай төрләре: классик курай; көпшә курай; агач курай; бакыр курай; казан курай; ногай курай.

Татарстанда һәм татарлар яшәгән башка җирләрдә курай белән кызыксыну көннән-көн арта. Курайда татар халык көйләрен һәм хәзерге заман җырларын да башкарып була.

**Гармун** — төрле конструкцияле һәм көйләнешле телле-клавишлы, пневматик музыка уен коралы, татар халкында киң таралган музыка уен коралларыннан берсе. Чыгышы — Европадан. Беренче конструкциясен 1822 елда немец остасы Бушман эшли. Барлык гармуннарга тартып уйнау принцибы һәм авазлар чыганагының конструктив үзенчәлекләре уртаклыгы хас.

Татарлар арасында бер рәтле рус һәм немец көйләнешле гармуннар, соңыннан төрле конструкцияле ике рәтле рус һәм немец көйләнешле «Саратов гармуны», «бараксин» (Вараксин), «тальян гармун» (вятский), «рус гармуны», «концерт гармуны» була. Аларда халык җырлары, көйләре һ.б. әсәрләр башкарыла.

**Доңгыра** — традицион татар музыка уен коралы, көтүче барабаны. Калынлыгы 25 мм, озынлыгы 400—500 мм, киңлеге 150—200 мм булган коры каен яисә чыршы тактасыннан шомартып эшләнгән, киң яңгырашлы уен коралы. Тактаның югары очы — бөтерелгән формада. Тактаның кырыйларына симметрик рәвештә яртылаш бөгелгән ике кадак сугыла, шуның ике очына каеш бәйләнә. Доңгыраны муенга эләләр. Ул — функциональ кулланылышлы уен коралы: башкаручы, талдан эшләнгән махсус таякчыклар белән, ритмик сигналлар шакылдата. Көтүчеләр доңгыраны иртән — хайваннарны көтүлеккә куу, кичен аларны абзарга куып кертеп, ябу өчен куллана.

**Дәф** — чыгышы белән Көнчыгышка бәйле борынгы татар музыкаль уен коралы; берьяклы мембранофон төре — агач кыршау торпышасы (диаметры — 400 мм га кадәр, биеклеге — 70 мм) бозау тиресеннән махсус эшкәртелгән күн белән бер яктан тарттырылган. Торпычаның эчке ягы металл алкалы. Дәфнең кырыенарак яисә уртасына бармак бәрү мөмкинлегенә карап, аның авазы төрле тембрлар ала. «Гаруз» метроритмы системасына нигезләнгән вокаль әсәрләргә уйналган, шулай ук сәяхәт итүче дәрвиш-суфилар тарафыннан Аллаһны олылаган догалар укыган вакытта файдаланылган. Музыкаль тактларда бәет, мөнәҗәтләр башкарганда кулланылган. Г.Кандалый, Т.Ялчыгол әсәрләрендә дәф искә алына. Әлеге уен коралы XIX йөз урталарында куллanudан төшеп кала.

**Быргы** — татар халкының тынлы музыка уен коралы. Иренгә куелып уйнала торган табигый көпшә төренә карый. 0,3—0,6 мм калынлыктагы калайдан, бармаклар өчен тишекләр уелмыйча эшләнгән 500—600 мм озынлыктагы конуссыман көпшәдән гыйбарәт; киң башының диаметры 90—110 мм, тар башыныкы 12—14 мм. Тар башына агачтан ясалган кәтүксыман мөштек киертелә. Авазлар мөштекне кыскан ирен кырыйларының калтырануы нәтиҗәсендә хасил була. Быргы тавышының югарылыгы иреннәрнең киеренкелегенә һәм өрелгән һаваның көченә бәйле. Быргының тавышы — көчле, тембры — яңгыравыклы, кискен.

**Дөмбери** — шөлдерле барабан, традицион татар бәрмә музыка уен коралы. Кыршау бер яктан күн белән тышлана. Кыршау тишекләренә кечкенә оркестр тәлинкәләре формасындагы металл пластинкалар беркетелә. Кыршау эчендә тартылган берничә бауга кечкенә шөлдерләр эленә. Ансамбль белән уйнау тәҗрибәсендә, дөмбери кызу темптагы җырлар һәм бию көйләрен башкарганда көйнең ритмын бизәү өчен кулланыла.

## 6 нчы дәрес

**Тема:** Тарих — тормыш остазы.

**Планлаштырылган нәтиҗәләр:**

М е т а п р е д м е т — әдәбиятта сәяхәтнамәләр һәм елъязмалар жанры турында теоретик төшенчә формалаштыру.

П р е д м е т — гарәп сәяхәтчесе Ибне Фадлан турында белешмә бирү. Ибне Фадланның 921 — 922 нче елларда Болгар дәүләтенә сәфәре вакытында язылган сәяхәтнамәсен өйрәнү.

Ш ә х е с к ә к а г ы л ы ш л ы — мәдәниятебезгә, тарихыбызга карата горурлык хисе тәрбияләү.

**Материал:** дәреслек (1 нче кисәк, 38—42 нче битләр).

**Җиһазлау:** Лотфулла Фәттахов һ.б. рәссамнарыбызның Ибне Фадланга багышлап ясаган картиналары, мультимедиа проекторы, слайдлар, Әнвәр Хәйринең рус телендә чыккан «Повествование о путешествии Ахмеда Ибне Фадлана, написанное во время поездки в 921 — 922 годах в Булгарское государство» китабы.

**Эпиграф:**

...Тарих фәне — барлык милләт һәм кабиләләрнең хәлләрен эченә ала, гыйльми тармакларны һәм фәнни бәхәсләрне тикшерә. Гади халык һәм белмәүчеләр аны белергә тели...

*Шиһабетдин Мәрҗани*

### Д ә р е с б а р ы ш ы:

**I. Мотивлаштыру-ориентлаштыру**

***1. Дәресне оештыру***

Дәресне башлау. Психологик уңай халәт тудыру.

***2. Актуальләштерү***

1) Алдагы дәреснең өй эшен тикшерү.

2) Һәр дәрестә, яңа бүлекне укый башлаганчы, алда үтелгән темалар эчтәлеге буенча әңгәмә.

3) Укучыларның Татарстан тарихыннан Болгар дәүләте турында белгәннәрен искә төшерү, фикер алышу.

Тарихыбызның никадәр бай, тирән булуы һәркемне горурлык хисе белән яшәтә һәм яшәтәчәк, чөнки безнең халкыбыз тарихы аеруча гыйбрәтле. Борынгы бабаларыбыз элек-электән үз дәүләтенә, шәһәрләргә, дингә — иманга, югары үскән рухи мәдәнияткә ия булган.

— Болгар дәүләте ничәнче гасырда оешкан?

— Болгар илендә нинди тармаклар үсеш алган?

— Һичшиксез, сәүдәдән башка, Болгар илендә икътисадның башка тармаклары да — игенчелек һәм һөнәрчелек тә — шактый үсешкә ирешкән булган. Болгар дәүләте ашлык, икмәк белән үз халкын гына туйдырып калмаган, артканын читкә дә чыгарган, хәтта берничә тапкыр корылыкка, ачлыкка дучар булган Рус дәүләтен дә зур бәладән коткарган.

Һөнәрчелекнең төзелеш-архитектура, зәркән (ювелир) сәнгате, үзле балчыктан гади һәм бизәкле савыт-саба ясау, җиз, бакыр, сөяк, пыяла эшкәртү, тимердән корал эшләү төрләре киң таралган булган. Зәркән сәнгате, ягъни алтын-көмештән эшләнгән беләзекләр-йөзекләр, алкалар һәм балдаклар, муенса-күкрәкчәләр, мәгъдән көзгеләр үзләренең камил булулары белән аерылып торганнар. Алар алтын-көмеш йөгертү, бөртекләү, каралту, асылташлар беркетү, металлны чокып сурәт төшерү ысуллары кулланып ясалганнар.

Болгар чорыннан калган бизәнү әйберләре, ә алар безгә төрле бай хәзинәләр булып та килеп җиткәннәр, археологик казулар вакытында да табылып торалар, Урта гасырларның ювелир сәнгате калыпларына туры киләләр, матди культураның зур байлыгы, горурлыгы булып саналалар. Корал эшләү осталыгы, гомумән, хәрби эш, кальгалар һәм ныгытмалар төзү техникасы хакында да шундый ук сүзләрне әйтеп булыр иде.

— Болгар илендә мәктәп-мәдрәсәләр булганмы?

— Матди культураның югарылыгы рухи мәдәниятнең дә үсешенә ярдәм иткән. Болгар илендә мәктәп-мәдрәсәләрнең булганлыгы, аерым укымышлыларның төрле фәннәр, әйтик, тарих, хокук, фәлсәфә гыйлемнәре белән шөгыльләнгәнлекләре хакында инде күп язылды.

***3. Уку мәсьәләсен кую***

1) Укытучы бүген дәрестә гарәп сәяхәтчесе Ибне Фадлан турында һәм аның 921 — 922 нче елларда Болгар дәүләтенә

сәфәре вакытында язылган сәяхәтнамәсеннән өзек укыячакларын әйтә.

2) Болгар дәүләтенең ил тарихындагы ролен ассызыклау.

3) Әдәбиятта сәяхәтнамәләр һәм елъязмалар жанры турында теоретик төшенчә формалаштыру.

**II. Уку мәсьәләсен өлешләп чишү**

1. Автор белән танышу:

1) укытучы, язучының китабын күрсәтеп, аның тормышы һәм иҗаты белән таныштыра;

2) бер укучы дәреслектән Ибне Фадлан турындагы белешмәне укый;

3) укытучы, сораулар ярдәмендә, укучыларның аңлавын тикшерә. Биографик белешмәгә нигезләнеп, сораулар бирелә. Укучылар үзләре дә сораулар төзиләр.

2. Сүзлек белән эш:

1) Укытучы сүзләрне укый, укучылар аның артыннан кабатлыйлар. Авыр сүзләрне аерым укучылардан кабатлаттыра.

2) Укытучы русчасын әйтә, укучылар тәрҗемәсен әйтәләр.

3) Укучылар чылбыр буенча яңа сүзләр белән сүзтезмәләр яки җөмләләр төзеп әйтәләр.

3. Әдәбиятта сәяхәтнамәләр һәм елъязмалар жанры турында теоретик төшенчә аңлатыла. Башка әсәрләрдән мисаллар китерелә. Укучылар кагыйдәнең русчасын укыйлар. Рус әдәбиятыннан мисаллар китерәләр. Сораулар һәм биремнәргә җавап бирү.

4. Ибне Фадланның 921 — 922 нче елларда Болгар дәүләтенә сәфәре вакытында язылган сәяхәтнамәсен чылбыр буенча уку.

1) Укытучы сораулар бирә:

— Әсәр нинди жанрда язылган?

— Хикәяләүче кайсы дәүләткә сәяхәт кыла?

— Бу дәүләт белән кайсы хан идарә итә?

— Ибне Фадлан сәяхәтнамәсендә кемнәр турында мәгълүматлар бар?

— Ибне Фадлан болгарларның нинди сыйфатларын тасвирлый?

— Патша кунакларны ничек каршы ала? Тексттан табып укыгыз.

2) Лотфулла Фәттахов рәсеме белән эш.

— Хикәяләүче хан каршында нәрсә укый?

— Болгар илен зур үсешкә китергән ханның исеме ничек?

3) Алмыш хан турында мәгълүмат китаптан укыла. Дәреслектән 2—3 нче биремнәр эшләнелә. Укучылар биремнәрне үзләре укыйлар, авыр булса, тәрҗемә итәргә мөмкиннәр.

### III. Рефлексив бәяләү

1. Укучылар дәреслектәге 4 нче биремне эшлиләр. Бу бирем эшләнгәндә, әсәрнең эчтәлеге тулысынча яңадан кабатланырга тиеш.

2. Бәяләү. Укучыларга, дәрестә катнашканнары бәяләнеп, билгеләр куела.

3. Өй эше:

а) сәяхәтнамәне сәнгатьле итеп укырга өйрәнергә;

ә) сүзлекчәдәге сүзләрнең татарчага тәрҗемәләрен яттан белергә;

б) Болгар иле, Алмыш хан, Ибне Фадлан һәм аның сәяхәтнамәсенә таянып, диалог төзү.

4. Алдагы дәрескә проблема кую.

Укытучы, дәресне тәмамлаганчы, йомгаклап, нәтиҗә ясар өчен сораулар бирә:

—Ибне Фадлан тарихи яктан бик мөһим нинди эш башкара?

**Укытучы өчен өстәмә материал**

Болгар патшалары Багдад хәлифәте белән элемтәгә кергәннәр. 922 нче елда Урта Иделгә хәлиф илчеләре килгән. Ул тарихта «Ибне Фадлан илчелеге» исеме белән мәгълүм. Болгар патшасы Алмыш үз дәүләтенең хәлифәткә дин ягыннан буйсынуын таныган, ә гарәп дине — ислам болгарларның дәүләт дине булып киткән.

Алтын Урда кулы астында Болгар иле политик һәм экономик мөстәкыйльлеген беркадәр саклап кала алган. Идел шәһәрләре яңадан торгызылган XIV гасырда илдә һөнәрчелек, авыл хуҗалыгы һәм сәүдәнең алга китүе күзәтелгән. Яңадан башкалага әйләнгән Шәһре Болгарны рус елъязмалары «Бөек шәһәр», «Бөек Болгар» дип атаганнар.

Гарәп авторларының Көнчыгыш Европа турындагы язмалары бик әһәмиятле тарихи чыганаклар булып тора. Ибне Фадлан, Ибне Даста истәлекләренә мөрәҗәгать ителә. Алар бу төбәктә яшәгән халыкларның җир эшкәртү белән шөгыльләнүләренә игътибар иткәннәр. Бу фактлар археологик табылдыклар белән дә раслана. XIII — XIV гасырларга караган ашлык саклый торган чокырларда археологлар тарафыннан күптөрле иген культуралары табыла: бодай, арыш, арпа, тары, солы, борчак, ясмык, борай. Болгарлар тарафыннан бигрәк тә бодай һәм борай яратып игелгән.

Тарихтан күренгәнчә, 922 нче елда Гыйрак илчесе Әхмәт Ибне Фадлан алтмыш дөя белән Болгарга килә. Шунда ул татар егетләренең бил алышканнарын күреп гаҗәпләнә. Бу хакта язып та калдыра. Аның истәлекләре бүген дә Багдад китапханәсендә саклана. Безнең баба-

ларыбыз яраланмый да, тән җәрәхәте дә алмый торган бәйге уйлап тапканнар. Җиңүчене зурлаганнар.

Ибне Фадлан яза: «...Һәм патшадан бу турыда сорагач (ягъни, кояш баер алдыннан, күк кызарып, болытларның сугышкан ике гаскәр рәвешенә керүе турында), имеш, аның бабалары әйтә торган булганнар, ди: алар — мөэмин һәм кяфер җеннәр, һәр кич шулай сугышалар, бабалары булганнан бирле, һәр кич сугышканнар, юкка чыкмаганнар». Моннан аңлашылганча, болгарларда, Алмыш патшаның ата-бабалары вакытында ук, җеннәр арасында кяферләре һәм мөселманнары булуы билгеле булган. Патшаның андый хикәятләрне үзе уйлап чыгарып утыруы мөмкин түгел. Бу — ислам диненең Болгар җирләренә борынгыдан таралуын раслый. Андый хикәятләрнең халык арасында таралуы өчен дистә еллар гына җитми.

Ибне Фадлан яза: «Мин һәм патшаның Багдад әһелләреннән булган тегүчесе — ул шул якларга барып чыккан — чатырыма кереп сөйләшеп утырдык...» Шулай итеп, Ибне Фадлан килгәнче үк, Болгар җирендә гарәпләр дә яшәгән.

Ибне Фадлан яза: «Аларның барысы да башлыклар кия». Ул бу урында болгарларга хас сыйфатны искә ала. Юлында очраган башка халыклардан аермалы буларак, болгарларның барысының да башлык киеп йөрүләре — борынгыдан ислам дине таралуының тагын бер билгесе.

Ибне Фадлан яза: «Әгәр алардан берәр ир кеше үлсә, аның мирасын ир туганы ала, балалары алмый. Патшага болай ярамаганлыкны аңлаттым. Аңа мирасның ничек бүленүен өйрәттем, хәтта төшенгәнче». Билгеле булганча, әгәр башка варислар риза булсалар, мирас бөтен килеш бер вариска гына бирелергә мөмкин. Безнең халыкларда, ир кеше үлсә, бертуганына аның хатынын никахландырганнар, шулай ук туганының балаларын да ул карарга тиеш булган. Бу очракта, мирастан балаларына тиеш өлеш тә аңа күчә. Болай эшләүдә шәригшы бернәрсә дә юк».

Ибне Фадлан яза: «Алардан барысы да исламны кабул иткән биш мең кешедән торган йорт әһелләрен (ягъни, ыруны) күрдек, «бәрәнҗәр» дип аталалар. Үзләренә агачтан мәчет төзегәннәр, шунда намаз укыйлар. Кыйраәтне (Коръән уку) белмиләр, алардан бер җәмәгатькә намаз укырлык Коръән өйрәттем». Мәчет салып, анда намазлар укый торган халык арасында, әлбәттә, Коръән укый белүче булмый калмас, мәгәр Ибне Фадлан укый белмәүчеләре турында гына искә ала.

Ибне Фадлан Алмышның кызы турында, мөселман булган, дип яза. Алар Болгарга килгәндә, Алмыш инде мөселман булган. Илчелек алдында ул исламны кабул итмәгән, бәлки хәлифәгә буйсынырга вәгъдә биргән.

Бу рәсми экспедиция турында Ибне Фадланның язмалары мөһим тарихи һәм сәяси документ булып тора.

*Рафыйк Миңнәхмәтовтан*

## 7 нче дәрес

**Тема:** Гыйлемсез кеше — канатсыз кош.

**Планлаштырылган нәтиҗәләр:**

Метапредмет — мәдәният учакларына тарихи күзәтү.

Предмет — Фатих Кәриминең тормыш юлы һәм иҗаты турында белешмә бирү, «Аурупа сәяхәтнамәсе» әсәрен уку.

Шәхескә кагылышлы — укучыларда сәнгать җәүһәрләренә, халкыбыз мирасына, белем алуга омтылыш тәрбияләү.

**Материал:** дәреслек (1 нче кисәк, 42—44 нче битләр).

**Җиһазлау:** мультимедиа проекторы, экран, слайдлар: Фатих Кәрими портреты, Петербург музейлары турында презентация.

### Дәрес барышы:

**I. Мотивлаштыру-ориентлаштыру**

***1. Дәресне оештыру***

Дәресне башлау. Психологик уңай халәт тудыру.

***2. Актуальләштерү***

Өй эше укытучы планлаштыруы буенча тикшерелә.

1) Сәяхәтнамә һәм елъязмалар искә төшерелә, уртак һәм аермалы яклары ачыклана.

2) Ибне Фадланның сәяхәтнамәсе турында фикер алышу.

— Ибне Фадлан тарихи яктан нинди мөһим эш башкара?

***3. Уку мәсьәләсен кую***

Бүгенге дәреснең темасы — Фатих Кәриминең «Аурупа сәяхәтнамәсе» әсәреннән өзек уку.

Темадан чыгып, дәрескә уку мәсьәләсен укучылар белән бергәләп кую.

1) Фатих Кәриминең тормышы, иҗаты белән танышу.

2) «Аурупа сәяхәтнамәсе» әсәрен уку, аңлау.

**II. Уку мәсьәләсен өлешләп чишү**

1. — Үткәнен белмәгән халыкның киләчәге юк, диләр. Ә безнең тарихи үткәнебез — бик кадерле мирас. Без аны саклыйбыз, өйрәнәбез. Казаныбыз, чыннан да, бай тарихлы, мәдәниятле шәһәр. Аның танылган шәхесләре, күренекле галимнәре, фән, сәнгать эшлеклеләре бар. Бүген без халкыбызның күренекле шәхесләреннән берсе — Фатих Кәрими, аның иҗаты турында сөйләшербез. Ул җәмгыять тормышының күп тармакларында

уңышлы эшли, яңа әдәбиятыбызны мәйданга чыгаруда катнашып, исеме К.Насыйри, Р.Фәхретдин, Г.Исхакый, Г.Ибраһимовлар белән бер биеклеккә куелырлык дәрәҗәгә ирешә.

1) Презентация, китаплар күргәзмәсе.

2) Дәреслектәге биографик белешмәне уку.

3) Парларда эшләү: шагыйрьнең тормышы һәм иҗаты турында сораулар төзү, җавап бирү.

2. Беренче өлешнең сүзлекчәсе белән эш.

1) Укытучы сүзләрне укый, укучылар аның артыннан кабатлыйлар. Авыр сүзләрне аерым укучылардан кабатлаттыра.

2) Укытучы русчасын әйтә, укучылар тәрҗемәсен әйтәләр.

3) Укучылар чылбыр буенча яңа сүзләр белән сүтезмәләр яки җөмләләр төзеп әйтәләр.

3. Бер укучы дәреслектән Фатих Кәрими турында белешмәне укый.

4. Укытучы, сораулар ярдәмендә, укучыларның аңлавын тикшерә.

— Фатих Кәрими кайда туган? Ул кайларда белем алган?

— Язучы нинди телләрне яхшы белгән?

— Фатих Кәримине сәяхәткә кем иптәш итеп ала?

— Сәяхәткә ни өчен киткән?

— Фатих Кәрими сәяхәт иткән Европа илләрен санагыз.

— «Аурупа сәяхәтнамәсен» ничәнче елда бастырып чыгара?

— Ф.Кәрими сәяхәттә нәрсәләр өйрәнә?

— Сәяхәтнамәне ни өчен яза?

— Кайларда һәм кем булып эшләгән?

5. «Аурупа сәяхәтнамәсе»н тыңлау яки укытучының сәнгатьле укуы.

1) Эчтәлек буенча сорау-җавап.

2) Чылбыр буенча уку, сүзгә-сүз русчага тәрҗемә итү.

— Сәяхәтнамәнең эчтәлеге аңлашыламы?

3) Өзекне ике өлешкә бүлеп уку.

4) Укыган өлешне анализлау.

— Укучылар, без сәяхәтнамәдә сурәтләнгән вакыйгаларны бүгенге көн, ягъни XXI гасыр белән чагыштырып барырбыз. Сорауларга җавап биргәндә шуны күз алдында тотыгыз.

— Без сәяхәтнамәне ике өлешкә бүлеп укыдык. Хәзер төркемнәрдә эшләү өчен биремнәр белән танышыйк.

**1 нче бирем.** Сөйләү.

1 нче төркем — беренче өлешнең эчтәлеген сөйли, исем куя.

2 нче төркем — икенче өлешнең эчтәлеген сөйли, исем куя.

**2 нче бирем.** Сорауларга җавап.

1 нче төркем.

— Фатих Кәрими «Аурупа сәяхәтнамәсе»н нинди жанрда яза? Эрмитаж кем тарафыннан төзелә? Эрмитажда нәрсәләр саклана?

2 нче төркем.

— Фатих Кәрими Петербургның кайсы истәлекле урыннарында була? Фән академиясе музее кайда урнашкан? Ничә бүлектән тора?

**3 нче бирем.** Проект эше.

Укучылар, Интернет челтәренә кереп, үзләре сайлап алган музейлар турында кызыклы мәгълүмат туплап, иптәшләрен таныштыралар.

XIX гасыр азагында музейлар нинди була? XXI гасырда музейларга караш ничек?

Санкт-Петербургтагы Эрмитаж дәүләт музее — Россиядәге сәнгать һәм мәдәни-тарихи музейларның иң зурысы.

Музей үзенең тарихын Екатерина II идарә иткән еллардан башлый. Иң беренче коллекция махсус флигельдә — Кечкенә Эрмитажда урнаштырыла. 1852 нче елда, коллекциянең баюы нәтиҗәсендә, Император Эрмитажы формалаша һәм халык өчен ачыла.

Хәзерге Дәүләт Эрмитажы музей комплексыннан гыйбарәт. Музейның төп экспозицион өлеше Нева елгасы буендагы биш бинаны үз эченә ала.

Бүгенге көнгә музей өч миллионнан артык сәнгать әсәре һәм дөньяви сәнгать һәйкәлләре коллекциясенә ия.

Фәннәр академиясе музее тарихы

Идарәчелек итүнең беренче елларында ук, Пётр I Россиядә Фәннәр академиясен барлыкка китерү турында уйлый башлый. Патша фән үсешеннән башка ил уңышлы үсеш алмасын яхшы аңлый. Шулай да, император Сенатта академия оештыру турындагы приказга бары тик 1724 нче елның 13 нче гыйнварында гына кул куя.

Пётр I фикеренчә: «Академия Европада безгә карата ышаныч һәм дәрәҗә тудырырга тиеш». Шулай итеп, Фәннәр академиясе оешкан көн булып, Сенат тарафыннан аны оештыру турындагы указ игълан ителгән көн, ягъни 1724 нче елның 28 нче гыйнвары санала.

Башта Академия Зур Нева яры урамында урнашкан була. Монда ук 1725 нче елның 27 нче декабрендә беренче академия утырышы була. Фәннәр акдемиясенең беренче президенты бу-

лып, Л.Л.Блюментрост билгеләнә. Фән һәм мәгърифәтчелек үзәге буларак, академия елдан-ел үсә бара, яңа биналары барлыкка килә.

Петербургта Фәннәр академиясе 210 ел эшли. 1934 нче елда Академия президиумы һәм аның кайбер институтлары хөкүмәт тарафыннан Мәскәүгә күчерелә. Шулай да Санкт-Петербург әле дә зур фәнни үзәкнең берсе булып тора.

**III. Рефлексив бәяләү**

1. — Дәрескә куелган уку мәсьәләсе чишелдеме?

— Фатих Кәриминең тормыш юлы турында нәрсәләр белдегез?

2. — Тест сорауларына җаваплар бирегез. Язучының тормыш юлы турында сорауларга дөрес җавапны сайлагыз.

**Тест**

1. Фатих Кәрими кайда туган?
а) Сарман районы Дусай авылында;
ә) Кукмара районы Балыклы авылында;
б) Әлмәт районы Миңлебай авылында.
2. Фатих Кәриминең эшчәнлек сферасына туры килмәгән өзекне күрсәтегез.
а) Шагыйрь;
ә) журналист;
б) әдип.
3.Фатих Кәрими Европа сәяхәтенә кем белән китә?
а) Шакир Рәмиев;
ә) Закир Камали;
б) Фатих Әмирхан.
4. Фатих Кәрими «Аурупа сәяхәтнамәсе»н ничәнче елда яза?
а) 1902 нче елда;
ә) 1905 нче елда;
б) 1907 нче елда.
5. Фатих Кәриминең «Аурупа сәяхәтнамәсе» нинди жанрда язылган?
а) Хикәя;
ә) повесть;
б) сәяхәтнамә.
6. Әсәр турында үзеңнең фикереңне әйт: ул нинди тәэсир калдырды?
7. «Аурупа сәяхәтнамәсе» язмасының әдәби кыйммәте нидән гыйбарәт?

**Нәтиҗә:** Фатих Кәрими татар җәмәгатьчелеген беренче мәртәбә Европа илләрендәге культура учаклары, әдәбият һәм сәнгать музейлары белән якыннанрак таныштыра. Бу хезмәтнең төп әһәмияте дә шунда. Яшь мәгърифәтче әдип Париждагы атаклы Лувр музеен, шунда бөтен дөньядан җыелган сәнгать җәүһәрләрен аеруча сокланып карый, татарларда культурага шундый игътибар кайчан булыр икән, дигән уйлар кичерә...

3. — «Ибне Фадланның 921 — 922 нче елларда Болгар дәүләтенә сәфәре вакытында язылган сәяхәтнамәсе» язмалары һәм Фатих Кәриминең «Аурупа сәяхәтнамәсе» язмалары арасында уртаклык бармы? Аңлатыгыз.

4. Дәрескә гомуми бәя. Укучыларга билге кую.

5. Өй эше: а) «Аурупа сәяхәтнамәсе»н сәнгатьле укырга;

ә) кайларга сәяхәт иткәнегез бар, сөйләргә өйрәнеп килергә. Теләк буенча сәяхәтнамә язарга.

б) 45 нче биттәге сорауларга җавап.

### Укытучы өчен өстәмә материал

1900 нче елда аталы-уллы Кәримиләр Оренбургта типография ачалар, ә 1902 нче елда Гыйльман Кәрими вафат булгач, бу эш тулысынча Фатих кулына күчә. Бу вакытларда инде Ф.Кәрими әдәби әсәрләр авторы — язучы-прозаик буларак та танылып өлгерә.

1905 — 1907 нче еллардагы революция чорында һәм аннан соң Ф.Кәрими үзенең төп игътибарын журналистлык хезмәтенә юнәлтә. 1916 — 1917 нче елларда ул Оренбургта чыккан «Вакыт» газетасының баш редакторы булып эшли, шушы газета һәм «Шура» журналы битләрендә иҗтимагый, мәдәни тормышның төрле мәсьәләләренә багышланган мәкаләләрен, очеркларын бастыра.

1917 нче елның 1 нче ноябреннән башлап, Ф.Кәрими үз наширлегендә «Яңа вакыт» газетасын чыгара. Бер үк вакытта Ф.Кәрими Оренбургта культура, укыту, тәрбия эшләрен оештыру һәм алып баруга актив катнаша. Татар, башкорт һәм казах мәктәпләренә мөгаллимнәр әзерләү курсларында укыта. Оренбургта 1919 нчы елның көзендә мәгариф институтлары (татарлар өчен аерым, башкортлар өчен аерым) ачыла. Соңрак шунда ук татар педагогия техникумы оештырыла. Ф.Кәрими, бу уку йортларының өлкән укытучыларыннан берсе буларак, яшьләрне тәрбияләүгә, белем бирүгә зур өлеш кертә. Шул ук елларда Оренбургта татар мәгариф институты каршында әдәбият түгәрәге оеша, аның да җитәкчесе Ф.Кәрими була. Аның эшендә Муса Җәлил дә актив катнаша. Шул түгәрәк путёвкасы белән, М.Җәлил Казанга укырга китә.

1925 нче елның гыйнвареннан башлап, Ф.Кәрими Мәскәүдә яши, СССР халыкларының Үзәк нәшриятында эшли һәм Н.Нариманов исемендәге Көнчыгыш университетында төрек теле укыта.

1925 нче елда аның «Фатих Кәрими әсәрләре» дигән хикәяләр («Салих бабайның өйләнүе», «Шәкерт белән студент», «Җиһангир мәхдүм», «Гаяш хәлфә») җыентыгы Казанда басылып чыга. Дәрдемәнднең 1929 нчы елгы шигырьләр җыентыгындагы Ф.Кәрими язган тулы биография — әдипнең татар әдәбиятын өйрәнү хезмәтләренең бер матур мисалы. Ф.Кәрими Көнчыгышны өйрәнүче бик күп галимнәрдән һәм язучылардан үзенә килгән хатларны, күп кенә газета-журнал мәкаләләрен җыеп барган. Ул материаллар хәзер Татарстанның дәүләт архивында саклана. Гаять бай бу фонд — Ф.Кәриминең әдәби һәм журналистлык эшчәнлеген өйрәнү өчен генә түгел, бәлки замандашларына бәйләнешле мәсьәләләрне ачыклауда да гаять әһәмиятле чыганак.

Әдипнең гомере фаҗигале тәмамлана. 1937 нче елның 4 нче августында аны Мәскәүдә кулга алалар. 27 нче сентябрьдә СССР Югары судының Хәрби коллегиясе Ф.Кәримине үлем җәзасына хөкем итә. Хөкем шул ук елны карарга кергән булырга тиеш. Кабере билгесез.

*Рафаэль Мостафиннан*

## 8 нче дәрес

**Тема:** Энҗе табучы әдип.

**Планлаштырылган нәтиҗәләр:**

М е т а п р е д м е т — язучы яшәгән чорга бәя бирү, тарихны аңлау.

П р е д м е т — Миргазиян Юныснең тормыш юлы һәм иҗаты белән танышу, «Су» хикәясен өйрәнү.

Ш ә х е с к ә  к а г ы л ы ш л ы — әдипнең тормыш юлына, әсәренә нигезләнеп, туган илне сагыну, Ватанга, туган җиргә, табигатькә мәхәббәт хисләре тәрбияләү.

**Материал:** дәреслекнең 1 нче кисәге, 45—49 нчы битләр.

**Җиһазлау:** мультимедиа проекторы, экран (такта), презентация, китаплар күргәзмәсе, сүзлекләр; Интернеттан алынган материаллар (М.Юныс сөйләве Интернет челтәрендә — You Tube)

Э к р а н д а — Миргазиян Юныс сүзләре: «Үткән заман тарихын аңлау киләчәккә бару өчен кирәк. Узгандагы ялгышларны белү киләчәктә аларны кабатламас өчен кирәк. Үзең яшәгән чорны бәяләү өчен дә тарихны белү яхшы».

Миргазиян Юныс — уникаль шәхес. Ул, талантлы әдип булу өстенә, искиткеч оста әңгәмәдәш, гаҗәеп оста рәссам, һәрчак юлга чыгарга атлыгып торган тынгысыз сәяхәтче дә. Аның җаны һәрчак борчулы, һәрчак хәрәкәттә...

### Д ә р е с   б а р ы ш ы:

**I. Мотивлаштыру-ориентлаштыру**

***1. Дәресне оештыру***

— Исәнмесез! Кәефегез ничек? Барыбызга да хәерле көннәр, уңышлар теләп, дәресне башлыйк.

***2. Актуальләштерү***

1) Өй эшен тикшерү: укучылар язып килгән сәяхәтнамәләрен укыйлар.

2) Сорауларга җавап.

— Сәяхәтнамә һәм елъязмаларның нинди уртак һәм аермалы яклары бар?

— Мәдәният учакларының кыйммәте нидән гыйбарәт?

***3. Уку мәсьәләсен кую***

— Кеше җирдә беренче адымнарын ясый, тәпи йөреп китә. Җир аның бишеге, туган йорты булса да, кешене галәм һәм дәрья киңлекләре кызыктыра, һәм кеше олы дөньяга ташлана: тугыз баллы гигант дулкыннар белән бәхәскә керә, болытлардан да өскәрәк күтәрелеп, күкнең җиденче катыннан тәпи йөреп киткән җирен күзәтә.

Кайда гына булмасын — күктәме, җирдәме, судамы — кеше үзен-үзе сыный, мораль һәм рухи сыйфатларның ныклыгына, батырлыкка һәм фидакарьлеккә имтихан тота. Шул имтихан уза алган кешеләр генә тормышта үз-үзен таба, башкалар алдында ихтирам казана. Күктә дә, җирдә дә, суда да булган кешеләрнең берсе — Миргазиян Юныс.

Укытучы бүген дә дәрестә үзенә язылган язмыш сынауларын җиңеп, сыгылмыйча, сынмыйча, алга — биеккә күтәрелүчеләр турында сөйләшүне дәвам итәчәкләрен әйтә.

Бүгенге дәреснең темасы — Миргазиян Юнысның тормыш юлы, иҗаты һәм «Су» хикәясе белән танышу.

Темадан чыгып, дәрескә уку мәсьәләсен укучылар белән бергәләп кую.

1) Миргазиян Юнысның тормыш юлы, иҗаты белән танышу.

2) «Су» хикәясен чылбыр буенча уку, аңлау.

**II. Уку мәсьәләсен өлешләп чишү**

1. Язучының иҗаты, тормыш юлы турында мәгълүмат.

1) — Миргазиян Юныс турында моңарчы ишеткәнегез бар идеме?

2) Интернет челтәреннән М.Юнысның сөйләвен тыңлау.

3) Укытучының тулыландырып сөйләве. Миргазиян Юнысның тормыш юлы; язучылык эше; сынчылык эше; диңгезчелек хезмәте.

2. «Су» хикәясен чылбыр буенча уку.

1) 1 нче абзацны укытучының сәнгатьле укуы, укучылар, күз йөртеп, карап баралар, тыңлыйлар. Калган өлешләрне укучыларның үзләреннән укытып аңлауга ирешү.

1 нче абзацның һәр җөмләсен уку, сүзлекчәне кулланып, сүзгә-сүз русчага тәрҗемә итү.

1 нче абзацның эчтәлеге буенча сорауларга җавап бирү: китаптан табып уку яки кыскача үз сүзләре белән әйтү.

— Вакыйга ничәнче елларда, кая бара? Әсәр кем исеменнән сөйләнелә? Автор нәрсә белән хозурлана? Ни өчен ул Венецияне «Әдрән диңгезнең гүзәл энҗесе» дип атый?

2) 2 нче абзац белән шул ук тәртиптә эшләү. Сорауларга җавап бирү:

— Венеция кайда урнашкан? (Географик урынын искә төшерү, укучыларның географиядән алган белемнәре белән уртаклашу.) Ул ничә канал белән бүлгәләнгән? Ни өчен Венецияне утрау өстенә салганнар? Шәһәрне материк белән нәрсә тоташтыра? Исемен атагыз. Шәһәр эчендә ничә күпер бар?

— 7 нче сыйныфта Илдар Юзеевның «Ак калфагым төшердем кулдан» әсәрендә «телевизион күпер» турында сөйләштегез. *Күпер* сүзенең мәгънәсен сез ничек аңлыйсыз? (Дуслык күпере, телевизион күпер һ.б.)

3) 3 нче абзац белән эшләү өчен сораулар.

— Венециянең материктагы өлешен ничек атыйлар? «Ат юлы» дип аталган мәйданнан автобус кая юл тота? Ни өчен бу як тылсымлы?

4) 4 нче абзац белән эшләү өчен сораулар.

— Автобус кая килеп туктый? Сан Марко мәйданына ничек барырга була? Совет диңгезчеләре ни өчен «унберенче трамвайны» сайлыйлар? «Унберенче трамвай» нәрсә ул?

5) 5 нче абзац белән эшләү өчен сораулар.

— Шәһәргә кемнәр күбрәк килә? Ул кемнәрне очратмый? «Безгә алмашка киләсе яшь буынга, белмим, мондый бәхет тәтерме, юкмы». Бу сүзләрдән авторның кичерешен ничек аңлатып була?

6) 6 нчы абзац белән эшләү өчен сораулар.

— Күпер астыннан нәрсә уза? Нинди көй яңгырап кала? —

Күпердән төшүгә, ул урамда нәрсәләр белән таныша? Бронзадан ясалган нинди шәхесне күрә?

7) 7 нче абзац белән эшләү өчен сораулар.

— Венециядән Мариуполь портына ничә тәүлек кайтасы? Азов диңгезе турында нәрсәләр белүегез турында сөйләгез. Китаптан табып укыгыз.

3. Һәр абзац белән шул рәвешле танышып чыккач, әсәрнең автор язмышы белән охшаш булуын ачыклау.

4. Дәреслектән 4 нче биремне телдән эшләү.

**III. Рефлексив бәяләү**

1. — Дәрескә куелган уку мәсьәләсе чишелдеме?

1) — Миргазиян Юныс турында нәрсәләр белдегез? Тест сорауларына җавап бирегез. Язучының тормыш юлы турында сорауларга дөрес җавапны сайлагыз.

**Тест**

1. Миргазиян Юнысның туган җире:
а) Татарстанның Баулы районы Исергәп авылы;
ә) Оренбург өлкәсенең Мостафа авылы;
б) Татарстанның Зәй районы Урта Баграж авылы.

2. Миргазиян Юнысның туган көне:
а) 1927 нче ел, 25 нче май;
ә) 1925 нче ел, 27 нче май;
б) 1930 нчы ел, 30 нчы май.

3. Ничә яшьтә Бөек Ватан сугышына китә?
а) 18 яшьтә;
ә) 17 яшьтә;
б) 20 яшьтә.

4. Миргазиян Юнысның эшчәнлек сферасына туры килмәгән өлкәне күрсәтегез.
а) Очучы;
ә) укытучы;
б) диңгезче.

5. Миргазиян Юнысның «Су» хикәясе нинди жанрда язылган?
а) Эпик;
ә) драматик;
б) лирик.

2) — Әсәрнең исеме ни өчен «Су» дип атала?

**Нәтиҗә:** бу хикәяне укыганда, без һәммәбез бер фикергә киләбездер, мөгаен — яшәү җиңел түгел, әмма яшәргә кирәк.

Язучының геройлары, аларның кичерешләре, яшәү рәвешләре, сагынуны басуга корылган гамәлләре — барысы да Миргазиян Юныс үзе икән. Аның әсәрләрендә туган җирне сагыну беренче урында тора. Язучы чит җирләргә язмыш тарафыннан ташланган татар халкы тормышын сурәтли.

3. Дәрескә гомуми бәя. Укучыларга билге кую.

4. Өй эше:

а) «Су» хикәясен сәнгатьле укырга өйрәнергә, тәрҗемәсен белергә;

ә) әсәр буенча план төзергә;

б) дәреслектән 3 нче биремне эшләргә (49 нчы бит).

### Укытучы өчен өстәмә материал

1944 нче елда 16 яшьлек Миргазиян, үзе теләп, Совет Армиясе сафларына китә. Укчы штурмовиклар мәктәбен тәмамлап, ИЛ-2 самолётына утыра. Сугышның соңгы көннәренә эләккән яшь егет Җиңү көнен Германия шәһәрләренең берсендә каршылый. Сугыштан соң киң илебезнең бер читеннән икенче читенә кадәр күкне гизә. Моның белән генә чикләнмичә, 1950 нче елны Харьков хәрби авиация училищесына укырга керә. Училищены уңышлы тәмамлаганнан соң, авиаэскадрильяда элемтә начальнигы булып хезмәт итә. Ләкин егет Сахалиннан котыпка очканда һәлакәткә юлыга, һәм табиблар аңа очарга рөхсәт итмиләр. Бу авырлыклар да Миргазиянның романтик рухын сындыра алмый. Шуннан соң ул кичке мәктәптә укый, гомуми урта белем ала. Хәзер инде ул югары белем турында хыяллана. Максатына ирешү өчен, Миргазиян Юныс көне-төне укый, рус һәм дөнья классикларын өйрәнә, программадан тыш та бик күп китаплар укып чыга. Һәм, бөтен имтиханнарны уңышлы биреп, Ломоносов исемендәге Мәскәү университетының филология факультетында укырга хокук ала.

Бер-ике ел университетта укыганнан соң, Миргазиян читтән торып уку бүлегенә күчә һәм Одессага китеп бара. Башта, гади матрос булып, Россиянең эчке диңгезләрендә йөри. Ниһаять, 1957 нче елда кыска вакытлы курсларны бетергәч, аны чит илләрдә йөри торган сәүдә корабына капитанның политик эшләр буенча ярдәмчесе итеп эшкә алалар.

Италия, Испания, Франция, Греция, Төркия, Алжир, Һиндстан, Вьетнам... Ул аяк баскан җирләрнең очына чыгарлык түгел. Миргазиян Җир шарын берничә тапкыр әйләнеп чыга. Аның 30 ел гомере диңгездә үтә. Шушы вакыт эчендә ул чит телләрне дә яхшы гына үзләштереп өлгерә. Миргазиян Юныс һәрбер илнең үзенә генә хас булган гореф-гадәтләрен, халкын, бәйрәмнәрен, шәһәрләрен, үсемлекләренә хәтле белә, алар турында бик озак итеп сөйли ала.

Аның биографиясе генә дә әллә ничә китаплык. Шуңа да язучы бер генә әсәрен дә һавадан алып язмый. Ул «Занзибар зәңгәр болытлар артында» повесте белән укучының ихтирамын казанды. «Табу һәм югалту», «Шәмдәлләрдә генә утлар яна» исемле повестьлары — бүген дә укучылар тарафыннан яратып укыла торган китаплар.

«Энҗе эзләүчеләр» җыентыгында М.Юнысның 1961—1971 нче елларда язылган повестьлары, хикәяләре һәм юлъязмалары тупланган. Китапның беренче битләрендә үк экзотик табигатьле ерак илләргә барып чыгасың. Кызыл һәм Кариб диңгезләрен, Италиядәге Генуя һәм Неаполь, Англиядәге Плимут шәһәрләрен үз күзең белән күргән кебек буласың. Ерак сәяхәтләр романтикасы яшьләр өчен бик кирәк. Профессиональ диңгезче булып өч дистәдән артык еллар эшләгән, дөньяны аркылыга-буйга гизгән Миргазиян Юныс иҗаты — бүген татар әдәбиятында тиңдәшсез.

1964 нче елны «Казан утлары» журналында яшь авторның «Безнең өй өянке астында иде...» исемле, Италиядәге Генуя шәһәрендә туган илен сагынып яшәүче бер татар карчыгының самими образын тасвирлаган, туган телендә язылган беренче хикәясе дөнья күрә. Аннан соң шул ук «Казан утлары», «Ялкын», «Азат хатын» журналларында бер-бер артлы «Энҗе эзләүчеләр», «Кочегар», «Йәмәнгә сәяхәт», «Диңгез чакыра», «Зәңгәр дөнья», «Румба негры» кебек хикәяләре, юлъязмалары басыла. 1968 нче елда Татарстан китап нәшриятында, «Тимер фил» исеме белән, беренче хикәяләр җыентыгы чыга.

Язучының иң көчле, иң отышлы әсәрләренең берсе — «Дөнья гизү» трилогиясе. Әсәрдә тасвирланган вакыйгаларның күбесен автор үз башыннан кичкән.

Җитмешенче-сиксәненче еллар М.Юнысның иҗат биографиясендә күләмле проза әсәрләре белән характерлы. Үз биографиясенә нигезләп язылган һәм диңгезче хезмәтенең романтикасын да, шул ук вакытта кешедән күп тырышлык, чыдамлык, ихтыяр көче сорый торган кырыс хакыйкатен дә бөтен профессиональ ваклыклары белән укучы күз алдына китереп бастырган «Тозлы җил», «Теләп алынган давыл», «Таңда Босфор аша» повестьлары; авыл — шәһәр кешеләре арасындагы каршылыклы мөнәсәбәтләрне лирик-психологик планда сурәтләгән «Табу һәм югалту» повесте, «Вавилон елгалары», «Шәрекъ», «Европа ат сагына», «Соңгы сулыш» исемле өч китаптан торган «Юлда уйланулар» юлъязма-сәяхәтнамәсе — әнә шундыйлардан.

## 9 нчы дәрес

**Тема:** Җиктереп пар ат, Казанга!

**Планлаштырылган нәтиҗәләр:**

Метапредмет — Габдулла Тукай яшәгән чор турында тарихи белешмә бирү.

Предмет — шагыйрьнең тормыш юлы һәм иҗаты турында өстәмә мәгълүмат бирү, «Пар ат» шигырен өйрәнү.

Шәхескә кагылышлы — татар халкының бөек әдипләре иҗатын өйрәнү аша тормышка караш тәрбияләү.

**Материал**: дәреслекнең 1 нче кисәге (57—63 нче битләр).

**Җиһазлау**: компьютер, мультимедиа аппаратурасы, компьютер презентацияләре: «Г.Тукай», язучы тормышы һәм иҗаты турында плакат, китаплар күргәзмәсе, матбугатта чыккан белешмәләр, материаллар, И.Шакиров башкаруында Г.Тукай сүзләренә язылган «Пар ат» җыры язмасы, РСФСРның халык артисты Айрат Арсланов башкаруында «Пар ат» шигыренең язмасы.

**Дәреснең эпиграфы:**

Күз карашыңда синең дөнья күренде — мәңге төн;
Киттең эзләп син, аны яктыртмага, идеал утын.

*Г.Тукай*

Открылся мир твоим глазам, и ты увидел мрак ночной.
И ты пошёл искать огонь, чтоб светлым сделать мир земной.

*(Перевод Я.Хелемского)*

### Дәрес барышы:

**I. Мотивлаштыру-ориентлаштыру**

***1. Дәресне оештыру***

Уңай психологик халәт тудыру.

***2. Актуальләштерү***

1) Өй эшен тикшерү: Миргазиян Юныс иҗатын кабатлау.

2) Укучылар өйдә төзегән план буенча әңгәмә оештырыла.

Миргазиян Юныс әйткән сүзләр искә төшерелә: «Үткән заман тарихын аңлау киләчәккә бару өчен кирәк. Узгандагы ялгышларны белү киләчәктә аларны кабатламас өчен кирәк. Үзең яшәгән чорны бәяләү өчен дә тарихны белү яхшы».

М.Юныска сәүдә корабларында күп илләр гизәргә туры килсә, Бөек Тукаебыз Казанга «Пар ат»та килеп керде.

*3. Уку мәсьәләсен кую*

Г.Тукай тормышы һәм иҗаты турында искә төшерү. Казан чорын өйрәнү. Г.Тукайның «Пар ат» шигырен уку, язылу тарихы белән танышу.

**II. Уку мәсьәләсен өлешләп чишү**

1. Габдулла Тукайның биографиясенә кагылышлы өстәмә материаллар белән танышу.

1) Укытучы шагыйрьнең шигырьләрен, китапларын күрсәтеп, тормышы һәм иҗаты белән таныштыруны дәвам итә.

2) Бер укучы дәреслектән Г.Тукай турындагы белешмәне укый.

3) Укытучы, сораулар ярдәмендә, укучыларның аңлавын тикшерә. 59 нчы биттәге 2—6 нчы биремнәр эшләнелә.

2. Сүзлек белән эш.

1) Укытучы сүзләрне укый, укучылар аның артыннан кабатлыйлар. Авыр сүзләрне аерым укучылардан кабатлаттыра.

2) Укытучы русчасын әйтә, укучылар тәрҗемәсен әйтәләр.

3) Укучылар, чылбыр буенча, яңа сүзләр белән сүзтезмәләр яки җөмләләр төзеп әйтәләр.

3. Укучылар Габдулла Тукай яшәгән шәһәр, авыллар астына ул яшәгән елларның даталарын язып куялар.

Тукай белән бәйле урыннар:

а) Кушлавыч авылы (туган);
ә) Сасна авылы (әнисе янында);
б) Өчиле авылы (бабасы йорты);
в) Казанның Печән базары;
г) Казанның Яңа Бистәсе;
д) Өчиле авылы;
е) Кырлай (Сәгъди абзый йорты);
ж) Уральск шәһәре;
з) Казан шәһәре.

Гомеренең Казанда яшәгән соңгы елларында Г.Тукайга шактый сәяхәт итәргә туры килә. Ул Арча өязенең Кырлай, Кушлавыч, Өчиле, Каенсар, Әтнә кебек авылларында, Сембер өязенең Гурьевка посёлогында, Түбән Новгород шәһәрендәге Мәкәрҗә ярминкәсендә, Әстерхан, Самара, Уфа, Петербург, Троицк кебек шәһәрләрдә була. (Укучылар схема ясыйлар.)

3. Габдулла Тукайның «Пар ат» шигыренең язылу тарихы белән танышу. Дәреслектән уку.

— Казанга кайту өметләре белән дәртләнеп, Габдулла Тукай Җаекта чакта ук «Пар ат» шигырен иҗат итә. 1907 нче елның

көзендә Тукай, 12 ел яшәгән Җаек каласын калдырып, поезд белән Казанга кайтып төшә. Килереннән 5 ай элек киләчәккә якты өметләр белән сугарылган «Пар ат» шигырен яза. Шигырь беренче мәртәбә «Фикер» газетасының 1907 нче елгы 6 нчы май һәм «Әлгасрелҗәдид» журналының шул ук елгы 5 нче май санында басыла. 1914 нче елда «Пар ат» шигыре, Тукайның кыскача биографиясе белән, «Россияне күзәтү» дигән журналда инглиз телендә басылып чыга. Шигырьгә З.Хәбибуллин тарафыннан көй язылган. Җыр буларак күбрәк Э.Җәләлетдинов тарафыннан башкарыла.

4. Габдулла Тукайның «Пар ат» шигырен уку. Шигырь, укытучы тарафыннан, сәнгатьле итеп яттан укыла.

5. Видеоязма карау, шигырьне язмада тыңлау. Шигырьне РСФСРның халык артисты Айрат Арсланов башкаруында икенче кат тыңлау, я булмаса, матур, йөгерек укый торган баладан кычкырып укыту.

6. Сүзлек эше.

7. «Пар ат» шигыренең рус теленә тәрҗемәсе белән танышу (А.Ахматова).

— Г.Тукай шигырьләре күп телләргә тәрҗемә ителгән. Күренекле шагыйрә Анна Ахматова тәрҗемә өчен юкка гына Тукайны сайламый. Уртак авырлыклар, ачы тормыш газаплары аларның иҗатын якынлаштыра. «Ачның хәлен тук белми,» — ди безнең халык. Күз алдына китерегез. 1910 нчы ел... «Болгар», «Амур» кунакханәләренең ягылмаган салкын бүлмәләре... Аңлашылмаган мәхәббәт... Өзелгән өмет... үпкә чире... Санап китсәң — күп алар. Шагыйрә Анна Ахматова да авыр тормыш кичергән. Илебездә булган кара еллар Ахматова тормышын да читләтеп үтмәгән.

8. Төркемнәрдә эш. Укучылар, тәкъдим ителгән биремнәр буенча, төркемнәрдә эзләнә, тикшерә, фикер алыша, нәтиҗә чыгара. Төркем җитәкчеләре йомгак ясый.

— «Пар ат» шигырен тәрҗемәсе белән чагыштырып укыгыз. Үзгәрешләр бармы? Нинди сүзләр тәрҗемә ителмәгән? Аларны дәфтәрегезгә языгыз. (Тәрҗемә ителмәгән: *намаз, Казан, шәкерт, кучер*, ялгызлык исемнәр: *Миңгали, Бикмулла, Бикмөхәммәт, Биктимер.)*

— Ни өчен бу сүзләр тәрҗемә ителмәгән? (А.Ахматова бу сүзләрне тәрҗемә итмәүнең сәбәбе шундадыр: шагыйрә татар шигыренең үзенчәлеген сакларга тырышкан, авторның дөньяга, әйләнә-тирәгә мәдәни күз карашын саклаган.)

— Лирик геройның эчке кичерешләрен ачыклауда Г.Тукай нинди эпитетлар куллана? Бу сүзләр кайсы сүз төркеменә керә? Шул ук эпитетлар тәрҗемәдә сакланалармы? (*Әкрен, тын, япят, таныш, иртәнге, моңлы, дәртле, нурлы.*)

— Габдулла Тукай кулланган эпитетлар рус телендә сакланмаган. Анна Ахматова тарафыннан иҗат ителгән тәрҗемә оригиналдан күпмедер аерыла икәнен ачыкладык.

— Шуңа карамастан, Тукай идеясе сакланган. Гомумән алганда, бик матур тәрҗемә, татар телен белмәгән кешеләр дә Тукай иҗаты белән таныша ала, чөнки рус телле укучы, шигырьнең тәрҗемәсен укып, Тукайның шигъри дөньясын ача алачак. Габдулла Тукай, татар шигыре ил алдында да, дөнья алдында да сынатырлык түгел, чөнки, дәреснең эпиграфында әйтелгәнчә, шагыйрь бөтен халык тормышының идеалына омтылган.

**III. Рефлексив бәяләү**

1. Укучылар тестларны эшлиләр.

2. Бәяләү. Укучыларга, дәрестә катнашканнары бәяләнеп, билгеләр куела.

3. Өй эше:

а) шигырьне сәнгатьле укырга өйрәнергә;

ә) шигырьне өлешләргә бүлергә, план төзергә.

4. Алдагы дәрескә проблема кую. Укытучы, дәресне тәмамлаганчы, йомгаклап, нәтиҗә ясар өчен сораулар бирә:

— Лирик геройга нинди бәя биреп була? Ул Казанны нинди шәһәр дип атый?

— Шигырь нәрсә турында?

— Тукай Казанны тарихи шәһәр (*бабайлар түре һәм почмагы*), гыйлем, мәгърифәт нурларын чәчүче мәдәният үзәге, оҗмахтагыдай нечкә билле хур кызлары белән тулы сөю-сәгадәт җире, булдыклы кешеләр иле (*гыйрфан*) дип атый, идеаллаштыра. Шигырь — шагыйрьнең милләт учагы булган Казанны зурлавы, хөрмәтләве, аңа зур өметләр баглавы турында.

## Укытучы өчен өстәмә материал

1907 нче елның 10 нчы октябреннән Габдулла Тукай тормышының Казан чоры башлана. Биредә ул шагыйрь, журналист, җәмәгать эшлеклесе буларак таныла.

Бу — илдә реакция кызып киткән вакытлар. Тукай Казанга кайту турында күптән хыялланып йөргән була. Әле Уральскида чакта,

1906 нчы елның җәендә, Казанга килү күренешләрен күзаллап, эчке бер күтәренкелек, романтик эчтәлек белән, ул «Пар ат» шигырен яза.

Алдарак әйтелгәнчә, Тукайның «Пар ат»ы иң беренче мәртәбә Уральскида «Әлгасрелҗәдит» газетасының 1906 нчы елгы 6 нчы май санында басыла. Әдәбият галиме Г.Халит исә аны 1907 нче елда язылган — Тукай Казанга кайткач язган шигырь дип саный (чөнки «Пар ат» шигыре Г.Тукайның «Габдулла Тукаев шигырьләре, 3 нче дәфтәр» дигән җыентыгында басыла (Казан, 1907).

«Пар ат» шигырендә халык җырлары рухы бар. Казан белән алдагы очрашу темасы «Пар ат» шигырендә поэтик яктан гаять тәэсирле итеп ачылган.

Казанда Тукай алдынгы татар зыялылары белән таныша, әдәби түгәрәкләргә йөри. 1910 нчы елның 15 нче апрелендә «Шәрык клубы»нда укыган «Халык иҗаты» лекциясе шәһәр яшьләрен таң калдыра. Ул «Әл-ислах» («Реформа») газетасының әдәбият бүлеге мөдире, «Яшен», «Ялт-Йолт» сатирик журналларының җаваплы сәркатибе, «Аң» журналы һәм «Кояш» газетасының хәбәрчесе вазифаларын да башкара.

Г.Тукайның беренче китабы «Г.Тукаев шигырьләре» исеме белән 1907 нче елның 17 нче ноябрендә Шәрәфләр типографиясендә басыла. 1908 нче елның 6 нчы гыйнварында икенче китабы нәшер ителә. Шулай итеп, 1913 нче елга кадәр аның барлыгы 35 китабы дөнья күрә. Ул һәрьяктан сәләтле бөек шагыйрь буларак танылa: бер яктан нечкә лирик, ә икенче яктан — үткен сатирик.

Гомеренең әлеге чорында Г.Тукай «Печән базары, яхуд Яңа Кисекбаш», «Мияубикә», «Су анасы», «Суык», «Кәҗә белән Сарык әкияте» поэмалары, «Исемдә калганнар» повесте, «Халык әдәбияты», «Милли моңнар» әсәрләре, «Туган тел», «Таз», «Туган авыл», «Көзге җилләр», «Китап» шигырьләре кебек үлемсез әсәрләрен иҗат итә. Монда Тукай тәнкыйтьче, тәрҗемәче, фикер иясе, фольклорчы галим, балалар язучысы, педагог булып җитлегә. Чын халык шагыйре, татар әдәби теленә һәм реалистик әдәбиятына нигез салучыларның берсе булып танылa.

*Ибраһим Нуруллиннан*

*Габдулла Тукай*

**Пара лошадей**

Лошадей в упряжке пара, на Казань лежит мой путь,
И готов рукою крепкой кучер вожжи натянуть.

Свет вечерний тих и ласков, под луною все блестит,
Ветерок прохладный веет и ветвями шевелит.

Тишина кругом, и только мысли что-то шепчут мне,
Дрема мне глаза смыкает, сны витают в тишине.

Вдруг, открыв глаза, я вижу незнакомые поля, —
И разлуку с отчим краем всей душой почуял я.

Край родной, не будь в обиде, край любимый, о, прости,
Место, где я жил надеждой людям пользу принести!

О, прощай, родимый город, город детства моего!
Милый дом во мгле растаял — словно не было его.

Скучно мне, тоскует сердце, горько думать о своем.
Нет друзей моих со мною, я и дума — мы вдвоем.

Как на грех еще и кучер призадумался, притих,
Ни красавиц он не славит, ни колечек золотых...

Мне недостает чего-то иль я что-то потерял?
Всем богат я, нет лишь близких, сиротой я нынче стал.

Здесь чужие все: кто эти Мингали и Бикмулла,
Биктимир? Кому известны их поступки и дела?

Я с родными разлучился, жить несносно стало мне,
И по милым я скучаю, как по солнцу, по луне.

И от этих дум тяжелых головою я поник,
И невольно слезы льются — горя горького родник.

Вдруг ушей моих коснулся голос звонкий, молодой:
— Эй, шакирд, вставай скорее! Вот Казань перед тобой!

Вздрогнул я, услышав это, и на сердце веселей.
— Ну, айда быстрее, кучер! Погоняй своих коней!

Слышу я: призыв к намазу будит утреннюю рань,
О Казань, ты грусть и бодрость! Светозарная Казань!

Здесь деянья дедов наших, здесь священные места,
Здесь счастливца ожидают милой гурии уста.

Здесь науки, здесь искусства, просвещения очаг,
Здесь живет моя подруга, райский свет в ее очах.

*Перевод Анны Ахматовой*

**Г.Тукайның тормыш юлы һәм иҗатына багышланган тест**

1. Г.Тукайның туган елы:
а) 1901;
ә) 1891;
б) 1886.
2. Уральск шәһәренең элекеге исеме:
а) Җәйлек;
ә) Җаек;
б) Җиләк.
3. Г.Тукай кайсы авылда туган:
а) Кушлавыч;
ә) Өчиле;
б) Кырлай.
4. Г.Тукайның автобиографик повесте исеме:
а) «Исемдә калганнар»;
ә) «Хатирәләр»;
б) «Габдулла Тукай».
5. Тукайның әти-әнисенең исеме:
а) Шәмсенур, Гайнулла;
ә) Мәмдүдә, Гайнулла;
б) Мәмдүдә, Мөхәммәтгариф.
6. Г.Тукайның туган көне:
а) 26 нчы апрель;
ә) 25 нче май;
б) 16 нчы апрель.
7. Тукай Казанга кайчан килә:
а) 1907 нче елның көзендә;
ә) 1907 нче елның язында;
б) 1907 нче елның кышында.
8. Тукайның Казанга килүе кайсы шигырендә тасвирлана:
а) «Китмибез»;
ә) «Пар ат»;
б) «Милли моңнар».

## 10 нчы дәрес

**Тема:** Монда хикмәт, мәгърифәт һәм монда гыйрфан, монда нур...

**Планлаштырылган нәтиҗәләр:**

М е т а п р е д м е т — тема буенча теоретик төшенчәләрне бирү. Әдәби-теоретик күнекмәләр булдыру.

П р е д м е т — Габдулла Тукайның «Пар ат» шигырен өйрәнү. Лирик әсәрне аңларга, андагы хис-кичерешләрне тоярга, аларның үсү-үзгәрүен яки алмашынуын күрергә әзерләү.

Ш ә х е с к ә к а г ы л ы ш л ы — туган җиргә, Ватанга мәхәббәт тәрбияләү.

**Материал:** дәреслек (1 нче кисәк, 59—63 нче битләр).

**Җиһазлау:** Г.Тукай портреты, мультимедиа проекторы, аудио-видеоязмалар, Г.Тукай китаплары күргәзмәсе, И.Шакиров башкаруында Г.Тукай сүзләренә язылган «Пар ат» җыры язмасы, Татарстан дәүләт фольклор ансамбленең «Пар ат» җыры видеоязмасы.

### Д ә р е с б а р ы ш ы:

**I. Мотивлаштыру-ориентлаштыру**

***1. Дәресне оештыру***

Дәресне башлау. Уңай психологик халәт тудыру.

***2. Актуальләштерү***

1) Өй эшен тикшерү: шигырьдән алган тәэсирләр турында сөйләшү-фикерләшү.

2) Укытучы, юнәлдерүче сораулар биреп, шигырьне анализлау максатыннан, әңгәмә оештыра.

— Лирик герой кем? (Автор, Тукай.)

— Лирик геройның хисләре әсәрне ничә кисәккә бүлә? (Өч)

3) Укучылар өйдә төзеп килгән планга ачыклык кертелә:

а) лирик геройның пар атта Казанга килүе;

ә) геройның туган җире белән саубуллашуы;

б) лирик геройның Казанга килеп җитүе һәм шәһәр белән горурлануы.

***3. Уку мәсьәләсен кую***

Укытучы бүген дәрестә Габдулла Тукайның « Пар ат» шигырен өйрәнүне дәвам итәчәкләрен, лирик әсәрне аңларга, андагы хис-кичерешләрне тоярга өйрәнәчәкләрен әйтә.

**II. Уку мәсьәләсен өлешләп чишү**

1. Татарстан дәүләт фольклор ансамбленең «Пар ат» җыры видеоязмасын яки И.Шакиров башкаруында Г.Тукай сүзләренә язылган «Пар ат» җыры язмасын тыңлау, «автор артыннан бару». (Шигырьдә строфа арты строфаны күзәтергә, алардагы хисне

һәм аны тудырган сәбәпне ачыкларга ярдәм итә, хисләр көчешен тоярга, шул көчешкә салынган мәгънәне аңларга булыша.)

2. «Өзек «чылбырлап» укытылып барыла. Укытучы ярдәмендә һәр строфа анализлана.

— **Беренче кисәктә** лирик герой нинди хисләр кичерә, аның сәбәпләре нидә?

1 нче строфада — шатлык, рәхәтлек, тынычлык. Аның сәбәбе — лирик геройның Казанга юнәлүендә, пар атларда җилдерүендә.

*Җиктереп пар ат, Казанга туп-туры киттем карап,*
*Чаптыра атларны кучер, суккалап та тарткалап.*

2 нче строфада табигать матурлыгын сөйләү шул шатлыкка рәхәтлек төсмере бирә.

*Кич иде, шатлык белән нурлар чәчеп, ай ялтырый,*
*Искән әкрен җил белән яфрак, агачлар калтырый.*

3 нче строфада шатлык хисенә канәгатьләнү төсмере өстәлә, чөнки лирик герой күңелендәге тынычлык, рәхәтлек иң югары ноктасына җитә.

*Һәр тараф тын. Уй миңа тик әллә ни җырлый, укый,*
*Нәрсәдәндер күз эленгән һәм тәмам баскан йокы.*

— **Икенче кисәктә** лирик герой нинди хисләр кичерә?

4 нче строфада шатлык хисе кинәт үзгәрә, борчылу, сискәнү белән алмашына. Сәбәбе — яп-ят кыр уртасында калган лирик герой аерылудан борчыла башлый. Алдагы юлларда борчылу үсә, зурая.

*Берзаман ачсам күзем: бертөрле яп-ят кыр күрәм;*
*Аһ, бу нинди аерылу? Гомеремдә бер тапкыр күрәм.*

5 нче строфада лирик геройның торган җире, корган уйхыяллары белән саубуллашуы әлеге борчылуга кайгыруны өсти.

*Сау бул инде, хуш, бәхил бул, и минем торган җирем,*
*Мин болай, шулай итәм дип, төрле уй корган җирем.*

6 нчы строфада үкенү төсмере белән байый.

*Хуш, гомер иткән шәһәр, инде еракта калдыгыз,*
*Аһ, таныш йортлар, тәмам күздән дә сез югалдыгыз.*

Шушы борчылу эченә 7—8 нче строфаларда юану килеп керә, лирик герой кайгысыннан юану эзли.

*Эч поша, яна йөрәк, хәсрәт эчендә, уйда мин;*
*Ичмасам, иптәш тә юк ич, тик икәү без: уй да мин.*
*Аһ, гөнаһым шомлыгы, бу кучеры бик тын тагын,*
*Җырламыйдыр бер матурның балдагын я калфагын!*

9 нчы строфада хис яңадан дәвам итә, лирик геройның үз-үзен жәлләү, кызгану төсмере барлыкка килә.

*Әллә нәрсәм юк кеби, бер нәрсә юк, бер нәрсә ким;*
*Бар да бар, тик юк туганнар, мин ятим, монда ятим.*

10 нчы строфада тагын бер төсмер — зарлану төсмере килеп кушыла.

*Монда бар да ят миңа: бу Миңгали, Бикмулла кем?*
*Бикмөхәммәт, Биктимер — берсен дә белмим, әллә кем!*

11 нче строфада әлеге борчылу хисенә юксыну, сагыну өстәлә.

*Сездән аерылып, туганнар, җайсыз, уңайсыз тору;*
*Бу тору, әйтергә мөмкиндер, кояш, айсыз тору.*

Ә 12 нче строфада, үзенең иң биек ноктасына җитеп, борчылу хисе чарасызлык төсмере белән кушыла. Лирик геройның күз яшьләре шуңа ишарәли. Лирик геройда өмет хисе уяна.

*Шундый уйлар берлә囗таштай катты-китте башларым,*
*Чишмә төсле, ихтыярсыз акты-китте яшьләрем.*

— **Өченче кисәктә** лирик герой нинди хисләр кичерә?

13 нче строфада тагын хисләр үзгәрә. Кинәт кенә борчулар юкка чыга — шатлык хисе яңадан әйләнеп кайта. Сәбәбе — Казанга килеп җитү, якынаю.

*Бер тавыш килде колакка, яңгырады берзаман:*
*«Тор, шәкерт! Җиттек Казанга, алдыбызда бит — Казан!»*

14 нче строфада шатлыкка лирик геройның ашкынуы өстәлә.

*Бу тавыш бик ачты күңлем, шатлыгымнан җан яна:*
*«Әйдә, чап, кучер, Казанга! Атларың ку! На! На-на!*

Ул исә 15 нче строфада соклану төсмеренә алышына. Сәбәбе — Казанның матурлыгы, моңы, нуры.

*Әйтә иртәнге намазга бик матур, моңлы азан.*
*И Казан! Дәртле Казан! Моңлы Казан! Нурлы Казан!*

16 нчы строфада шатлык горурлану белән аралаша.

*Мондадыр безнең бабайлар түрләре, почмаклары,*
*Мондадыр дәртле күңелнең хурлары, оҗмахлары.*

Соңгы — 17 нче строфа өмет хисе белән тулы.

*Монда хикмәт, мәгърифәт һәм монда гыйрфан, монда нур,*
*Монда минем нечкә билем, җәннәтем һәм монда хур...*

3. Әсәрнең теленә игътибар итү.

1) Риторик эндәш яки сорау: «Аһ, бу нинди аерылу?»

2) Инверсия *(Шундый уйлар берлә таштай кайтты-китте башларым.)*

3) Шигырьдә нинди тасвир-сурәтләр (фразеологик әйтелмәләр) кулланылган?

(Хәсрәт эчендә янган йөрәк, эч пошу, чишмә төсле аккан күз яшьләре, таштай катып киткән баш һ.б.)

4) Лирик геройның моңсу эчке кичерешләре нинди табигать күренешләре аша тасвирлана?

(Нурлар чәчеп ялтыраучы ай, искән әкрен җил белән калтыраучы яфраклар һәм агачлар, яп-ят кыр.)

4. Сүзлек белән эш.

1) Укытучы сүзләрне укый, укучылар аның артыннан кабатлыйлар. Авыр сүзләрне аерым укучылардан кабатлаттыра.

2) Укытучы русчасын әйтә, укучылар тәрҗемәсен әйтәләр.

3) Укучылар чылбыр буенча яңа сүзләр белән сүзтезмәләр яки җөмләләр төзеп әйтәләр.

5. Габдулла Тукай исемендәге Дәүләт премиясе турында укучыларга мәгълүмат бирү:

1) дәреслекнең 65 нче битендәге белешмәне уку;

2) 66 нчы биттәге сорауларга җавап бирү.

**III. Рефлексив бәяләү**

1. Укучылар дәреслекнең 63 нче битендәге 10 нчы биремне эшлиләр. Бу бирем эшләнгәндә, шигырьнең эчтәлеге тулысынча яңадан кабатланырга тиеш.

2. Бәяләү. Укучыларга, дәрестә катнашканнары бәяләнеп, билгеләр куела.

3. Өй эше:

а) шигырьнең хикәяләп сөйләргә;

ә) Габдулла Тукайның «Пар ат» шигыренә Бакый Урманче иллюстрациясе буенча үзара фикер алышып, әңгәмә оештырырга әзерләнеп килергә;

б) китапның 63 нче битендәге 5, 6, 7 нче биремнәрне телдән эшләргә.

4. Алдагы дәрескә проблема кую.

Укытучы, дәресне тәмамлаганчы, йомгаклап, нәтиҗә ясар өчен сораулар бирә:

— Ни өчен кешегә туган җире кадерле? (Туган җир һәрбер кеше өчен берәү генә. Иң кадерле хатирәләр туган җир белән бәйле. Әти-әни белән туган җир янәшә тора.)

### Укытучы өчен өстәмә материал

Мәктәптә лирик әсәрне тикшерү, анализлау бик авыр. Анализ, гадәттә, һәрвакыт түбәндәге моментларга таяна: укучыларның шигырьдән алган тәэсирен ачыклау, әсәрдәге хисне һәм аның сәбәбен билгеләү, гомумиләштереп, лирик герой һәм аның кичереше турында нәтиҗәләр

ясау, шигырьнең теле, яңгырашы, ритм-рифмалары яки элементлары аша хиснең көчәйтелүен күзәтү.

Лирик әсәр анализлауның иң киң таралган юлы — «автор артыннан бару». Бу юл шигырьдәге строфа арты строфаны күзәтергә, алардагы хисне һәм аны тудырган сәбәпне ачыкларга ярдәм итә, хисләр күчешен тоярга, шул күчешкә салынган мәгънәне аңларга булыша.

Лирик әсәр анализлау, нигездә, урта сыйныфларда эзләнү яки тикшеренү ысулына мөрәҗәгать итә. Мәктәп анализында шигырьнең темасын — кичерешнең сәбәбе, ә идеясен хис-кичерешнең үзе, иң югары ноктасы белән бәйләп аңлату җиңел.

## 11 нче дәрес

**Тема:** Милли мәдәниятебезне үстерүдә Бакый Урманче иҗаты.

**Планлаштырылган нәтиҗәләр:**

М е т а п р е д м е т — сәнгать төрләренә мәхәббәт тәрбияләү, «триптих» сәнгать төшенчәсен аңлату.

П р е д м е т — укучыларны Бакый Урманченың тормыш юлы, эшчәнлеге һәм иҗат сәхифәләре белән таныштыру.

Ш ә х е с к ә к а г ы л ы ш л ы — балаларда татар халкының бөек шәхесләре, аларның иҗаты белән кызыксыну уяту; сирәк очрый торган талантка ия булган сынчы иҗаты белән горурлану хисләре тәрбияләү. Әхлак тәрбиясе бирү.

**Материал:** дәреслек (1 нче кисәк, 64—68 нче битләр).

**Җиһазлау:** Бакый Урманче портреты, Бакый Урманче әсәрләренең фотокүчермәләреннән күргәзмә (тормыш юлы, картиналары, сыннары, график эшләре), компьютер, проектор, экран, магнитофон, «Мәңгелек моң» кассетасы, укучыларның иҗади эшләреннән күргәзмә; «Бакый Урманченың рухи дөньясы» китабы, (Казан, 2005 ел), «Казан», «Мәгариф» журналлары.

**Эпиграф:**

Әй адәм, әүвәл мал җыясың комсызланып,
Аннары кол буласың шул малыңа;
Картаясың малыңа сакчы булып,
Барысын да калдырасың үзең үлеп.

*Бакый Урманче*

— Бу эпиграфта нәрсә турында язылган?

— Кеше байлык, мал җыяр өчен генә яшәргә тиеш түгел. Ул рухи байлыкка омтылырга тиеш. Рухи байлык — иң зур хәзинә. (Бу хакта русча да әйтергә кирәк.)

**Д ә р е с   б а р ы ш ы :**

**I. Мотивлаштыру-ориентлаштыру**

***1. Дәресне оештыру***

Дәресне башлау. Психологик уңай халәт тудыру.

***2. Актуальләштерү***

1) Өй эшен тикшерү: Габдулла Тукайның «Пар ат» шигыренә нәтиҗә ясау.

2) Габдулла Тукайның «Пар ат» әсәре буенча Бакый Урманче иҗат иткән иллюстрациягә укучыларның фикерләрен тыңлау. Укучылар дәреслектәге сорауларга җавап бирәләр (1 нче кисәк, 64 нче бит).

— Тукайга багышланган әдәбият-сәнгать әсәрләре туа икән, димәк, Тукай яши, аның үлмәс әсәрләре укучыларны үзенә җәлеп итә. Шуңа да Габдулла Тукай — татар халкының бөек шагыйре, ихтирамга ия заты.

Бүген Габдулла Тукай иҗатын үстерүдә күп көч куйган рәссамыбыз Бакый Урманче турында сөйләшербез. Алар гаиләсендә Г.Тукай исемендәге Дәүләт премиясенә ике кеше лаек була: Флора Әхмәтова-Урманче һәм Бакый ага үзе.

***3. Уку мәсьәләсен кую***

1) Бүгенге дәреснең темасы — милли мәдәниятебезне үстерүдә Бакый Урманче иҗаты. Темадан чыгып, дәрескә уку мәсьәләсен укучылар белән бергәләп кую.

2) Укучыларны Бакый Урманченың тормыш юлы, эшчәнлеге һәм иҗат сәхифәләре белән таныштыру.

— Бакый Урманченың тормыш юлы һәм иҗатына виртуаль экскурсия ясарбыз. Экскурсия ахырында сезне биремнәр көтә. Шуңа күрә игътибар белән тыңлагыз. Сәяхәтебезне без Казаннан башлыйбыз һәм Щапов урамында урнашкан Урманче музеена юл тотабыз.

**II. Уку мәсьәләсен өлешләп чишү**

1. Язучының иҗаты, тормыш юлы турында мәгълүмат.

1) Язучы турында презентация карау яки укытучының портрет, китапларын күрсәтеп сөйләве.

— Бакый Идрис улы Урманче — нәкыш остасы, сынчы, график һәм педагог. Ул — татар сынлы сәнгатенә нигез салучы. Бакый Урманче — Татарстанның һәм Россиянең халык рәссамы, республикабызның Габдулла Тукай исемендәге Дәүләт премиясе лауреаты.

Бакый Урманче тарихи шәхесләр, мәгърифәтчеләр, әдәбият һәм сәнгать вәкилләре, ялкынлы революционерларның скульптур портретларын иҗат итә. Аның 100дән артык скульптура әсәре, 300гә якын нәкыш картиналары, меңнәрчә графика әсәрләре бар.

Бакый Урманче эшләре Татарстанда һәм чит ил күргәзмәләрендә даими күрсәтелеп тора. Талантлы улын татар халкы онытмый. Республикада Бакый Урманче исемендәге премия булдырылды. 1997 нче елда башкалабызның Зур Кызыл урамындагы скверда мәшһүр сынчының бронза һәйкәле урын алды. Скульпторы — М.Гасыймов, архитекторы — Г.Бакулин. 1998 нче елда Казанда рәссамның музее ачылды. 2012 нче елда Мәскәүдә Третьяков галереясында Бакый Урманче күргәзмәсе оештырылды.

2) Дәреслектән Бакый Урманче иҗатын уку. Укытучының сәнгатьле укуы, укучылар, күз йөртеп, карап баралар, тыңлыйлар. Сорауларга җавап бирәләр.

— Рәссам кем ул? Рәссамнардан кемнәрне беләсез?

— Бакый Урманче ул кем? Сез аның турында ишеткәнегез бар идеме?

— Рәссам нинди зур шәхесләрнең скульптур портретларын ясаган?

3) Сүзлекчәне кулланып, авыр сүзләрне русчага тәрҗемә итү.

2. Бакый Урманче музеена виртуаль экскурсия.

Бүген монда — Бакый күргәзмәсе,
Бүген монда хуҗа — Урманче.
Йөрдем олы сәнгать дөньясында,
Йөрдем тәмам күңел булганчы.

— Хәзер танышуыбызны дәвам итеп, компьютерда слайдлар карап үтәрбез. (Укытучы комментарий ясап бара.)

1) Рәсемдә Казандагы Бакый Урманче музеен күрәсез. Ул Казанда Щапов урамында 20 нче йортта урнашкан.

2) Б.Урманче вестибюле.

3) Б.Урманче музеенда скульптура залы.

4) Б.Урманче музеенда нәкыш залы.

5) Музейда этнографик күренешләр.

6) «Печән базары» картинасы.

7) Г.Казанцева (җырчы).

8) «Сепаратор янында».

9) Кырлайда Тукайның мемориаль музее.

10) Ш.Мәрҗани.

11) Г.Ибрагимов (язучы).

12) М.Гафури.

13) С.Сәйдәшев.

14) Ф.Әмирхан.

15) Ф.Әхмәтова-Урманче.

16) Бакый Урманче үзенең автопортретын да язган. Ул портретларны буяу һәм график юл белән эшләгән.

(Графика — буяусыз, сызыклар һәм штрихлар белән генә рәсем ясау дигән сүз.)

17) Г.Тукай һәйкәле (бронзадан эшләнгән).

18) Г.Тукай бюсты (бронзобетон).

19) Ш.Мәрҗани (гипс).

20) Дәрдемәнд (мәрмәрдән эшләнгән ярымфигура).

21) Шәмаил (экранга шәмаилләр турында язу чыга). Мөселман динен тотучыларда изге дип саналган урыннарның рәсеме төшерелә, матурлап догалар языла һәм стенага элү өчен рамга куела (русча да әйтергә кирәк). Менә бу «Туган тел» җырының шәмаиле. Җырның бер куплеты тыңлана, балалар кушылып җырлый алалар.

22) Бакый Урманченың китапханәсе дә бай булган. Анда меңләгән китап саклана.

3. Дәреслектән Бакый Урманче музее турында уку. Укучылар парлап эшлиләр, диалоглар төзиләр.

— Укучылар, сезгә музей ошадымы?

— Музейның адресы ничек?

— Иң зур картинасы ничек атала?

— Бакый Урманче кемнәрнең сыннарын ясаган? (Г.Тукай, Н.Исәнбәт, Ф.Әмирхан, Дәрдемәнд, Г.Ибрагимов, М.Җәлил, Г.Камал.)

4. «Триптих» сәнгать төшенчәсен аңлату. Укучылар дәреслекнең 68 нче битеннән аңлатманы укыйлар. «Татарстан» триптихы турында әңгәмә.

**III. Рефлексив бәяләү**

1. — Дәрескә куелган уку мәсьәләсе чишелдеме?

— Бакый Урманче турында нәрсәләр белдегез?

— Укучылар, без бүген дәрестә нинди зур шәхес турында сөйләштек? Ул кем булган?

— Бакый Урманче нәрсәләр иҗат иткән?

2. Дәрескә гомуми бәя. Укучыларга билге кую.

3. Өй эше: а) Б.Урманченың тормыш юлы һәм иҗаты турында белергә;

ә) «Татарстан» триптихы турында сөйләргә әзерләнеп килергә;

б) Б.Урманченың үзеңә ошаган бер картинасы турында сөйләргә өйрәнергә.

**Тест**

1. Б. Урманче ничәнче елда туган?
а) 1890; б) 1897;
ә) 1894; в) 1900.
2. Кайсы районда туган?
а) Буа; б) Алексеевск;
ә) Чистай; в) Аксубай.
3. Иң зур картинасы ничек атала?
а) «Сабантуй»; б) «Семипалатинск»;
ә) «Татарстан»; в) «Башкорт йорты».
4. Б.Урманче музее кайсы урамда урнашкан?
а) Г.Тукай; б) М.Җәлил;
ә) А.Щапов; в) А.Пушкин.
5. Бакый Урманче музее Казанда ничәнче елда ачыла?
а) 1998; б) 2000;
ә) 1999; в) 2001.

**Укытучы өчен өстәмә материал**

Нәкый Исәнбәт: «Яңа татар поэзиясенә һәм татар музыкасына нигез салучылар Тукай һәм Сәйдәш булса, татар сурәтчелек сәнгатенең нигез салучысы кем, дигәндә, Бакый ага Урманче, дип, хаклы рәвештә әйтә алабыз», — дип язган иде.

Бакый Урманче — җитмеш елдан артык гомерен сынлы сәнгатькә багышлаган һәм үз иҗатында, татар халкының рухи дөньясын күрсәтү белән генә чикләнмичә, бәлки әле башкорт, рус, казах, үзбәк, уйгур, карел һ.б. халыклар тормышын да киң һәм тирән итеп тасвирлаган зур оста.

Аның иҗат киңлеге монументаль нәкыш, скульптура, гамәли-декоратив сәнгать, графика, театраль-декоратив сәнгать, рәсем, гравюра, иллюстрация сәнгатен үз эченә ала.

Бакый Урманче музыкага да бик хирыс булган. Җырларга яраткан. Шигырьләр язган, борынгы кулъязма әсәрләргә оста текстологик анализ ясаган. Университет студентларына гарәп каллиграфиясен өйрәткән.

Чит телләрне дә әйбәт белгәнгә, Абай һәм Сәгъди, Байрон һәм Гёте, Хәйям һәм Хикмәтләрне оригиналда укыган, шактый шигырьләрен яттан белгән.

Әмма Бакый Урманчега, сынлы сәнгать белән чынлап торып шөгыльләнә башлаганчы, зур тормыш мәктәбен үтәргә туры килә. 1914 нче

елда, бәхет эзләп, Урал, Донбасс якларына чыгып китә. Тамбов якларында мөгаллимлек итә. Беренче бөтендөнья сугышы елларында армиягә алынып, Казахстанда хезмәт итә. Анда Бакый рәсем ясау буенча тәүге сабагын ала.

1919 нче елда 22 яшьлек Бакый Казан сәнгать мәктәбенә укырга керә. Әлеге мәктәпнең беренче татар студенты була ул.

1920 нче елны ВХУТЕМАСта укый башлый.

1933 — 1941 нче елларда, Бакый Урманче Мәскәүдә яши һәм эшли. Аның эшләре 1934 нче елда беренче тапкыр яшь рәссамнарның Бөтенсоюз күргәзмәсенә куела һәм югары бәя ала. 1937 нче елда Мәскәүдәге Совет рәссамнары берлегенә әгъза итеп алына. 1937—1941 нче елларда Бөтенсоюз авыл хуҗалыгы күргәзмәсендә эшли. 1941—1949 нчы елларда, Алма-Ата һәм Семипалатинск шәһәрләрендә административ сөргендә вакытта казах шагыйрьләре һәм язучылары Абай, М.Ауэзов, С.Муханов әсәрләренә иллюстрацияләр, график серияләр, Тукайның казах теленә тәрҗемә ителгән шигырьләренә, Казахстанның тарихына, көнкүрешенә һәм сәнгать әһелләренә багышланган нәкыш әсәрләре иҗат итә.

1949—1958 нче елларда Үзбәкстанда яши, Урта Азия табигатенә бәйле нәкыш һәм график портретлар, тематик картиналар, пейзаж, эпизодлар яза. Ташкент театр сәнгать институтында эшли, анда сын сәнгате бүлеген оештыра.

Б.Урманче, рәссам буларак, үз эшчәнлеген графика өлкәсеннән башлаган. Ул тушь, акварель, каләм, каурый белән эшләргә яраткан. Борынгы кытай стилен дә кулланган.

Графика өлкәсендәге эзләнүләре рәссамны сәнгатьнең тагын бер төре — шәмаилләргә алып килә.

Б.Урманченың иң зур картинасы «Татарстан» дип атала. Ул өч полотнодан тора. Берсендә борынгы һәйкәлләр һәм Болгар иленең башкаласы тасвирлана. Икенчесендә православие монастыре белән Зөя сурәтләнә. Үзәк полотнода — «Сөембикә» манарасы белән Казан. Алар янәшә торганда, бердәм эчтәлекле композиция тәшкил итәләр.

Бакый Урманченың үз куллары белән ясалган һәйкәлләре шәһәр һәм авыл мәйданнарын, урамнарын бизи. Бакый ага татар зыялыларының портретларын эшләүгә күп көч куйган. Мәсәлән, Урта гасыр шагыйре Кол Гали образын тудыру өчен, Бакый Урманче бик күп әсәрләр укыган, тарихи эзләнүләр үткәргән. Мәгърифәтчеләр Шиһабетдин Мәрҗани, Каюм Насыйри, шагыйрьләр Дәрдемәнд, Муса Җәлил, Габдулла Тукай һ.б. портретларын иҗат иткән.

Урманченың яраткан эш материалларының берсе агач булган. Мәсәлән, юкәдән ясалган Сөембикә портреты. Аңа карап, Казан ханбикәсенең үз халкы өчен кайгыруын, эчке кичерешләрен күрәбез.

Пластика өлкәсендә иң уңышлы эшләренең берсе «Язгы моң» дип атала.

Бакый аганың тагын бер танылган эше «Уйлану» дип атала. Бу олы яшьтәге кешенең йөзендә эчке дөньясы, аның көче күренә. Бу эшне еш кына Бакый Урманченың «психологик автопортреты» дип атыйлар.

Арча районының Яңа Кырлай авылында сынчы Г.Тукайның архитектур-мемориаль комплексын ясый. Музей каршында кунакларны каршы алучы Тукай һәйкәленең авторы да — Бакый Урманче.

Бакый Урманче 1990 нчы елның 6 августында 93 яшендә вафат була. Бөек оста Казанның Яңа Бистә зиратына җирләнгән.

## 12—13 нче дәресләр

**Тема:** Нәҗәр Нәҗми — Тукай шәкерте.

**Планлаштырылган нәтиҗәләр:**

Метапредмет — «тел», «халык», «тарих» төшенчәләрен аңлауга ирешү.

Предмет — Нәҗәр Нәҗминең тормыш юлы һәм иҗаты турында белешмә бирү, «Агыйделдә — ак пароход» әсәрен өйрәнү.

Шәхескә кагылышлы — укучыларда милли үзаң тәрбияләү, туган телгә, милли тарихка ихтирам хисе уяту.

**Материал:** дәреслек (1 нче кисәк, 69—71 нче битләр).

**Җиһазлау:** мультимедиа проекторы, экран, слайдлар: Нәҗәр Нәҗминең портреты, шигырьләре, Нәҗәр Нәҗми сүзләренә язылган җырлар.

### Дәрес барышы:

**I. Мотивлаштыру-ориентлаштыру**

***1. Дәресне оештыру***

Исәнләшү, хәлләр сорашу, яхшы кәеф теләп, дәресне башлау.

Психологик уңай халәт булдыру.

***2. Актуальләштерү***

1) Алдагы дәрестә бирелгән өй эшен тикшерү.

2) Укытучы, юнәлдерүче сораулар биреп, Бакый Урманче иҗаты турында әңгәмә оештыра.

— Рәссамның иң зур картинасы ничек атала?

— Ул ничә полотнодан тора?

— 1 нче төркем үзәк полотно турында сөйли.

— 2 нче төркем беренче полотно турында сөйли.

— 3 нче төркем икенче полотно турында сөйли.

Укучылар Бакый Урманче иҗат иткән тарихи шәхесләр турында сөйлиләр.

Без бүген Тукай иҗатын олылаган язучыбыз Наҗар Нәҗми иҗаты белән танышырбыз. Гүя Тукайның уй-фикерләре, еллар аша килеп, хәзерге татар-башкорт әдәбияты аксакалы Наҗар Нәҗми иҗатында кайтаваз булып яңгырый.

***3. Уку мәсьәләсен кую***

Укытучы бүген дәрестә Наҗар Нәҗми иҗаты белән танышачакларын һәм «Агыйделдә — ак пароход» әсәрен өйрәнәчәкләрен әйтә.

**II. Уку мәсьәләсен өлешләп чишү**

1. Автор белән танышу.

1) Укытучы, шагыйрьнең шигырьләрен, китапларын күрсәтеп, тормышы һәм иҗаты белән таныштыра.

2) Бер укучы дәреслектән Наҗар Нәҗми турында белешмәне укый.

3) Укытучы, сораулар ярдәмендә, укучыларның аңлавын тикшерә.

— Наҗар Нәҗми кайсы төбәктә туган?

— Нинди уку йортын тәмамлаган?

— Язучының нинди бүләкләре бар?

— Наҗар Нәҗмине кайсы халыклар үзенеке дип саный?

— Ул кем иҗатын үстергән?

— Телгә багышланган нинди шигырь иҗат иткән?

— Кайсы язучының тел турында шигыре бар?

(Габдулла Тукайның «Туган тел» шигырен балалардан хор белән сөйләтергә. Укытучы Наҗар Нәҗминең «Татар теле» шигырен яттан сөйләп күрсәтә.)

2. Сүзлек белән эш.

1) Укытучы сүзләрне укый, укучылар аның артыннан кабатлыйлар. Авыр сүзләрне аерым укучылардан кабатлаттыра.

2) Укытучы русчасын әйтә, укучылар тәрҗемәсен әйтәләр.

3) Укучылар чылбыр буенча яңа сүзләр белән сүзтезмәләр яки җөмләләр төзеп әйтәләр.

3. «Агыйделдә — ак пароход» әсәрен чылбыр буенча уку.

1) Яңа текстны укырга әзерләү: сүзлекчә белән эшләү (дөрес әйтелешне тыңлау, кабатлау, тәрҗемә итү — башта үзләре уйлаганча, аннары дөреслеген тикшерәләр яки тәрҗемәсен китаптан карыйлар).

2) Яңа текстны тыңлау (тәрҗемәсез, анализсыз гына).

— Текстта нәрсә турында сүз бара?

3) Һәр абзацны уку, эчтәлекне аңлаганны тикшерү өчен, гади сораулар бирү. Үз фикерләрен әйткәндә, башта русча әйтергә

мөмкин, аннары татарча сөйлиләр. Укучылар, берничә төркемгә бүленеп, текстка сораулар төзиләр.

— Алар кая сәяхәт итәләр?

— Ни өчен сәяхәт аклыктан тора? (Китаптан табып укысыннар.)

— Сәфәрләре озакка сузыламы?

— Сәяхәтнең кульминацион өлешен табып укыгыз.

— Алар арасында нинди сөйләшү була?

— Сөйләшүнең темасы нинди?

— «Түгәрәк өстәл»дә кемнәр катнашкан?

— Аларның фикерләрен тексттан табып укыгыз.

— Наҗар Нәҗми нәрсәгә өметен өзгән?

— Сәфәр кем иҗатына багышланган була?

— Авторга нинди сорау биргәннәр? Җавапны китаптан табып укыгыз.

— Әмирхан Еникиның очрашуда әйткән сүзен тексттан табып укыгыз.

— Ул нинди фикер әйтә?

— Аны кем раслый?

— Ул нинди милләттән?

— Кем булып эшли?

— Ул егет кайда туган?

— Ни өчен әсәр «Агыйделдә — ак пароход» дип атала?

Көчлерәк төркемнәрдә укытучы үзе телдән тагын охшаш биремнәр әзерләсә отышлы булыр. Дәресләрдә телдән күп эшләнсә, укучылар, мәҗбүри бирем булмаса да, гади җөмләләр белән, укылган әсәрнең (бүлекнең) кыскача эчтәлеген сөйли алалар.

4. «Урамдагы бозылган һаваны яулык болгап куу» фразеологизмын уку, тәрҗемә итү, аңлауга ирешү.

— «Тере классик остаз» сүзләрен ничек аңлыйсыз?

**III. Рефлексив бәяләү**

1. — Дәрескә куелган уку мәсьәләсе чишелдеме? Һәр дәрес башында куелган уку мәсьәләсе үтәлдеме, максатка ирештекме — йомгак ясыйбыз.

— Ни өчен әсәр «Агыйделдә — ак пароход» дип атала? Нинди ике аклык турында сүз бара?

2. Дәрескә гомуми бәя. Укучыларга билге кую.

3. Өй эше. Укучыларга проект эшләре тәкъдим ителә:

а) «Казанның тарихи урыннары»;

ә) «Минем урамымның тарихы»;

б) Бауман урамындагы йолдызлар аллеясында кайсы җырчы-

ларга йолдызлы ташлар куелган? Үзеңә ошаган артист турында сөйләргә (Илһам Шакиров һ.б.)

4. Алдагы дәрескә проблема кую.

Укытучы, дәресне тәмамлаганчы, йомгаклап, нәтиҗә ясау өчен сораулар бирә:

— Ни өчен Наҗар Нәҗмине «Тукай шәкерте» дип әйтәбез?

— Әсәрдә хәзерге көндә актуаль булган нинди мәсьәлә күтәрелә? Сез язучы фикере белән килешәсезме?

### Укытучы өчен өстәмә материал

Наҗар Нәҗми — М.Акмулла, Г.Чокрый, Г.Ибраһимов, Ш.Бабич, М.Гафурилар башлап җибәргән ике тугандаш халыкның мәдәни һәм әдәби диалогын дәвам итүче һәм үстерүче. Наҗар Нәҗми йогынтысында татар һәм башкорт әдәбиятларында шактый талантлар иҗат юлына чыкты. Алар арасында Р.Миңнуллин, Р.Гаташ, Г.Садә, М.Нәзиров, Р.Идиятуллин, Х.Мөдәррисова кебек бүгенге көн сүз сәнгатенең йөзен билгеләүче язучыларны атарга мөмкин. 1993 нче елда Башкортстанның халык шагыйре исеменә лаек булган Наҗар Нәҗминең иҗаты тулы бәяләнә: ул — күпсанлы премияләр лауреаты; аның әсәрләре меңләгән тираж белән кат-кат нәшер ителә; даими рәвештә аның тормыш юлын һәм иҗатын өйрәнүгә багышланган фәнни җыеннар уздырыла; шагыйрьнең кече ватаны Дүртөйле районында дистә елдан артык әдипнең музее эшли; район үзәгендә һәм Уфада Наҗар Нәҗми исемен йөрткән урамнар бар. Наҗар Нәҗминең шигъри таланты башкорт әдәбиятының гына түгел, татар сүз сәнгатенең дә көчле йогынтысында формалаша һәм үсә. Ул озак еллар дәвамында «Казан утлары» журналының редколлегиясе әгъзасы булды, татар әдәбиятын үстерүдәге хезмәтләре өчен, Татарстан Язучылар берлегенең Гаяз Исхакый исемендәге премиясенә лаек дип табылды.

Беренче иҗади уңыш Наҗар Нәҗмигә 1937 нче елда килә. Ул, Уфаның «Востоксталь» рабфагында укыган чагында, шигырь конкурсында катнаша һәм анда «Троцкий — халык дошманы» дигән шигыре белән чыгыш ясый (кызганычка, бу шигырьнең тексты сакланмаган). Бу көн — Наҗар Нәҗминең зур шигърият дөньясына кергән көне! Беренче бүләкне алганда, ул җавап сүзе итеп ни әйтергә белми, бары, русчалап: «Шагыйрь булырга йөкләмә алам!» — дигәнен генә хәтерли.

1930 нчы елларда аның иҗатында туган авылны сагыну мотивы өстенлек итә («Беренче җыр» (1938), «Икенче җыр» (1939) альманахларында, «Октябрь» (1940) журналы битләрендә урын алган әсәрләре, «Шатлан, ана!» (1937), «Авырсынма» (1939), «Кышкы юл», «Саумы, авылым» (1940) һ.б. шигырьләре).

1945 — 1955 нче елларда Наҗар Нәҗми шигърияте «конфликтсызлык теориясе»нең йогынтысы астында үсә. Бөек Ватан сугышы хатирәләренең әледән-әле яңарып торуы — шагыйрьнең бу чор иҗатында сугыш тематикасы өстенлек итүенең төп сәбәбе. Шагыйрь лирик геройның эмоциональ дөньясын тирәнрәк һәм объективрак сурәтләргә омтыла («Кайту» циклы, «Котелогым» (1948). Сугыштан соңгы еллар Наҗар Нәҗми иҗатында лиро-эпик әсәрләр язылуы белән дә игътибарга лаек («Ана» (1948), «Капкалар» (1955—1960) поэмалары; «Тау һәм диңгез» (1948), «Ике елга» (1948), «Мин кайтып киләм туйдан» (1949), «Тар сукмак буйлап» (1953) балладалары). Аның тыныч тормыш романтикасы белән сугарылган шигъри әсәрләре беренче мәртәбә рус теленә тәрҗемә ителә. Бу елларда Наҗар Нәҗми Алишер Нәвоиның «Фәрхад һәм Ширин» поэмасын, М.Лермонтов, А.Пушкин, Н.Некрасов, Р.Рождественский, Р.Гамзатов, К.Кулиев һ.б. шагыйрьләрнең әсәрләрен тәрҗемә итә. 1950 нче еллар ахыры — 1980 нче еллар башы — Наҗар Нәҗми иҗатының иң «җимешле» чоры. Бу вакыт аралыгында аның 24 шигырь җыентыгы, 4 мемуар һәм публицистика әсәрләрен берләштергән китаплары, 3 сәхнә әсәрләре тупламасы дөнья күрә.

1970 — 1980 нче елларда Наҗар Нәҗми җыр жанрына актив мөрәҗәгать итә. 1950 нче елларда ук Наҗар Нәҗминең «Котелогым», «Таулар җыры» җырлары концерт-тамашаларда еш яңгырый. Шагыйрьнең композитор Рим Хәсәнов һәм җырчылар Фәридә Кудашева, Фидан Гафаров, Нәзифә Кадыйрова, Асия һәм Илфак Смаковлар белән хезмәттәшлеге татар-башкорт эстрадасы мирасын баеткан «Уфа юкәләре», «Юкка түгел, юкка түгелдер», «Юллар, юллар...», «Бу дөньядан синсез китмимен мин...» һ.б. җырлар иҗат итүгә китерә. Шагыйрьнең 30дан артык җыры һаман да тамашачылар арасында популяр булып кала бирә. 1977 — 1978 нче еллар аралыгында дөнья күргән өч томлык «Әсәрләр» җыентыгы Наҗар Нәҗмине әдәбият классиклары сафына кертә. «Тарафлар» («Стороны») җыентыгы өчен, 1982 нче елда Наҗар Нәҗмигә РСФСРның Максим Горький исемендәге Дәүләт премиясе бирелә.

Нәҗми Татарстан Язучылар берлегенең Гаяз Исхакый исемендәге премиясенә һәм Башкортстанның Салават Юлаев исемендәге Дәүләт бүләгенә лаек була. Наҗар Нәҗминең 1980 нче еллар ахыры — 1990 нчы еллар иҗатында мәрсия, элегия жанрлары җанлана. Аның соңгы «Ак чишмә» (1997) җыентыгына кергән «Рөстәм Яхин истәлегенә» (1993), «Телләр» (Рәшит Әхмәтҗановка, 1995), «Зәки Вәлиди кабере янында» (1995), «Сибгат Хәким истәлегенә» (1996) багышлаулары да, үз вакытында Татарстан гимны булуга дәгъва иткән «Татар теле» шигыре дә (Р.Яхин көе, 1966), башка бик күп әсәрләре һәм чыгышлары да шул хакта сөйли.

## 13 нче дәрес — кабатлау дәресе

**Тема:** Үзенең үткәнен онытткан халыкның киләчәге юк (бәйләнешле сөйләм үстерү).

**Планлаштырылган нәтиҗәләр:** бу бүлектә укылган әсәрләрне, теоретик төшенчәләрне истә калдыру; әсәрләрдә күтәрелә торган проблема — туган җирне ярату, туган як кадере, милләт язмышы, чит илләрдәге милләттәшләребез турында аңлап калу; туган җиргә, милләттәшләребезгә ихтирам хисләре тәрбияләү.

**Дәресне оештыру вариантлары:**

1) Һәр әсәрнең эчтәлеген бергәләп искә төшерү, язучының әйтергә теләгән фикерен ассызыклап үтү.

2) Укучыларның проектларны яклавы — төп фикерне ачу, алдан әзерләнеп чыгыш ясавы.

3) Бу бүлектә өйрәнгән әсәрләрнең бер-берсе белән бәйләнешен ачыклау. Һәркайсының бүлекнең төп темасын ничек ачуын күрсәтү.

4) Төркемнәргә бүленеп, викторина, ярыш, ТЗК формасында, әсәрләрне үзләштерү дәрәҗәләрен билгеләү.

## 14 нче дәрес

**Тема:** Билгесез биеклектә.

**Планлаштырылган нәтиҗәләр:**

М е т а п р е д м е т — Бөек Ватан сугышы чоры турында белемнәрне яңарту.

П р е д м е т — Рәссам Виктор Куделькиннның тормыш юлы, иҗаты турында мәгълүмат бирү, Гариф Ахуновның «Замандашлар портреты»н уку.

Ш ә х е с к ә  к а г ы л ы ш л ы — сугыш авырлыгын үз җилкәләрендә күтәргән яшь буынга, шул чор кешеләренә ихтирам тәрбияләү.

**Материал:** дәреслек (74—76 нчы битләр).

**Җиһазлау:** компьютер, проектр, электрон презентация, В.Куделькин портреты, рәсемнәре.

## Дәрес барышы:

**I. Мотивлаштыру-ориентлаштыру**

***1. Дәресне оештыру***

Дәресне башлау. Психологик уңай халәт тудыру.

***2. Актуальләштерү***

Укучыларга өстәмә уку өчен бирелгән әсәрләр буенча фикер алышу.

— Ни өчен тарихны белү кирәк?

— Шиһабетдин Мәрҗани әйткән сүзләрне ничек аңлыйсыз?

— Сәяхәтчеләрдән кемнәрне беләсез?

— Алар тарихи яктан нинди мөһим эш башкаралар?

— Бөек Ватан сугышының тарихтагы эзе, бабаларыбызның Җиңүгә омтылышы — тыныч тормышта яшәүгә этәрүче көч.

***3. Уку мәсьәләсен кую***

— Бүгенге дәреснең темасы — Гариф Ахуновның «Замандашлар портреты» аша рәссам Виктор Кудельkinнның иҗатын өйрәнү. Виктор Кудельkinнның «Билгесез биеклектә» картинасы буенча эш.

Темадан чыгып, дәрескә уку мәсьәләсен укучылар белән бергәләп кую.

1) Гариф Ахуновның «Замандашлар портреты» аша Виктор Кудельkin иҗаты белән танышу.

2) Виктор Кудельkinнның «Билгесез биеклектә» картинасы белән эш.

**II. Уку мәсьәләсен өлешләп чишү**

1. Бөек Ватан сугышы чоры турында мәгълүмат бирү.

2. Виктор Кудельkinнның тормыш юлы, иҗаты турында укытучы сөйләве. Презентация, картиналары.

3. «Билгесез биеклектә» (На безымянной высоте») дип исемләнгән, М.Матусовский сүзләренә язылган җырны Интернет челтәреннән табып тыңлау һәм фикер алышу.

4. Гариф Ахуновның «Замандашлар портреты»н чылбыр буенча уку. Өзекне өч өлешкә бүлү. Гариф Ахунов турында белешмә биреп китү.

1) Беренче өлеш: эчтәлек буенча сорау — җавап.

— Автор кем белән очраша?

— Рәссам кемнәрнең портретларын күрсәтә?

— Виктор Ивановичның табигать турында картиналары исемен атагыз.

— Картиналарының исемнәрен рус теленә тәрҗемә итегез.

5. Парларда эшләү:

1) I нче төркем 2 нче өлешне укый, сораулар әзерли. Аларга Виктор Куделькинның «Билгесез биеклектә» картинасы бирелә.

— Картинада нинди тема сурәтләнгән?

— Сез анда кемне күрәсез?

— Ул кайда басып тора?

— Аңа ничә яшь?

— Ул билгесез биеклеккә нәрсәләр китергән?

— Виктор Иванович Куделькин сюжет-композицияне кайдан ала?

— Рәссам нинди төсләрне, тоннарны кулланган һәм ни өчен?

— Картинаның исеме — «Билгесез биеклектә». Ни өчен шулай аталган дип уйлыйсыз? Сез нинди исем бирер идегез?

2) II нче төркем 3 нче өлешне укый, сораулар әзерли. Аларга Муса Җәлилгә багышланган «Политрук шигырьләре» картинасы бирелә.

— Картинада нинди тема сурәтләнгән?

— Җәлил образын тудыру өчен, рәссам нинди эзләнү эшләре алып бара?

— «Политрук шигырьләре» турындагы картинада Җәлил ничек сурәтләнгән?

— Картинада Җәлил кемнәр уртасында басып тора?

— Рәссам нинди төсләрне, тоннарны кулланган?

— Картинаның исеме — «Политрук шигырьләре». Ни өчен шулай аталган дип уйлыйсыз? Сез нинди исем бирер идегез?

6. Дәреслектәге 3, 5 нче биремнәрне эшләү.

— Виктор Куделькин кайсы күренекле шәхесләрнең портретларын иҗат иткән? Тексттан табып, дәфтәрегезгә языгыз.

Укытучы рәссам иҗат иткән башка күренекле шәхесләрнең дә исемен яздыра: Габдулла Тукай — язучы; Байназар Әлменов — художник; Нәкый Исәнбәт — татар драматургы; Диас Вәлиев — язучы; Әбүбәкер Терегулов — медицина институтының профессоры; Мөнирә Булатова — ТАССРның халык артисткасы; Әмирхан Еники — язучы; Садри Ахун — скульптор.

**III. Рефлексив бәяләү**

1. — Дәрескә куелган уку мәсьәләсе чишелдеме? В.И.Куделькинның тормыш юлы, иҗаты турында ниләр белдегез? Аның нинди картиналары бар? Ул нинди темаларга иҗат иткән?

2. Дәрескә гомуми бәя. Укучыларга билге кую.

3. Өй эше: а) Гариф Ахуновның «Замандашлар портреты»н сәнгатьле укырга;

ә) 76 нчы биттәге 6 нчы биремне үтәргә;

б) В.И.Куделькинның үзеңә ошаган картинасын сөйләргә өйрәнергә.

## Укытучы өчен өстәмә материал

Куделькин Виктор Иванович 1911 нче елның 9 нчы ноябрендә Симбирия губернасы Алатырь шәһәре янындагы Кудьма исемле, зур булмаган тимер юл станциясендә тимер юлчылар гаиләсендә туа. Ул үзенең иҗат юлын Алатырь шәһәрендә декорацияләүче һәм сәнгать түгәрәгенең җитәкчесе булып башлый.

1934 нче елда Алатырь шәһәренең сәнгать училищесына укырга керә. Укуын тәмамлагач, белемен күтәрергә Мәскәүгә — В.Бакшеев җитәкчелегендәге курсларга китә. Анда ул 2 ел белем ала.

1940 нчы елда Казанга күчеп кайта һәм «Локомотив» газета редакциясендә график булып эшли, сәнгать белән шөгыльләнә башлый. 1941 нче елның башында Виктор РСФСРның яшь рәссамнары күргәзмәсендә катнаша. Күргәзмәдәге «Казан урамнары» картинасы һәм татар кызы портреты игътибарны җәлеп итмичә калмый, һәм аны Совет рәссамнары союзына алалар.

1940 — 1941 нче елларда халык иҗат йортында рәссам-методист булып эшли. Интенсив рәвештә башланган иҗат юлын Бөек Ватан сугышы озак елларга бүлә. Виктор Куделькин 1941 нче елның 28 нче июленнән сугышка китә, 2 нче Белорусия фронтында көрәшә.

Туган якларына әйләнеп кайткач, 1946 нчы елда, ул Казан шәһәренең сәнгать училищесына эшкә урнаша. Виктор Иванович җанлы сәнгать, графика, композиция предметларыннан белем бирә. Шул ук елны училищеның директоры итеп билгеләнә.

### На безымянной высоте

*слова М.Матусовского*
*музыка В. Баснера*

Дымилась роща под горою,
И вместе с ней горел закат...
Нас оставалось только трое
Из восемнадцати ребят.
Как много их, друзей хороших,
Лежать осталось в темноте —
У незнакомого посёлка
На безымянной высоте.

Светилась, падая, ракета,
Как догоревшая звезда...
Кто хоть однажды видел это,
Тот не забудет никогда.
Он не забудет, не забудет
Атаки яростные те —
У незнакомого посёлка
На безымянной высоте.

Над нами «мессеры» кружили,
И было видно, словно днём...
Но только крепче мы дружили
Под перекрёстным артогнём.
И как бы трудно ни бывало,
Ты верен был своей мечте —
У незнакомого посёлка
На безымянной высоте.

Мне часто снятся все ребята,
Друзья моих военных дней.
Землянка наша в три наката,
Сосна сгоревшая над ней.
Как будто вновь я вместе с ними
Стою на огненной черте —
У незнакомого посёлка
На безымянной высоте.

**Гариф Ахунов**
(1925 — 2000)

Прозаик, драматург, публицист һәм күренекле җәмәгать эшлеклесе Гариф Ахунов (Гарифҗан Ахунҗан улы Ахунов) 1925 нче елның 18 нче сентябрендә Татарстанның Арча районы Өчиле авылында туа. Күрше Казанбаш авылы мәктәбендә җиде сыйныф белем алганнан соң, Гариф Арча педагогия училищесында укый. Аннары, Казанга килеп, университетның татар теле һәм әдәбияты бүлегенә укырга керә.

1951 нче елда «Үсү юлы» альманахында яшь авторның «Галләм сорау бирә» исемле тәүге хикәясе басылып чыга. «Совет әдәбияты» (хәзерге «Казан утлары») журналында әдәби хезмәткәр, проза бүлеге мөдире һәм журналның җаваплы сәркатибе вазифаларын башкара. Бу елларда ул күп кенә хикәяләрен, беренче күләмле әсәре булган «Яшьлек яме» (1955) повестен иҗат итә. И.Гази, Г.Әпсәләмов, Ә.Давыдов,

Г.Бәширов, Ш.Маннур, С.Баттал кебек танылган язучылар турында әдәби-тәнкыйть мәкаләләрен һәм иҗат портретларын бастыра. 1956 нчы елның көзендә Гариф Ахунов республиканың нефть үзәге Әлмәт шәһәренә күчеп китеп, ун елдан артык нефтьчеләр арасында яши. Шул җанлы тормыш материалы нигезендә, күпсанлы очерклар, публицистик мәкаләләр, хикәяләр, кечкенә повестьларын яза (җыентыклар: «Еллар чатында», 1959; «Хыялый Хәйрүш егетләре», 1965; повестьлар: «Артышлы тау буенда», 1960; «Канатлар кая илтә?», 1967), аннары зур күләмле әдәби әсәрләреннән «Хәзинә» (1963) һәм «Хуҗалар» (1968) исемле романнарын иҗат итә.

Г.Ахунов 1968 нче елда Казанга кайта. 1972 — 1974 нче елларда ул «Казан утлары» журналының баш мөхәррире булып эшли. 1974 нче елда Татарстан Язучылар берлеге идарәсенең рәисе итеп сайлана. 1974 — 1984 елларда ул шулай ук СССР Югары Советында Татарстаннан сайланган депутат вазифаларын башкара.

1978, 1986 нчы елларда әдипнең өч кисәкле роман итеп уйланыган «Идел кызы» исемле трилогиясенең беренче ике китабы басылып чыга.

Г.Ахуновның әдәби мирасында Казанда Татар дәүләт академия театры, К.Тинчурин исемендәге драма һәм комедия театры, Әлмәт, Минзәлә драма театрлары сәхнәләрендә кат-кат куелып, заманында тамашачының игътибарын җәлеп иткән берничә пьесасы да бар: «Чулпы җыры», «Утлар яна учакта», «Тынгысыз йөрәк» (Ф.Мостафин белән бергә язылган), «Чикләвек төше», «Ардуан батыр» (шул исемнәрдәге повестьлар буенча инсценировкалар), «Акчарлаклар» (Ш.Камалның шул исемдәге повесте буенча инсценировка) һ.б. Әдип шулай ук күпсанлы әдәби һәм истәлек язмалары, әдәби тәнкыйть мәкаләләре («Әдәби язмышлар», «Чишмәләр белән сөйләшү» исемле җыентыклар, 1970, 1985) һәм әдәби тәрҗемә китаплары белән дә укучылар арасында киң танылa. Ул татар теленә В.Закруткинның «Плавучая станица» («Йөзмә станица», 1953) романын, А.Макаренконың «Педагогик поэма»сын (1957), Рабиндранат Тагор «Хикәяләр»ен (1960), М.Шолоховның «Тихий Дон» («Тын Дон») эпопеясының икенче, дүртенче китапларын (1964, 1965), Татар дәүләт академия театры өчен Н.Погодин, А.Островкий һәм башка драматургларның пьесаларын тәрҗемә итә.

Г.Ахуновның проза әсәрләреннән күбесе русчага тәрҗемә ителә, хикәя һәм повестьлары украин, үзбәк, кыргыз, мари, чуваш, якут һ.б. телләрдә басыла, «Хәзинә» романы казахча һәм төрекмәнчә тәрҗемәдә нәшер ителә.

Әдәбият өлкәсендәге казанышлары һәм иҗтимагый тормыштагы актив эшчәнлеге өчен, Г.Ахунов 1975 нче елда — Хезмәт Кызыл Байрагы, 1981 нче елда Халыклар Дуслыгы орденнары белән бүләкләнә; 1972 нче елда аңа «Россиянең атказанган мәдәният хезмәткәре» дигән мактау-

лы исем бирелә, ә 1993 нче елда, Татарстан Президенты М.Шәймиев Указы белән, ул «Татарстан Республикасының халык язучысы» дигән мәртәбәле исемгә лаек була. Әдип шулай ук 1998 елдан «Татарстан Фәннәр академиясенең шәрәфле академигы» дигән мактаулы исем йөртә.

## 15 нче дәрес

**Тема:** Тырышса да дошман, шагыйрьләрне
Аералмый җырдан, халыктан.

**Планлаштырылган нәтиҗәләр:**

М е т а п р е д м е т — музыка сәнгатенең матур әдәбият белән тыгыз бәйләнештә булуын һәм бер-берсенә йогынты ясауларын күзәтү.

П р е д м е т — Бөек Ватан сугышына багышланган җырлар турында белешмә бирү. Татар халык җыры «Герман көе» һәм Роберт Әхмәтҗановның «Солдатлар» дип аталган җырларын өйрәнү.

Ш ә х е с к ә к а г ы л ы ш л ы — укучыларда гражданлык һәм патриотик хисләр, туган җиргә, милләткә карата мәрхәмәтлелек, горурлык хисләре тәрбияләү.

**Материал:** дәреслек (1 нче кисәк, 78—79 нчы битләр).

**Җиһазлау:** мультимедиа проекторы, экран, слайдлар, магнитофон, компьютер, китап күргәзмәсе, сүзлек.

**Дәреснең эпиграфы**

Бары да үтә,
Бар да онытыла:
Байлык, зурлык китә, югала....
Тик җыр үлми,
Күчеп буыннарга,
Киләчәктә яшәп, җыр кала...

### Д ә р е с б а р ы ш ы :

**I. Мотивлаштыру-ориентлаштыру**

***1. Дәресне оештыру***

Исәнләшү, хәлләр сорашу, яхшы кәеф теләп, дәресне башлау.

Психологик уңай халәт булдыру.

— Һәр яңа көн туугa, без бер-беребезгә «Хәерле көн!» дип дәшәбез, тынычлык һәм иминлек телибез. Ә бит тыныч тормыш-

та яшәмәгән, балачакларын рәхимсез сугыш урлаган кешеләр бихисап. Бу дәресне без бүгенге тормышыбызның, бәхетле балачагыбызның никадәрле кадерле икәне турында сөйләшүгә багышларбыз. Ә хәзер, әйдәгез, бераз тарихка күз салыйк.

Моннан нәкъ 76 ел элек фашистлар Германиясе, бөтен кешелекне үзенә буйсындырырга теләп, сугыш башлаган. Ниятенең күпмедер өлеше тормышка да ашкан: Гитлер күп илләрне басып алган. Әлеге кара афәт 1941 нче елның матур җәендә безнең илебез өстенә дә канатларын җәйгән. Кыю ир-егетләребез Ватанны сакларга яуга киткәннәр. Алар арасында узган дәрестә өйрәнгән рәссамыбыз Виктор Кудελькин да булган.

***2. Актуальләштерү***

1) Алдагы дәрестә бирелгән өй эшен тикшерү.

2) Укытучы, юнәлдерүче сораулар биреп, Виктор Кудελькинның сугышта катнашуы һәм сугышка багышланган картиналары буенча әңгәмә оештыра.

— Ни өчен автор «Билгесез биеклектә» картинасының сюжет-композициясен җырдан ала?

3) Дәреснең эпиграфы белән танышалар (эпиграф укыла).

— Бу шигырь юлларында сүз нәрсә турында бара? (Җыр турында, аның киләчәккә яшәп калуы турында.)

(«Җыр» төшенчәсен алдагы сыйныфларда алган белемнәренә таянып искә төшерү».

— Көйгә салынган шигъри әсәрләрне «җыр» дип йөртәләр.

***3. Уку мәсьәләсен кую***

Укытучы Роберт Әхмәтҗановның Бөек Ватан сугышына багышланган «Солдатлар» җыры һәм татар халык җыры «Герман көе» белән танышачакларын әйтә.

**II. Уку мәсьәләсен өлешләп чишү**

1. Роберт Әхмәтҗановның Фәтхерахман Әхмәдиев көенә язылган «Солдатлар» җыры тыңлана. Балалар дәреслектән карап баралар.

1) Укытучы композитор Фәтхерахман Әхмәдиев һәм шагыйрь Роберт Әхмәтҗанов турында кыскача мәгълүмат бирә.

2) Укытучы шигырьне сәнгатьле укый.

3) Укучылар дәреслектән, чылбыр буенча, шигырьне сәнгатьле итеп укыйлар.

4) Укытучы, сораулар ярдәмендә, укучыларның аңлавын тикшерә. 78 нче биттәге 3, 4 нче биремнәр эшләнелә.

— Шигырь нәрсә һәм кемнәр турында?

— Лирик герой кемнәрне юксына?
— Мәңгелек ут нинди символик мәгънәгә ия?
— Нинди сугыш турында сүз бара?
— Аналарның балалары сугыштан кайтканмы?
— Лирик геройның кичерешләрен дәреслектән табып укыгыз.
— Аналар йөрәге һәм җил образы нәрсә белән чагыштырыла? Китаптан табып укыгыз.
— Ана образына характеристика бирегез яки китаптан табып укыгыз.

2. Сүзлек белән эш.

1) Укытучы сүзләрне укый, укучылар аның артыннан кабатлыйлар. Авыр сүзләрне аерым укучылардан кабатлаттыра.

2) Укытучы русчасын әйтә, укучылар тәрҗемәсен әйтәләр.

3) Укучылар, чылбыр буенча, яңа сүзләр белән сүзтезмәләр яки җөмләләр төзеп әйтәләр.

3. Татар халык җыры «Герман көен» тыңлау.

1) Укытучы сораулар бирә. Халык җырлары турында искә төшерелә.
— Шигырь нәрсә һәм кемнәр турында?
— Лирик герой нәрсәгә моңая?
— Ул кемнәр белән саубуллаша?
— Лирик геройның кичерешләрен китаптан табып укыгыз.
— Ул кая китә?
— Лирик геройның хыялы нинди?

2) Шигырьне укучылар үзлекләреннән укыйлар.

3) Берничә укучы шигырьне кычкырып укый.

4. Биремнәр һәм сораулар, эш дәфтәрендә эшләү.

Дәреслекнең 79 нчы битендәге 4 нче биремне дәфтәрдә эшләү.

**III. Рефлексив бәяләү**

1. — Дәрескә куелган уку мәсьәләсе чишелдеме? Җырлар нинди темага иҗат ителгән? Роберт Әхмәтҗановның «Солдатлар» шигырендә өстенлек иткән хис «Герман көе»ндә бармы? Ул нәрсә ярдәмендә үстерелә?

2. Бәяләү. Укучыларның дәрестә катнашулары бәяләнеп, билгеләр куела.

3. Өй эше: а) шигырьне сәнгатьле укырга өйрәнергә;
ә) үзең теләгән җырны яттан өйрәнергә;
б) җыр турында мәкальләр эзләп килергә.

4. Алдагы дәрескә проблема кую.

Укытучы, дәресне тәмамлаганчы, йомгаклап, нәтиҗә ясар өчен сорау бирә:

— Ни өчен татар халкының җыр хәзинәсе үзенә күрә бер тарих ул? (Анда без ерак гасырлар тавышын да, бүгенге көннәр аһәңен дә ишетәбез.)

## Укытучы өчен өстәмә материал

Безнең татар халкы — борын-борыннан җырга-моңга хирыс халык. Шатлыгын да, сагышын да җыр аша белдерә ул. Татар халкы моңнан яралгандыр, ахрысы. Шулай булмаса, халкыбызның «Кара урман», «Шахта», «Гөлҗамал», «Тәфтиләү», «Әллүки», «Зиләйлүк»ләре булмас иде. Әйтерсең, халык җырлары кешенең күңелен нечкәртеп, җанына рәхәтлек бирүче аһәң булып яңгы-рый, аның йөрәгенә барып җитә дә күңелендәге изге хисләрне уята, тетрәндерә.

Кеше үзенең көндәлек тормышында сагыш, кайгыдан арынасы яки, киресенчә, эченә сыймаган шатлыгын, куанычын белдерәсе килсә, җырлап җибәрә. Күптән ишетелгән, күңелендә сакланган, үзенең хис-тойгыларына туры килә торган көйне суза.

Җыр туа, җыр яши, җырлаучысы булганда, җыр мәңге яши. Җыр ул — яшәү чарасы. Җыр ул — халыкның җаны. Үзенең теле булмаган халык булмаган кебек, үзенең җыры, музыкасы һәм музыка уен кораллары булмаган халык та дөньяда юк.

Кешенең бөтен гомере җыр һәм музыка белән тыгыз бәйләнештә уза. Ул иң элек бишек җыры тыңлап үсә. Соңрак кеше тормышында уен, хезмәт һәм көнкүреш җырлары киңрәк урын алып бара.

Халык җырларын, халыкның милли көйләрен, уен җырларын бөтен нечкәлекләре белән оста һәм матур итеп башкару — ул үзе бер сәнгать. Халкыбызның уен җырлары элек бик киң таралган булган. Кич белән болыннарда, авылның елга буйларында, клубларда «Наза» уены, түгәрәкле җырлы уеннар, кара-каршы җырлап уйный торган уеннар, «Йөзек салыш», «Йолдыз санау» һ.б. уеннар киң таралган. Заманалар үзгәрү белән, бу җырлар, уеннар, акрынлап, онытылып баралар.

Үз халкыңның улы яки кызы булу өчен, аның гореф-гадәтләрен, җыр-моңнарын, әкият-дастаннарын, күп гасырлы тарихын, әхлак, тәрбия тәртипләрен белеп үсү кирәк.

Җыр — татар халкының иң таралган, иң хөрмәтле иҗат җимеше. Җыр — бер-берсенә тыгыз бәйләнгән ике өлештән — көйдән һәм поэтик сүзләрдән тора. Җыр сөйләр өчен түгел, ә көйләр өчен чыгарыла. Әгәр халыкның моңлы, аһәңле матур көйләре аның тиңдәшсез һәм оста композитор булуы турында сөйләсәләр, шул көйләрнең нәфис сүзләре аның акыллы һәм талантлы шагыйрь булуын раслый.

Татар халкының җыр хәзинәсе — үзенә күрә бер тарих ул. Анда без ерак гасырлар тавышын да, бүгенге көннәр аһәңен дә ишетәбез.

## 16 нчы дәрес

**Тема:** Патриот шагыйрь.

**Планлаштырылган нәтиҗәләр:**

М е т а п р е д м е т — Бөек Ватан сугышында катнашкан әдипләр турында тарихи мәгълүмат бирү.

П р е д м е т — укучыларны Фатих Кәримнең тормыш юлы һәм иҗаты белән белән таныштыру, шигырьләре турында фикер йөртә белергә өйрәтү, аның туган иленә тугрылыклы патриот-шагыйрь булуына басым ясау.

Ш ә х е с к ә  к а г ы л ы ш л ы — укучыларда кыюлык, батырлык, туган илгә бирелгәнлек, аны саклый белү сыйфатлары тәрбияләү.

**Материал:** дәреслек (79—81 нче битләр).

**Җиһазлау:** Фатих Кәрим портреты, шагыйрь китапларыннан күргәзмә, магнитофон, мультимедиа, презентация.

**Эпиграф:**

Батырлык ул — рухи матурлык... Әнә шуңа күрә дә халкыбыз кеше күңеленең рухи бөеклеген югары бәяләгән. Батырларның кылган изге гамәлләре, данлы исемнәре әкиятләргә күчкән, җырларга кергән. Шул олуг батырлык алдында безнең чор кешеләре генә түгел, киләсе гасырларда яшәүчеләр дә башларын иярләр әле...

*Минтимер Шәймиев*

### Д ә р е с  б а р ы ш ы:

**I. Мотивлаштыру-ориентлаштыру**

***1. Дәресне оештыру***

Исәнләшү, хәлләр сорашу, яхшы кәеф теләп, дәресне башлау.

Психологик уңай халәт булдыру.

***2. Актуальләштерү***

1) Алдагы дәрестә бирелгән өй эшен тикшерү.

2) Роберт Әхмәтҗановның «Солдатлар» җырын җырлау.

— Ни өчен татар халкының җыр хәзинәсе — үзенә күрә бер тарих?

3) Укытучы, юнәлдерүче сораулар биреп, укучылар белән халкыбызның сугыш кырларында күрсәткән батырлыгы турында әңгәмә оештыра.

— Сез сугышта катнашкан кайсы язучыларны беләсез?

— Сугыш турында нинди әсәрләр укыганыгыз бар?

Матурлыгы өчен бу көннәрнең
Кемнәр генә корбан булмаган.
Исемнәрен тарих безгә үзе
Саклап килә ерак еллардан.

— Сугыш! Ничә миллион кешенең гомерен өзгән, күпме балалар — ятим, аналар тол калган. Бөек Ватан сугыш елларында илебезне сакларга Татарстаннан 560 меңнән артык кеше киткән. Туган илебезне яклап, меңнәрчә ир-егетләр чит җирләрдә ятып калганнар. Күренекле язучыларыбыз, шагыйрьләребез Муса Җәлил, Абдулла Алиш, Гадел Кутуй, Нур Баяннар һәм башка бик күп асыл затларыбыз илебез азатлыгы хакына гомерләрен корбан иттеләр.

Шулар арасында татар шигъриятенең йөзек кашларыннан саналган патриот шагыйрь Фатих Кәрим дә бар.

4) «Герман көе» җыры, укучылар да җырлыйлар.

***3. Уку мәсьәләсен кую***

Укытучы бүген дәрестә Бөек Ватан сугышы турында сөйләшәчәкләрен, шагыйрь Фатих Кәрим иҗаты белән танышачакларын, «Ант» шигырен өйрәнәчәкләрен әйтә. Шулай ук гражданлык лирикасы һәм пафос турында теоретик төшенчәләрне үзләштерәчәкләрен әйтә.

**II. Уку мәсьәләсен өлешләп чишү**

1. Автор белән танышу.

1) Укытучы, шагыйрьнең шигырьләрен, китапларын күрсәтеп, тормышы һәм иҗаты белән таныштыра.

2) Бер укучы дәреслектән Фатих Кәрим турында белешмәне укый.

3) Укытучы, сораулар ярдәмендә, укучыларның аңлавын тикшерә.

— Фатих Кәрим кем ул?

— Ул кайчан туа?

— Аның язмышында нинди аянычлы хәл була?

— Сезгә аның кайсы әсәрләре таныш?

— Аның шигырьләрендә үз язмышы кабатланамы?

2. Сүзлек белән эш.

1) Укытучы сүзләрне укый, укучылар аның артыннан кабатлыйлар. Авыр сүзләрне аерым укучылардан кабатлаттыра.

2) Укытучы русчасын әйтә, укучылар тәрҗемәсен әйтәләр.

3) Укучылар, чылбыр буенча, яңа сүзләр белән сүзтезмәләр яки җөмләләр төзеп әйтәләр.

3. «Ант» шигырен уку.

Укытучы сораулар бирә:

— «Ант» сүзен сез ничек аңлыйсыз?

Татар теленең аңлатмалы сүзлегеннән сүзнең аңлатмасын уку.

*Ант* — 1) ил, халык алдында биргән тантаналы вәгъдә;

2) изге дип саналган әйберне (җир, кояш, ипи, ана, ил) шаһитлеккә чакырып әйтелгән вәгъдә сүзе, нәрсәне дә булса үтәргә ышандыру сүзе.

(Дәфтәрләргә язып кую.)

— Шигырьнең исеменә тагын бер кат игътибар итегез әле. Сезнең ант иткәнегез бармы? Кайчан һәм нинди очракларда?

— Шагыйрь туган илен, халкын, хатынын, баласын яратуын ничек белдерә?

— Шигырьнең лирик герое нинди хисләр кичерә?

— Сугышка китүче солдат ни өчен баласын тотып ант итә?

— Сабыйның күз карашы нәрсә дип әйтә кебек?

— Шигырь безне нәрсәгә өйрәтә?

— Шигырь нинди пафос белән укыла? Без нинди шигырьләрне шулай укыйбыз?

4. Гражданлык лирикасы турындагы теоретик төшенчәне аңлату, шигырь юллары белән дәлилләү. (**Гражданлык лирикасы**нда хис-кичерешнең сәбәбе булып, ниндидер тарихи вакыйга яки хәл, ситуация тора. Хис-кичереш үзе шагыйрьнең гражданлык позициясен, җәмгыятьтәге тәртипләргә һәм кагыйдәләргә мөнәсәбәтен ача. Ул җәмгыятьтәге, ил-халык тормышындагы хәлләрдән, каршылыклардан туа, шулар турында әйтеп, сөйләп узуны таләп итә.)

5. Пафос турындагы кагыйдәне уку, укучыларның кагыйдәне аңлап калуларына ирешү. (**Пафос** — әсәрнең эмоциональ көйләнеше, яңгырашы, аһәңе. Үз фикерен укучыга җиткерү өчен, язучы билгеле бер яңгыраш дулкыны таба да әсәрнең башка элементларын шуңа яраклаштыра. Пафосның җиде төре бар: героик, романтик, трагик, драматик, сентименталь, сатирик, комик.)

6. Укытучы шигырьне сәнгатьле укый.

1) Шигырьне укучылар үзлекләреннән укыйлар.

2) Укучылар шигырьне тәрҗемә итәләр.

3) Берничә укучы шигырьне кычкырып укый.

7. Китаптан 4 нче биремне телдән эшләү.

**III. Рефлексив бәяләү**

1. Укучылар дәреслектәге 3 нче биремне эшлиләр. Бу бирем эшләнгәндә, шигырьнең эчтәлеге тулысынча яңадан кабатланырга тиеш.

— Безнең солдатлар 1941 — 1945 нче елларда азатлык өчен көрәште, ә фашистлар, безнең илебезгә сугыш башлап, дөрес эшләделәрме?

— «Азатлык» һәм «явызлык» сүзләрен ничек аңлыйсыз? Сугышчылар мисалында ачыклап бирегез.

2. Бәяләү. Укучыларга дәрестә катнашканнары бәяләнеп билгеләр куела.

3. Өй эше:

а) шигырьне сәнгатьле укырга өйрәнергә;

ә) шигырьне ятларга;

б) дәреслектәге 6 нчы биремне эшләргә.

4. Алдагы дәрескә проблема кую. Укытучы, дәресне тәмамлаганчы, йомгаклап, нәтиҗә ясау өчен сораулар бирә:

— «Сугыш» дигән сүзне ишеткәч, күз алдына коточкыч күренешләр килә, дидек, нәрсәләр алар?

— Күз яше, кайгы, бәхетсезлек, ...

— «Сугыш» сүзенең капма-каршы мәгънәдәге сүзе нинди сүз?

— Тынычлык.

— «Тынычлык» сүзен ничек аңлатырсыз?

— Яшәү, өмет, шатлык, сәламәтлек...

— Димәк, без нәрсә яклы икән?

— Без бу дөньяга ярату, Җирне матурлау өчен килгән. Без тынычлык яклы. Без сәламәт яшәү яклы. Матур яшәү — үзе батырлык.

### Укытучы өчен өстәмә материал

Фатих кече яшьтән үк белемгә омтыла, поэзиягә булган мәхәббәте дә ата-ана нигезендә үк сиземләнә башлый. Шагыйрь үзе бу хакта болай дип язган: «Әдәби әсәрләр язу теләге бала чагымнан ук йөрәгемә кереп урнашты. Егет чагыннан ук тома сукыр әтиемнең үзе өчен язган шигырьләрен безгә укыштырганын ишетү, апам Мәрьямнең үз дәфтәренә Дим буе табигатен тасвирлап язган күп кенә шигырьләрен башкалардан яшереп кенә миңа укуы, абыем Ярлы Кәримнең мат-

бугатта чыгып барган шигырьләрен уку — иҗат эшемә төп этәргеч булдылар».

Бәләбәй педагогия техникумында укыганда, ул шигырьләрен кулъязма журналга кертә. 1924 нче елны Казанга килгәч, аларның кайберләрен балалар матбугатында бастыра. Тора-бара бөтенләй газета-журналларда эшләүгә күчә.

Ләкин 1937 нче елда Фатих Кәрим кулга алына. Мулла улы булarak, имеш, ул сыйнфый көрәшкә зыян китергән: үзенең нинди катлам кешесе икәнен яшереп, комсомолга кергән...

Төрмәдә утырганда да ул иҗат итүдән туктамый. Шигырьләрен күңелендә ятлап саклый. Мөмкинлек булу белән, папирос кәгазенә вак-вак хәрефләр белән язып, кием җөйләрендә яшереп тота. Бу шигырьләрдә тоткын хәле бик ачык чагыла. Алай гына да түгел, шигърият аңа яшәү көче бирә, кешелеген сакларга, сыгылып төшмәскә ярдәм итә.

Бөек Ватан сугышы башлангач, Фатих Кәрим, кулына корал тотып, сәфәргә кузгала. Сугышка китү — шатлык түгел, әмма Фатих Кәрим моңа чиксез куана. Чөнки ул хәзер ил алдындагы бурычын чын ирләрчә үти ала. Шулай итеп, 1941 нче елда Ф.Кәрим үзе теләп фронтка китә.

Фронтта ул — сапёр, разведчик һәм взвод командиры була. Мәскәүдән алып Көнчыгыш Пруссиягә кадәр араны, солдат булып, җиңеп үтә, зур батырлыклар күрсәтә. Ул ике тапкыр каты яралана, шуңа карамастан, яңадан сугышка омтыла. Ватанны дошманнан азат итү аның намус эшенә әверелә.

Сугыш елларында Фатих Кәрим кебек бай әдәби мирас калдырган башка каләм остасын табу кыендыр. Ул үзенә яшәү өчен бирелгән елларның санаулы икәнен тоя, күңелендәгесен тиз-тиз язып калырга тырыша. «Гөлсем», «Идел егете», «Тирән күл», «Партизан хатыны» «Өмет йолдызы» поэмаларында илебез кешеләренең сугыш чорындагы батырлыгын, шул ук вакытта фашистларның канэчкеч вәхшилеген гәүдәләндерә.

Бөек Ватан сугышы елларында язылган «Разведчик язмалары» һәм «Язгы төндә» повестьлары проза әсәрләре арасында аеруча әһәмиятле урын алып тора. Аларда сугышчыларның җиңүебезгә олы ышаныч белән яшәүләре, шушы изге максат өчен бөтен көч-ихтыярларын туплаулары сурәтләнә.

Ул балалар өчен дә шигырьләр, поэмалар, хикәяләр язган. «Гармунчы Аю белән җырчы Маймыл», «Пионерка Гөлчәчәккә хат», «Үлем уены», «Тирән күл» һ.б. әсәрләре — балалар әдәбиятының гүзәл үрнәкләре.

Кызганыч, Фатих Кәримгә җиңү шатлыгын кичерергә туры килми. Ул 1945 нче елның 19 нчы февралендә Көнчыгыш Пруссиядә һәлак була. Ләкин шагыйрьнең йөрәк ялкыны сугыш кырында сүнеп калмады. Аның батырлыгы онытылмый.

## 17—18 нче дәресләр

**Тема:** Үлем турында уйлама, илең турында уйла.

**Планлаштырылган нәтиҗәләр:**

Метапредмет — укучыларда сәнгатебезгә, халык уен коралларына мәхәббәт тәрбияләү.

Предмет — укучыларның Ф.Кәрим иҗаты турындагы белемнәрен ныгыту; «Кыңгыраулы яшел гармун» поэмасының төп фикерен ачыклый һәм аңлата белергә өйрәтү; «образлар системасы» төшенчәсен аңлату.

Шәхескә кагылышлы — укучыларда кешелеклелек сыйфатлары, җаваплылык хисе тәрбияләү.

**Материал:** дәреслек (1 нче кисәк, 82—85 нче битләр).

**Җиһазлау:** Фатих Кәрим портреты, Ф.Кәрим китапларыннан күргәзмә, магнитофон, мультимедиа, презентация.

**Эпиграф:**

«Тәвәккәллек, батырлыкта җыр булып калсам иде». *(Ф.Кәрим)*

### Дәрес барышы:

**I. Мотивлаштыру-ориентлаштыру**

***1. Дәресне оештыру***

Исәнләшү, хәлләр сорашу, яхшы кәеф теләп, дәресне башлау.

Психологик уңай халәт булдыру.

***2. Актуальләштерү***

1) Алдагы дәрестә бирелгән өй эшен тикшерү.

Укытучы, юнәлдерүче сораулар биреп, укучылар белән халкыбызның батыр улы Фатих Кәрим турында әңгәмә оештыра. Укучылар «Ант» шигырен сөйлиләр.

— Жанры буенча әсәр нинди төргә керә? (Лирик жанр-поэма.)

— «Шигырь» дип нәрсәгә әйтәбез? (Шигырь-эмоциональ, хисле сөйләмгә. Ул тойгы-фикерләрне, омтылыш-кичерешләрне сурәтли.)

— 1942 нче елда Фатих Кәрим кая эләгә? (1942 нче елның маенда шагыйрь яралана һәм Казан госпиталендә дәвалана. Ул «Кыңгыраулы яшел гармун» поэмасын шунда иҗат итә.)

***3. Уку мәсьәләсен кую***

Ф.Кәримнең «Кыңгыраулы яшел гармун» әсәренең эчтәлеге белән танышырбыз, әсәрдәге образлар өстендә эшләрбез һәм сәнгатьле укырга өйрәнербез, халык уен кораллары белән танышырбыз.

**II. Уку мәсьәләсен өлешләп чишү**

1. Ф.Кәримнең «Кыңгыраулы яшел гармун» поэмасын Интернет челтәреннән табып тыңлау.

— Әсәрнең исеменә игътибар итик әле. Бүген без татар халкының кайсы уен коралы турында укыячакбыз икән?

— Безнең халкыбыз элек-электән җырлы-моңлы халык булган. Ул төрле уен коралларында уйнап күңелен күтәргән. Аларны осталар үз куллары белән ясаганнар. — Бездә курай, кубыз, кәтүк сыбызгы кебек уен кораллары (рәсемнәр күрсәтелә) бар. Әйдәгез, тыңлыйк әле.

— Бу нинди уен коралының тавышы? (Курайда уйнау.)

— Ә иң күп кулланылганы — гармун булган (Гармун күрсәтелә). (Гармун моңы яңгырый.)

2. Гармун турында белешмә белән танышу (дәреслек, 87—88 нче бит).

— Татарларда гармунны Вараксин дигән оста ясаган. Элегрәк кыңгыраулы гармуннар булган. Көе ераккарак яңгырасын өчен, гармуннарга кыңгырау такканнар. Шагыйрь Фатих Кәрим дә шундый гармун турында яза. Ул гармунның төсен «яшел» ди. «Яшел» сүзенә шагыйрь яшәрү, яшәү мәгънәсен дә салган.

3. Китапның 88—89 нчы битендәге 3, 4 нче биремнәрне эшләү.

4. Укучылар шигырьне чылбыр буенча сәнгатьле укыйлар.

5. Поэма жанры турында искә төшерелә.

— Поэма белән шигырь арасында нинди уртак яклар һәм аермалар бар? Дәфтәрегезгә язып куегыз. (Поэма — шигырь белән хикәяләп язылган зур әдәби әсәр.)

6. Сүзлек өстендә эш.

7. Укытучы эчтәлекне ачу өчен сораулар бирә:

— Әсәрне ничә өлешкә бүлеп булыр иде? Башта без кем белән танышабыз?

а) Фазыл — булдыклы егет;

ә) Кыңгыраулы яшел гармун;

б) Зәңгәр күлмәкле кыз;

в) Госпиталь егетләре — Ватанның бөркетләре.

8. Батырлар — ил терәге, халык аларны зурлый, йөрәгендә саклап йөртә, җырларда җырлый. Халык үзләренең әйтемнәрендә дә алар турында онытмый.

— Ә сез батырлар турында нинди мәкальләр беләсез?

* Батыр үз халкын яклый.

* Батыр ярасыз булмас.

* Батыр яуда беленер.
* Батырга үлем юк.
* Егет сүзе бер булыр.
* Батыр үзе өчен туар, иле өчен үләр.
* Батыр башлап җибәрә, артыннан мең иярә.
* Кыюлык — ярты бәхет.
* Егетлек белән үлгән — үлем түгел.

**2 нче дәрестә** образлар системасын ачыклау.

1. «Образлар системасы» төшенчәсен аңлату.

**Образлар системасы** — ул әсәрдәге образларның, үзара бәйләнешкә кереп, бер-берсенең эчтәлеген баетып, бербөтен булып оешуы.

1) — Турыдан-туры образларга керешкәнче, әйтегез әле, вакыйгалар кайда, кайсы чорда бара? (Госпитальдә, Бөек Ватан сугышы чорында.)

— Игътибар итегез әле, әдип госпитальне ничек итеп сурәтли? Шул юлларны табып укыгыз. (Госпиталь бакча эчендә, ишекләре язулы, кәрнизләре челтәрле.)

— Димәк, госпиталь әсәрдә бер образны тәшкил итә.

2) — Әсәрдә тагын нинди образлар бар?

— Әсәрнең үзәгендә — Фазыл образы. Ул сугышка кадәр алдынгы шахтёр булган, сугышта да батыр, кыю егет икәнлеге күренә. Өстәвенә, гармунчы, җырчы. Чибәрлеге өстенә шаянлыгы да бар.

3) — Кыз образы. Алар икәү: берсе — аны сугышка озатып калган, вәгъдәләшкән кыз, ә икенчесе — бакча буйлап килүче шәһәр кызы.

— Кызларның портретларын сурәтләгән урынны табып укыгыз. (Шәһәр кызы — бөдрә чәчле, шомырт кебек кара күзле, өстендәге зәңгәр күлмәге бик килешле итеп тегелгән, итәкләре дулкынланып тора; елмаюы белән теләсә кайсы егетне үзенә гашыйк итәрлек чибәр кыз кулындагы чәчәк бәйләмен Фазылга бирә).

— Авыл кызы ничек сурәтләнгән? (Укучыларның фикерләре тыңлана.)

— Укучылар, без ул кызны һәрберебез үзебезчә күзаллыйбыз. Ягез әле, сурәтләп карыйк, аның образы ни рәвешле, нәрсә ярдәмендә тудырыла? (Аның образын Фазыл үзенең гармунда уйнап җырлавы ярдәмендә тудыра. Әсәрдә кызның портреты булмаса да, без аны шәһәр кызыннан да чибәррәк итеп күз алдына китерәбез, чөнки Фазыл аны «былбыл, гөл чәчәге, күгәрченем» дип атый, аның тыйнаклыгы, вәгъдәсенә тугрылыклы булуына

иманы камил егетнең; үзе сугыштан кайтмаган очракта да аның бәхетле булуын кайгырта, үзе кебек үк аны сөя, назлый белүче, батыр, кыю кеше белән генә тормыш итүен тели.)

4) — Образлар арасында барысын да бәйләп торучы образны табыгыз. (Гармун, хат, җыр образлары. Хат образы аша егет үзенең сөйгәненә җырлар юллый, хатын язып бетергәч, гармунын сорап ала да уйнап җибәрә.)

— Шулай да егет белән кыз образын нәрсә бәйләп тора дип уйларга була? (Гармун образы поэмада яңа образлар тудыра, әсәрдәге бөтен бәйләнешләр ачыклана. Автор юкка гына әсәргә шундый исем куймаган. Гармун — үзе кыңгыраулы, үзе яшел, үзе бик матур тавышлы, Саратовта ясалуы белән, «саратский» дип тә атала. Оста гармунчы сызып җибәргәндә, ул яралы егетләрнең күңел дөньясын тибрәтә, алар түзмиләр, гармунга кушылып җырлый башлыйлар.) (Укучыларга егетләрнең җыры укытыла.)

5) — Җыр әсәрдә нинди роль уйный? (Ватан азатлыгы өчен көрәшкән солдатлар үзләренең гомер озынлыгын җырда күрәләр. Йөрәкләрендә йөрткән иң кадерле хисләрен җырга салып әйткәннәрен сизми дә калалар. Көрәшнең иң киеренке чагында да Ватан солдаты җыр, гармун белән яши, чөнки гармун моңы аңа көч бирә, аның яшәү дәртен арттыра.)

— Шулай булгач, гармун белән бергә җыр да төп образ була аламы? Моны ничек дәлилли алабыз?

— Әгәр дә әсәрдә Фазыл, кызлар, яралы солдатлар турында гына сүз барса, поэманың тәэсире бу кадәр көчле булмас иде. Әсәр тукымасына Фазыл язган хатның соңгы юллары буларак килеп кергән халык җыры башка образларның тууына, образларның бәйләнешенә китерә. Җыр поэмада бик әһәмиятле вазифа башкара. Ватан бөркетләре — гап-гади солдатларның җырлары аша Фатих Кәрим безгә әсәрнең төп идеясен аңларга ярдәм итә.

**III. Рефлексив бәяләү**

1. — Дәрескә куелган уку мәсьәләсе чишелдеме?

— Без әсәрдәге образларның үзара бәйләнешен ачыкладык. Никадәр образ, әмма берсе дә очраклы рәвештә генә килеп кермәгән. Әлеге образлар бер-берсен тудыралар һәм үзара бәйләнештә торалар, ахырда бербөтен буларак оешып, система тәшкил итәләр.

— Нәрсә ул образлар системасы? (Дәфтәргә язылган кагыйдәне кабатлыйлар.)

— Без бүген сезнең белән Ф.Кәримнең «Кыңгыраулы яшел гармун» әсәрендәге образларга характеристика бирергә тырыштык, образлар системасын ачыкладык. Бу әсәр безне нәрсәгә өйрәтә? (Тынычлыкның кадерен белергә, сугышта һәлак булганнарның батырлыгын онытмаска, исемнәрен мәңгеләштерергә һәм киләчәк буыннарга да тапшырырга.)

2. Бәяләү. Укучыларның дәрестә катнашулары бәяләнеп, билгеләр куела.

3. Өй эше: а) поэманы сәнгатьле укырга өйрәнергә;

ә) Илдар Юзеевның «Һаман көтә» шигырен сәнгатьле укырга өйрәнергә;

б) 93 нче биттәге 2 нче биремгә җавап әзерләргә.

4. Алдагы дәрескә проблема кую.

Укытучы, дәресне тәмамлаганчы, йомгаклап, нәтиҗә ясар өчен сорау бирә:

— Автор безгә бу поэмасы белән нәрсә әйтергә теләгән ? (Автор Фазыл кебек көрәшкән меңнәрчә геройларның батырлыгын чагылдырган, Ватанга чиксез мәхәббәт, туган илгә турылыклы булып калу, кирәк булса гомереңне дә кызганмау идеясе дә яктыртылган.)

**Укытучы өчен өстәмә материал**

| Укытучы куярга тиешле сораулар | Көтелгән җаваплар |
|---|---|
| Вакыйга кайсы вакытны үз эченә алган? | Бөек Ватан сугышы чоры, 1941—1945 нче еллар. |
| Әсәрдә вакыйгалар ничә өлешкә бүленә? | 1. Сугышка кадәрге чор.<br>2. Госпитальдә.<br>3. Халык җырларының әһәмияте. |
| Әсәрнең темасы нинди? | Сугыш турында. |
| Әсәрнең өлешләре арасындагы бәйләнешләрне карыйк. Охшашлык бармы? | 1. Граната тоткан.<br>2. Чәчәк тоткан.<br>3. Гармун тоткан. |
| Каршылык алымы чагылганмы? Кабатлаулар кулланылганмы? Ни өчен? | Тыныч тормыш — сугыш; өч өлештә дә шушы каршылык. Җавапларны дәлилләү. Татар халык җырлары. |

| | |
|---|---|
| Чагыштыруларны табыгыз. | «Күгәрчен кебек гөрләшеп», «Чүлмәк кебек челпәрәмә китергән өч танкны», «Шомыртлар кебек күзе», «Күгәрченем, гөл чәчәгем». |
| Метафоралар бармы? | «Тын калып тыңлый бу җырны Күктә алтын йолдызлар». |
| Гармунның көче нәрсәдә? | Гармунның көче шунда, ул госпитальдәге егетләрнең барлык йөрәк серләрен җырларга кушып әйттерә. Ф. Кәрим шуны оста итеп сурәтли. |
| Бу бәйләнешләр ни өчен кирәк? | Әсәрне бербөтен итеп кабул итү өчен, истә калдыру өчен; образлар янәшә килеп үзара бәйләнешкә керәләр дә өр-яңа эчтәлек тудыралар, бер-берсенең эчтәлеген баеталар. |
| Бу әсәре аша Ф.Кәрим укучысына нәрсә әйтергә тели? Әсәрнең идеясе нинди? | Сугыш батырларына, хезмәт батырларына дан җырлаган. Халыкның сынмавын, сыгылмавын, киләчәккә өметенең, ышанычының ныклыгын әйтергә тели. Кыю булсыннар, батыр булсыннар, ди. |
| Әсәрдә нинди образлар бар? Әсәрдәге образлар ничек сурәтләнгән? | Фазыл образы, таныш түгел кыз образы, сөйгән яр образы, госпиталь егетләре, гармун. |

**Фазыл** — шахтёр булган, сугышта кыю, батыр; гармунчы, җырчы, чибәрлеге өстенә шаянлыгы да бар. Шуңа күрә аңа кызлар яратып карыйлар. Госпиталь егетләре үз итәләр, хөрмәт итәләр.

**Таныш түгел кыз** — бөдрә чәчле, чибәр, зәңгәр күлмәктән, кулына чәчәк бәйләме тоткан, ачык йөзле, йомшак күңелле.

**Госпиталь егетләре** — сугышта каннарын кызганмыйча сугышалар, кыюлар, чибәрләр, якты йөзлеләр, җырга да осталар.

**Гармун** көче поэмада бик ачык чагыла. Ул госпиталь егетләренең барлык йөрәк серләрен җырга кушып әйттерә. Ф.Кәрим дә татар халык

җырларының зур әһәмияткә ия икәнлеген күрсәтә. Ул поэмага табигый рәвештә халык җырларын кертеп урнаштыра.

**Сөйгән кызы** — чибәр, сагына, көтә. Сөйгәненә хатлар яза, аны ярата.

| | |
|---|---|
| Әсәрдә нинди зур проблема күтәрелгән? | Сугыш проблемасы. |
| Шушы проблема нәтиҗәсендә нинди хисләр туа? | Кыюлык, ныклык, хезмәт сөю, мәхәббәт, сагыну, аклык, сафлык, тугрылык, туган илне ярату, шатлык, кайгы, түземлелек, сабырлык. |
| Димәк, бу поэмада кешедә була торган барлык хисләр дә чагылган.<br>Әсәрнең интонациясе нинди? Нинди рух белән укыла? | Күтәренке рух. |

## 19 — 20 нче дәресләр

**Тема:** Исемең калды моңлы бер җыр булып...

**Планлаштырылган нәтиҗәләр:**

Метапредмет — Бөек Ватан сугышында катнашкан геройлар тарихы.

Предмет — Туфан Миңнуллинның тормыш юлы, иҗаты белән таныштыру, «Моңлы бер җыр» драмасын уку һәм нәтиҗә ясау.

Шәхескә кагылышлы — туган ил өчен көрәшү, туган илне яклау изге бурыч булуына төшендерү, көчле рухлы булырга өндәү.

**Материал:** дәреслек (1 нче кисәк, 89—100 нче битләр).

**Җиһазлау:** мультимедиа проекторы, экран (такта), Туфан Миңнуллин китаплары, Муса Җәлил портреты, «Моңлы бер җыр» спектакленнән өзек, Интернеттан алынган материаллар, «Сибелә чәчәк» җыры.

**Д ә р е с   б а р ы ш ы:**

**I. Мотивлаштыру-ориентлаштыру өлеше**

***1. Дәресне оештыру***

Исәнләшү, дәресне башлау. Хәлләрен, нинди кәеф белән килүләрен сорашу. Психологик уңай халәт тудыру.

***2. Актуальләштерү***

1) Өй эшен тикшерү.

2) Бөек Ватан сугышында катнашкан герой шагыйрьләр арасында Муса Җәлил иҗаты да зур урын алып тора. Без бүгенге дәрестә Туфан Миңнуллинның «Моңлы бер җыр» әсәре аша Җәлилнең бөеклеген тагын бер мәртәбә исбатларбыз.

***3. Уку мәсьәләсен кую***

Укытучы беренче дәрестә Туфан Миңнуллинның тормыш юлы һәм иҗаты, «Моңлы бер җыр» драмасы белән танышачакларын әйтә.

«Моңлы бер җыр» драмасы өйрәнелә, образлар белән таныштырып барыла, аларга кыскача тасвирлама бирелә, бу дәресләрдә әсәрнең эчтәлеге тулысынча үзләштерелә.

Темадан чыгып, дәрескә уку мәсьәләсен кую.

**II. Уку мәсьәләсен өлешләп чишү**

1. Туфан Миңнулинның тормыш юлы, иҗаты белән танышу.

Бу — укытучы сөйләве, презентация карау, алдан әзерләнгән укучыларның чыгышлары да булырга мөмкин.

2. Дәреслектәге биографик белешмә белән укучыларның танышуы. Сорауларга җавап бирү: алдан әзерләнгән карточкаларда сораулар, парларда яки төркемнәрдә сорау — җавап.

Туфан Миңнуллин — күпкырлы талант иясе. Аның драма һәм проза әсәрләре турында мәгълүмат бирү (дәреслектә, Интернет челтәрендә, китапларында.)

3. Сүзлек эше.

4. Пьесаның (1 нче дәрестә — 1 нче бүлеге, 2 нче дәрестә — 3—4 нче бүлекләре) эчтәлеге белән танышу: рольләргә бүлеп уку, тәрҗемә итү.

Эчтәлек буенча әңгәмә.

— Сезнең нинди драма әсәрләре укыганыгыз бар? Әлеге драма башкаларыннан аерыламы?

— Вакыйгалар кайда бара?

— Шагыйрь төрмәгә нинди ният белән килгән?

— Сугышта булган, пленга төшкән кешеләр турында китаплар, кинофильмнар караганыгыз бармы?

— Тоткынлыкта геройлар нинди хисләр кичерә?

5. «Сибелә чәчәк» җырын Интернеттан табып тыңлау.

6. Образлар турында.

— Шагыйрь төрмәдә кем белән таныша?

— Муса Җәлил турында ниләр беләсез? Тормыш юлын исегезгә төшерегез.

— Шагыйрь өчен Муса Җәлил кем?

«Сезнең янга хыялым алып килде, Муса абый... Мин сезне хыялымда терелттем. Сез — шагыйрь, хыялның ни икәнен яхшы беләсез. Без, кешеләр, хыялда һәм төшебездә дөньяда үзләре булмаганнар белән дә очраша алабыз» җөмләләрен ничек аңлыйсыз? Әлеге сүзләргә ышанасызмы? Хыял сезнең өчен нәрсә ул?

— Шагыйрь һәм Муса янына кем килә?

— Кем ул Риенеро Ланфредини? Әсәрдәге роле нидән гыйбарәт?

— Шагыйрьнең Муса Җәлилгә карата мөнәсәбәте нинди?

— Муса Җәлилне күбрәк нәрсә кызыксындыра? Аның өчен иң мөһиме нәрсә?

— **2 нче өлештә** геройлар нәрсә турында сөйләшәләр?

— Әсәрдәге тарихи фактны атагыз. Әлеге вакыйганы исегезгә төшерегез.

«Шәхесне дөрес бәяләүче шәхес үзе түгел, аның кылган эшләрен күргән, белгән кешеләр. Аның иптәшләре дә көчле рухлылар иде. Елмаю алар өчен, ихтимал, гадәти эштер, әмма мин үзем җәза алдыннан елмая алмас идем» дигән сүзләрне Ланфердини кемне уйлап әйтә. Көчле рух сезнең өчен нәрсә ул? Муса Җәлил көчле рухлымы? Бүгенге заманда көчле рухлы кешеләрне очратырга мөмкинме?

— Вакыйгаларда тагын кемнәр катнаша? Һәрберсе турында аерым сөйләргә. (Укытучы өстәмә рәвештә аңлатма бирергә тиеш.)

— **3 нче өлештә**ге геройларның исемнәрен атагыз. Араларында таныш шагыйрьләр бармы?

— 11 җәлилче нәрсә турында сөйләшә? Аларда үкенү хисләре бармы? Сез ничек уйлыйсыз: аларга шулай тыныч калырга нәрсә ярдәм иткән? Алар нәрсәгә ышаналар? (Әлеге сораулар ярдәмендә әсәрнең идеясен табыгыз.)

— Әсәр эченә халык авыз иҗаты элементлары — мәзәкләр кергән. Аларга нинди мәгънә салынган? (Көлке элементы ярдәмендә персонажларның күңел халәте ачыла.)

7. Теоретик төшенчәләр (символик образ, диалог, ремарка) белән эш.

— Драма ни өчен фантазия ярдәмендә генә бирелә? (Дөньяда булмаган кешеләр белән очрашу өчен; персонажлар кичергән драма күңелдә үзәк өзгеч моң тудыра.)

8. Дәреслектә 99 нчы биттәге 2, 3 нче сорауларга җавап бирү.

9. «Моңлы бер җыр» публицистик драмасы турында текстны 99—100 нче битләрдән укырга. Муса Җәлилнең әлеге юллар кергән «Җырларым» шигырен сәнгатьле уку, фикер алышу.

**III. Рефлексив бәяләү**

1. — Дәрескә куелган уку мәсьәләсе чишелдеме? Нәтиҗә чыгару.

2. Дәрескә гомуми бәя. Укучыларга билге кую.

3. Өй эше: а) 4 нче өлешнең эчтәлеген сөйләргә өйрәнергә;

ә) бер геройга характеристика язып килергә.

б) Герой Муса Җәлил турында проект төзергә, реферат язарга.

4. Алдагы дәрескә проблема кую.

Укытучы, дәресне тәмамлаганчы, йомгаклап, нәтиҗә ясар өчен сораулар бирә:

— Драма ни өчен «Моңлы бер җыр» дип аталган? (Укучылар фикере тыңлана.)

— Муса Җәлилнең тормыш юлын һәм иҗатын өйрәнүдә Туфан Миңнуллинның «Моңлы бер җыр» драмасының роле нинди? (Туфан Миңнуллин үзенең әсәре аша Муса Җәлилнең кичерешләрен, иҗаты аша шагыйрьнең бөеклеген раслый.)

### Укытучы өчен өстәмә материал

Тематика һәм проблематика буенча да, сәнгатьлелек ягыннан да Т.Миңнуллин драматургиясе күптармаклы һәм бай. Язучы аерым бер тема яки тормыш материалы, бер характердагы геройлар белән генә эш йөртми. Монда аның иҗат принциплары торган саен ачыклана. Т.Миңнуллин драматургиясе образлар системасы ягыннан да, жанрлар һәм стиль төрлелеге җәһәтеннән дә бай. Ул тарихи, тарихи-биографик һәм фәлсәфи-романтик драмалардан, психологик драманың һәм комедиянең күп төрләреннән, водевиль һәм экият-пьесалардан тора. Сәнгатьчә эшләнеше буенча алар арасында саф реалистик стильгә караганнары да, шартлы-фантастика элементлары белән баетылганнары да бар.

Туфан Миңнуллин драматургиясенең характерлы якларыннан берсе — аның заман проблемаларына аерата сизгер булуы. Агымдагы

чынбарлыкны аның бүген чишүне сорый торган мәсьәләләрне чын сәнгать югарылыгында хәл итү, замандаш образын, аның тарихи ролен үзенчәлекле гәүдәләндерү кебек гаять авыр һәм катлаулы бурычларны үтәүдә Т.Миңнуллин иҗаты татар әдәбиятының алгы сафына чыкты һәм бүген дә алда тора.

«Моңлы бер җыр» исемле публицистик драмасында (1981) автор әлеге алымга кабат мөрәҗәгать итте. Әсәрнең идея-художество эчтәлеге нык кына абстракцияләүгә корылган. Драматургның әйтергә теләгән фикерен, аның дөньяга карашын чагылдырган хәзерге шагыйрь монда легендар шәхес Муса Җәлил белән очраша. Мондый ситуациядә күрсәтелгән персонажларның үзара мөнәсәбәте шактый катлаулы шартлылыкка корылган. Үзе дә шартлы сәхнә образы булган Шагыйрь фантазиясе белән Муса Җәлилне, аның көрәштәшләрен һәм дошманнарын һ.б. «терелтә»; берәүләре белән диалог-бәхәс алып бара, икенчеләре белән диалог-фәлсәфә кора, өченчеләреннән сорау алу оештыра. Болар һәммәсе драманың фәлсәфи-сәяси эчтәлеген тирәнәйтергә булыша. Зур мәсьәләләрне хәл итүдә, фашизмның кешелек өчен куркынычлыгын, аның үлемгә хөкем ителгәнлеген күрсәтүдә әлеге алымнарның киң мөмкинлекләреннән Т.Миңнуллин оста файдалана. Бу әсәр нигезендә куелган спектакльдә яшәү белән үлем фәлсәфәсе, аның азатлык көрәшендәге, гомумән кеше язмышындагы роле үзенчәлекле һәм тирән ачылды.

## 21 нче дәрес

**Тема:** Һәйкәлләргә килик, гөлләр куйыйк,
Һәйкәлләрне тыңлыйк тын гына.

**Планлаштырылган нәтиҗәләр:**

М е т а п р е д м е т — Казаныбызның истәлекле урыннары белән таныштыруны дәвам итү. «Барельеф» төшенчәсен аңлауга ирешү.

П р е д м е т — герой-шагыйрь Муса Җәлилнең тормыш юлы һәм иҗаты буенча белемнәрне ныгыту; Марсель Сәлимҗанов һәм Ринат Таҗетдинов эшчәнлеге белән танышу.

Ш ә х е с к ә к а г ы л ы ш л ы — балаларда ихтыяр көче, рухи ныклык сыйфатлары тәрбияләү, бәйләнешле сөйләм үстерү.

**Материал:** дәреслек (1 нче кисәк, 100—105 нче битләр).

**Җиһазлау:** мультимедиа проекторы, экран, слайдлар: Муса Җәлил портреты, китаплары, Марсель Сәлимҗанов һәм Ринат Таҗетдинов портретлары, рәсемнәр, Җ.Фәйзинең С.Хәким сүзләренә язылган «Торыгыз, Мусалар» дигән җыры.

**Эпиграфлар:**

Минем өчен Муса Җәлил сынаулар һәм үлем каршында гражданлык һәм язучылык батырлыгы күрсәткән кешеләрнең бер үрнәге булды һәм шулай булып кала. Ул зур шагыйрь генә түгел, бәлки көчле рухлы батыр да, безнең аңа карата рәхмәт хисе йөргән күңелебезгә нәкъ шулай булып урнашкан зур кеше дә.

*Константин Симонов*

## Дәрес барышы:

**I. Мотивлаштыру-ориентлаштыру**

***1. Дәресне оештыру***

Исәнләшү, хәлләр сорашу, яхшы кәеф теләп, дәресне башлау. Психологик уңай халәт булдыру.

***2. Актуальләштерү***

Укытучы, юнәлдерүче сораулар биреп, Муса Җәлил белән бәйле урыннар турында әңгәмә оештыра:

— Казан кайсы галимнәргә, язучыларга, артистларга иҗат канаты биргән?

— Муса Җәлил белән бәйле нинди урыннарны беләсез?

— Һәйкәлләр нәрсә турында сөйли? «Һәйкәлләрдә — халык хәтере» дигән сүзләрне ничек аңлыйсыз?

— Казан — күпме көрәшчеләр тәрбияләп үстергән, күпме даһиларга иҗат канаты биргән данлы кала. Биредә Шиһабетдин Мәрҗани, Каюм Насыйри, Хөсәен Фәезханов, Казембек кебек акыл ияләре, А.М.Бутлеров, Н.И.Лобачевский кебек галимнәр яшәгән һәм иҗат иткән. Казан университетында студент Ульяновның дөньяга карашы формалашкан. Н.Е.Федосеев, М.Вахитов, Х.Ямашевларның көрәш юлы шушы шәһәрдә башланган. А.М.Горький Казанда тормыш мәктәбенең күп баскычларын узган, татар халкының даһи шагыйре Габдулла Тукай үзенең иҗат канатын шушында чыныктырган.

Көрәшче һәм шагыйрь, Советлар Союзы Герое, Ленин премиясе лауреаты Муса Җәлил исеме дә шул якты йолдызлар арасында балкый. Борынгы Казан Кремленең таш стеналары буенда аңа мәңгелек һәйкәл куелган. Шуннан торып, ул киң Идел өстенә, илебез өстенә, киләчәккә карый. Һәйкәлнең мәрмәр нигезенә патриот-шагыйрьнең үлемсез сүзләре уелган:

Гомерем минем моңлы бер җыр иде,
Үлемем дә яңгырар җыр булып.

***3. Уку мәсьәләсен кую***

1) Укытучы бүген дә дәрестә Казанда Муса Җәлил һәйкәле һәм җәлилчеләргә куелган барельефлар турында сөйләшәчәкләрен искәртә. «Барельеф» төшенчәсен аңлауга ирешәчәкләрен әйтә.

2) Муса Җәлил образын югары сәнгать дәрәҗәсенә ирештергән шәхесләр белән танышуны дәвам итәчәкләрен җиткерә.

**II. Уку мәсьәләсен өлешләп чишү**

1. Укытучы Муса Җәлил һәйкәле һәм җәлилчеләргә куелган барельефлар турында мәгълүмат бирә.

2. Дәреслектәге 100 — 101 нче биттән Муса Җәлил һәйкәле һәм җәлилчеләргә куелган барельефлар турында өзек укыла.

1) «Барельеф» сүзенә аңлатма бирелә.

2) Сүзлек өстендә эш.

3) Укытучы сораулар бирә:

— Өзек нәрсә турында? Ничә өлешкә бүлеп була?

4) Төркемнәрдә эш.

**I нче төркем** өлешкә исем куя һәм сорауларга җавап бирә.

— Казанда Муса Җәлилгә һәйкәл кайчан ачыла? Һәйкәлнең авторлары кемнәр?

— «Муса Җәлил һәйкәле югарыга очар өчен канатларын җайлап куйган бөркетне хәтерләтә» җөмләсен рус теленә тәрҗемә итегез. Фикер алышыгыз.

Төркем өч эпиграфның берсен сайлап ала һәм аңлата.

Төркем Галиәсгар Камал театры режиссёры Марсель Сәлимҗановның тормыш юлы, иҗаты белән таныша.

— Ул Муса Җәлил образын ачуда нинди эш алып бара? План төзеп сөйләү.

**II нче төркем** өлешкә исем куя һәм сорауларга җавап бирә.

— Муса Җәлилнең көрәштәшләренә ничәнче елда барельефлар куела? Анда кемнәр сурәтләнгән?

— Аларны нәрсә өчен һәм ничәнче елда үлем җәзасына хөкем итәләр?

Төркем өч эпиграфның берсен сайлап ала һәм аңлата.

Төркем Галиәсгар Камал театры артисты Ринат Таҗетдиновның тормыш юлы һәм иҗаты белән таныша.

— Аны Муса Җәлил образы белән нәрсә бәйли? План төзеп сөйләү.

— Ел буе үлем җәзасын көткән көрәшчеләрне 1944 нче елның 25 нче августында Плетцензее төрмәсенә алып килеп, гильотинада башларын кисәләр. Горур татар егетләре Гайнан Курмашев, Фоат Сәйфелмөлеков, Абдулла Алиш, Фоат Булатов,

Муса Җәлил, Гариф Шабаев, Әхмәт Симаев, Абдулла Батталов, Зиннәт Хәсәнов, Әхәт Атнашев, Сәлим Бухаров шулай һәлак була. Юк, һәлак булмый, аларның соңгы адымнары үлемсезлеккә атлау иде. Без бүген батырлар алдында баш иябез. Алар мәңге хәтеребездә! Халкы өчен үлемнән дә курыкмаган каһарманнар безгә һәрчак үрнәк!

3. 102 нче биттәге 2 нче биремне телдән эшләү.

4. Җәүдәт Фәйзинең Сибгат Хәким сүзләренә язылган «Торыгыз, Мусалар» дигән җырын тыңлау. Әңгәмә оештыру.

**III. Рефлексив бәяләү**

1. — Дәрескә куелган уку мәсьәләсе чишелдеме? Дәреснең эпиграфын уку. Дәрескә нәтиҗә ясау.

— Муса Җәлил һәм аның көрәштәшләре турында нәрсәләр әйтә аласыз?

2. Дәрескә гомуми бәя. Үзбәя. Укучыларга билге кую.

3. Өй эше: а) өзекне сәнгатьле укырга;

ә) Муса Җәлил образын халыкка җиткергән шәхесләр турында сөйләргә;

б) 102 нче биттәге 5 нче биремне эшләргә.

4. Укытучы, дәресне тәмамлаганчы, йомгаклап, нәтиҗә ясар өчен сораулар бирә:

— Сугыш хатирәсен, батырлар данын нәрсәләр саклый?

— Сугыш хатирәсен, батырлар данын һәйкәлләр саклый. Алар, тын гына, сугыш афәтен башка кабатламаска чакыралар, тиңдәшсез батырлыкка дан җырлыйлар.

Әлеге сугышта башларын салганнар чорлар аша безгә эндәшәләр. Алар инде беркайчан да әйләнеп кайтмаячак, балаларын кочакларына алмаячак, оныкларын күрү бәхетенә ирешмәячәк. Бәхетле киләчәк өчен газиз гомерләрен корбан иткән батырларның изге рухы алдында баш иик, аларны бер минутлык тынлык белән искә алыйк!

Һәйкәлләрдәге, геройлар аллеясындагы чәчәкләр хөрмәт, ихтирам билгесе булып утыралар. Телләре булса, алар һәр үткән кешегә менә шулар турында сөйләрләр иде. Җир йөзендә сугышлар кабатланмасын, яшь егетләрнең гомерләре вакытсыз өзелмәсен, әти-әниләр кайгы яше түкмәсен, диярләр иде.

## 22 нче дәрес

**Тема:** Каз канаты каурый-каурый,
Хатлар язарга ярый.

**Планлаштырылган нәтиҗәләр:**

Метапредмет — эпистоляр жанр турында төшенчә бирү.

Предмет — фронт хатларын уку. Хат язарга өйрәнү.

Шәхескә кагылышлы — укучыларда гражданлык һәм патриотик хисләр, туган җиргә, милләткә карата мәрхәмәтлелек, горурлык хисләре тәрбияләү.

**Материал:** дәреслек (1 нче кисәк, 108—109 нчы битләр).

**Җиһазлау:** мультимедиа проекторы, экран, слайдлар, магнитофон, компьютер, фронт хатлары, сүзлек, китаплар күргәзмәсе.

### Дәрес барышы:

**I. Мотивлаштыру-ориентлаштыру**

***1. Дәресне оештыру***

Исәнләшү, хәлләр сорашу, яхшы кәеф теләп, дәресне башлау. Психологик уңай халәт булдыру.

***2. Актуальләштерү***

1) Алдагы дәрестә бирелгән өй эшен тикшерү.

2) Бөек Ватан сугышы батырлары турында әңгәмә кору.

— Бөек Ватан сугышы кешелек тарихында моңарчы күрелмәгәнчә дәһшәтле һәм авыр булды. Җиңү таңы атты. Ләкин бу Җиңү бик күп гомерләр бәрабәренә яуланды.

— Бөек Ватан сугышы батырларыннан кемнәрне беләсез? (Газинур Гафиятуллин, Мәгубә Сыртланова, Муса Җәлил, Фатих Кәрим, Абдулла Алиш, Хәйретдин Мөҗәй һ.б.)

— *Кыю, түзем, тәвәккәл, туры сүзле, ихтыярлы* кебек сыйфатларны батырлыкка кертергә буламы? Ни өчен шулай дип уйлыйсыз? (Кешедә бу сыйфатлар булмаса, ул батырлык эшли алмас иде.)

— Без бүген Бөек Ватан сугышы геройларының фронт хатларын укырбыз. Аларның батырлыкларына тагын бер мәртәбә сокланырбыз.

***3. Уку мәсьәләсен кую***

Бүген хатларның төрләре, аларны язу нормалары, этикеты, бөек кешеләрнең хат үрнәкләре белән танышырбыз. Бөек Ватан сугышы батырларының фронт хатларын укырбыз.

**II. Уку мәсьәләсен өлешләп чишү**

1. Укытучының кереш сүзе.

— Без кешеләр белән аралашмыйча тора алмыйбыз. Ерактагы якыннар белән дә төрлечә аралашырга була. Шуның бер мисалы — хат язу. Хатны бүгенге көндә Интернет аша да җибәрергә була. Бу — бик тиз, уңайлы. Вакытны да аз ала, адресатыгыз Интернет челтәрендә булса, җавапны да шул ук вакытта алырга була. Хатны ак кәгазь битенә үз кулың белән язып, почта аша җибәрергә дә мөмкин. Монда инде яңалыклар белән бергә күңел җылысын да сизәргә була. Күргәнебезчә, хат язу — бер дә җиңел эш түгел. Аның үз кануннары бар. Әдәбият фәнендә хат формасында язылган әсәрләр бар. Аларны «эпистоляр жанр» дип атыйлар. Мәсәлән, Һ.Такташның «Киләчәккә хатлар»ы, Г.Кутуйның «Тапшырылмаган хатлар»ы. Аның берсе шигырь белән язылган, икенчесе — повесть.

2. Дәреслектән укучылар «эпистоляр жанр» төшенчәсен укыйлар.

3. Аңлатмалы сүзлектә «хат» сүзенә булган билгеләмәне карыйлар. (1 укучы сүзлектән «хат» сүзенә аңлатма таба, кычкырып укый.)

*Хат* — үзара хәбәрләшү максатында кемгәдер атап язып җибәрелә һәм тапшырыла торган язма.

4. Сорауларга җавап бирү, әңгәмә.

— Каурый каләмнәр кайсы гасырда барлыкка килгән?
— Кайсы гасырда язулар барлыкка килгән?
— Сез хатлар язасызмы?
— Хатны кемнәргә язып була?
— Хатлар кемнән килә?
— Ни өчен без хатларны сирәк язабыз?
— Хатлар турында тагын нәрсәләр беләсез?
— Сез ничек уйлыйсыз, хат алу күңеллеме?

5. Хат төрләре турында сөйләшү: шәхси хатлар; мәхәббәт хатлары; эш хаты; тәкъдим хаты; җавап хаты; кайгы уртаклашу хаты; котлау хаты.

— Без күбрәк шәхси хатлар язабыз. Алар аша туганнар, дуслар белән аралашабыз. Хат башында, гадәттә сәламләү сүзләреннән соң, хәлләрне, сәламәтлекне сорашу булырга тиеш. Хатның эчтәлегендә нинди вакыйгалар, яңалыклар турында сүз барса да, логик эзлеклелек булырга тиеш. Әлеге этикет киңәшләрен истә тотарга кирәк. Имзаны үз кулың белән генә куярга.

Шәхси хатларның бер төре — мәхәббәт хатлары — кемгә языла?

Мәхәббәт хатын язу өчен тел байлыгы кирәк. «Мин сине яратам, син миңа ошыйсың», — дигән сүзләр белән генә матур хат яздым дип булмый. Үз хисләреңне башка сүзләр белән дә белдерә белергә кирәк. Шуңа күрә китаплар күп уку мөһим. Классик әдәбиятта мәңгелек мәхәббәт хатлары үрнәкләрен очратырга була. Сез дә, 9 нчы өлкән сыйныфта А.С.Пушкинның «Евгений Онегин» поэмасын өйрәнгәндә, төп геройларның мәхәббәт хатларын укырсыз. Шунда игътибар итәрсез: ничек матур, нәфис итеп язылган алар! Татар әдәбиятында да тулысы белән хат рәвешендә язылган әсәрләр бар. Мәсәлән, Г.Кутуйның «Тапшырылмаган хатлар» повесте — тулысы белән хат. Галиянең үз мәхәббәте Искәндәргә язган хатлары.

Эш хатларына (деловые письма) тукталыйк. Мәсәлән, сез бик зур фирма директоры, ди, эш хатлары кемгә язылырга мөмкин һәм нинди максат белән? Эш хатына партнёр эзләү, фирма күрсәткән хезмәт төрләрен тәкъдим итү яки фирма товарын тәкъдим итү дә керә. Реклама хатлары да эш хатларының бер төре булып тора. Алар хәзерге вакытта почта ящикларында бик күп ята. Ләкин без аларның барысын да укыйбызмы? Бүгенге көндә фирмаларның саны искиткеч күп. Эш хатлары бик күп килә. Кайбер хатлар бөтенләй укылмыйча кала. Шуңа күрә фирмалар төрле кызыктыру чаралары эзләп табалар. Адресатның исемен язалар, аның турында информация өстиләр, конверт эченә бүләк салалар, игътибарны җәлеп итүче бер генә җөмләне конвертның тышына ук язып куялар. Мәсәлән, «Татар теленнән имтиханны бишлегә генә бирергә телисезме?» һ.б.

Без бүген сезнең белән фронт хатларын укырбыз.

6. Дәреслектән Муса Җәлил, Фатих Кәрим хатларын уку:

1) хатның эчтәлеген сөйләү;
2) сүзлек өстендә эш;
3) шагыйрьнең иҗатына бәйле 5 сорау төзү;
4) өстәмәгә Абдулла Алиш хатларын уку.

**III. Рефлексив бәяләү**

1. — Дәрескә куелган уку мәсьәләсе чишелдеме? Хат язу ни өчен кирәк?

2. Бәяләү. Укучыларның дәрестә катнашулары бәяләнеп, билгеләр куела.

3. Өй эше: а) хат язарга. Ул хат дустыгызга, туганнарыгызга, яраткан кешегезгә булырга мөмкин;

ә) хатларны сәнгатьле укырга;

б) укылган хатлар буенча сораулар әзерләргә.

4. Алдагы дәрескә проблема кую.

Укытучы, дәресне тәмамлаганчы, йомгаклап, нәтиҗә ясар өчен сораулар бирә:

— Фронт хатлары аша геройларның эш-гамәлләрен белеп буламы?

— Фронт хатларының эчтәлеге нидән гыйбарәт?

— «Эпистоляр жанр» төшенчәсен аңлатыгыз.

### Укытучы өчен өстәмә материал

1942 нче елның 15 нче феврале. Муса Җәлилнең кызына 5 яшь. Әтисе аңа фронттан болай дип яза: «Мин синең өчен бик кызыклы әкият уйлап чыгардым. Алтын әтәч турында. Аның артыннан фашистлар куалар, әмма үзләре тозакка килеп эләгәләр...»

Шул ук елның 24 нче мартында язылган хатында да Муса бу турыда искә төшерә: «Кадерле Чулпаным!.. Мин яңа гына сугыш сызыгыннан кайттым. Сугыштан соң дуслар белән әтәч шулпасы ашадык. Ә менә сиңа ышандырган әтәч турында язарга һич вакыт таба алмыйм. Мин аны язармын. Ул — сугыш һәм әтәч турында бик кызыклы хикәят...»

Башка хатларыннан да күренгәнчә, Җәлил алтын әтәч турында ниндидер кызыклы әкият уйлап чыгарган, ләкин аны кәгазьгә язарга вакыт кына таба алмаган...

Чулпан исә әтисе вәгъдә иткән әкиятне бик көткән, үзе дә алтын әтәч турында төрле кызыклы хәлләр уйлап чыгарган. Әмма Җәлилнең әкияте язылмый калган...

### Абдулла Алиш хатлары

...Без ярты ел Берлин төрмәсендә утырдык. Суд 7 нче февральдә 1944 нче елда Дрезденда булырга тиеш.

Килдем, көрәштем, киттем.

Күрәсең, безнең язмыш шундый. Без соңгы сулышкача үз халкыбызга турылыклы калабыз. Аһ, ничек яшисе килә, сезне — кадерлеләремне күрәсе һәм бөтен кичергәннәрне сөйлисе килә. Язылган һәм уйланган күп нәрсәләр үзебез белән китә...

Бик каты үбәм. Бигрәк тә минем Алмаз белән Айвазны. Бәхил булыгыз, сезнең турылыклы улыгыз А.Алиш. 28.01.44.

*А.Алишның Берлин төрмәсеннән язган хушлашу хатыннан*

Советлар Союзы
Казан шәһәре

Дзержинский ур, 18\19, кв.1
Тюльпанова Рокыяга

Минем тормыш иптәшем, яраткан әнием, минем кадерле балаларым, туганнарым һәм дусларым! Сезгә кайнар сәламемне җибәрәм. Бәлки, бу сәламем соңгысы булыр. Мин, Абдулла Бари улы Алиш, язучы Абдулла Алиш, 1001 укчы полкының кызылармеецы, тоткынлыкка эләгеп, 1941 нче елның 12 нче октябрендә әсирлеккә төштем. Төрле төрмәләрдә «сәяхәт итеп», Чехиягә эләктем, монда заводта шлифовщик булып эшләдем. 1942 нче елның ахырында Берлин янындагы бер лагерьда Муса Җәлил һәм Р. Саттарны очраттым.

1943 нче елның августында мине яңадан кулга алып, хөкем иттеләр. Легионерлар арасында листовкалар таратуда гаепләделәр. Минем белән бергә башка легионерларны да кулга алдылар...

**Фатих Кәрим хатлары**

Сөекле Кадриям һәм күз нурларым Адам белән Ләйләм!

Сезгә тирән якынлык һәм чиксез сагыну хисләре белән чолганган кайнар сәламемне җибәрәм. Сагынам сезне, сагынам, халык җырында әйтелгәнчә: «Төнлә төшләремдә күрәм, көндез әллә кайда сез!» Кадрия, үзеңне, кызларымны ни дәрәҗәдә якын күреп ятканлыкны бөтен тирәнлеге белән аңласаң иде...

*30 июнь, 1942 ел*

## 23 нче дәрес

**Тема:** Син күрсәткән батырлыкны, солдат,
Халкым сөйли мактап бүген дә.

**Планлаштырылган нәтиҗәләр**:

М е т а п р е д м е т — Бөек Ватан сугышында катнашкан әдипләр турында тарихи мәгълүмат бирү.

П р е д м е т — Мостай Кәримнең тормыш юлы һәм иҗаты турында белешмә бирү, «Билгесез солдат» шигырен өйрәнү.

Ш ә х е с к ә к а г ы л ы ш л ы — укучыларда туган илгә мәхәббәт, белем алуга омтылыш тәрбияләү.

**Материал:** дәреслек (1 нче кисәк, 109—111 нче битләр).

**Җиһазлау:** мультимедиа проекторы, экран, слайдлар: Мостай Кәрим портреты, шигырь җыентыклары, сугыш темасына ясалган рәсемнәр.

**Д ә р е с   б а р ы ш ы:**

**I. Мотивлаштыру-ориентлаштыру**

***1. Дәресне оештыру***

Дәресне башлау. Психологик уңай халәт тудыру.

***2. Актуальләштерү***

1) Алдагы дәрестә бирелгән өй эшен тикшерү.

2) Укытучы, юнәлдерүче сораулар биреп, укучылар белән халкыбызның сугыш кырларында күрсәткән батырлыгы турында әңгәмә кора.

— Сугышта катнашкан кайсы язучыларны беләсез?

— Сугыш турында язылган нинди әсәрләр укыганыгыз бар?

— Әдәби төрләрне атагыз.

— Нәрсә ул лирика?

— Лирика жанрлары нинди бул?

***3. Уку мәсьәләсен кую***

— Бүгенге дәреснең темасы — Мостай Кәримнең «Билгесез солдат» шигырен уку.

Темадан чыгып, дәрескә уку мәсьәләсен укучылар белән бергәләп кую.

1) Мостай Кәримнең тормышы, иҗаты белән танышу.

2) «Билгесез солдат» шигырен уку, аңлау.

**II. Уку мәсьәләсен өлешләп чишү.**

1. Автор белән танышу.

1) Укытучы, язучының китапларын күрсәтеп, тормышы һәм иҗаты белән таныштыра (презентацияләрдән файдалану).

2) Бер укучы дәреслектән Мостай Кәрим турында белешмәне укый.

3) Укытучы, сораулар ярдәмендә, укучыларның аңлавын тикшерә.

— Мостай Кәрим кайсы төбәктә туган?

— Шагыйрь беренче шигырьләрен кайчан яза башлый?

— Мостай Кәрим Бөек Ватан сугышында катнашканмы?

— Язучы нинди жанрларда иҗат иткән?

— Мостай Кәримнең шигырьләре нинди телләргә тәрҗемә ителгән?

2. Беренче өлешнең сүзлекчәсе белән эш.

1) Укытучы сүзләрне укый, укучылар аның артыннан кабатлыйлар. Авыр сүзләрне аерым укучылардан кабатлаттыра.

2) Укытучы русчасын әйтә, укучылар тәрҗемәсен әйтәләр.

3) Укучылар чылбыр буенча яңа сүзләр белән сүзтезмәләр яки җөмләләр төзеп әйтәләр.

3. Мостай Кәримнең «Билгесез солдат» шигырен сәнгатьле уку.

1) Укытучы сораулар бирә:

— Шигырь кем турында?

— «Билгесез солдат», «ил әниседер» сүзләре нәрсәне аңлата?

— Ни өчен һәйкәлнең «бер күзеннән шатлык нуры сибелә, бер күзеннән әче яшь тама»?

2) Укытучы шигырьне сәнгатьле укып күрсәтә.

3) Шигырьне укучылар үзлекләреннән укыйлар.

4) Шигырьгә укытучы ярдәме белән анализ ясала.

Лирик геройның кичереше, шәхесләр язмышы.

1 нче строфада лирик герой, чыннан да билгесезме солдат һәйкәле, дип, хәтергә, тарихка мөрәҗәгать итә.

2 нче строфада хәтер лирик геройга мәңгелек сынга әйләнүен сөйләп бирә. (Солдатларның көрәшкә күтәрелеп һәлак булуларын сурәтли.)

3 нче строфада лирик герой һәйкәлгә сокланып караучы кошларны, балаларны күзәтә. Балалар — киләчәк буын вәкилләре. Геройлар тыныч тормыш, киләчәк өчен көрәш алып барганнар. Тарих онытылмаган, һәйкәл янындагы чәчәкләр моны раслый.

4 нче строфада автор бер хатынның елавын, борчылуын сурәтли. Лирик герой аны «ил әниседер» дигән фикер әйтә. Ул үз баласы өчен генә түгел, ә бәлки сугыштан кайтмаган миллионларча солдатлар өчен дә кайгыра. Сугышта һәлак булган уллары өчен яшь түгүче ана — җыелма образ.

5 нче строфада лирик герой җиңү шатлыгын — биттәге кояш балкышы белән, югалтуларны моңсу ай белән чагыштыра.

5) — Тексттан «һәйкәл» сүзенең синонимын табыгыз. (Бакыр кеше.)

6) — Шигырьнең соңгы строфасыннан тел-сурәтләү чараларын табыгыз?

Сынландыру — *гөлләр яналар, нур сибелә.*

Чагыштыру — җиңү шатлыгын — биттәге кояш балкышы белән, ә югалтуларны моңсу ай белән чагыштыра.

Риторик өндәү — Җиңү!

Анафора — «бер күзеңнән» юлының кабатлануы.

**III. Рефлексив бәяләү**

1. — Дәрескә куелган уку мәсьәләсе чишелдеме? Нинди образ-

лар белән очраштык? Аларның шигырьдәге рольләрен ачыклау. (Лирик герой, хәтер, билгесез солдат, ил анасы, киләчәк буын.)

2. Бәяләү. Укучыларның дәрестә катнашулары бәяләнеп, билгеләр куела.

3. Өй эше: а) шигырьне сәнгатьле укырга өйрәнергә;

ә) шигырьне ятларга;

б) «Билгесез солдат һәйкәле янында» темасына кечкенә хикәя язарга.

4. Алдагы дәрескә проблема кую.

Укытучы, дәресне тәмамлаганчы, йомгаклап, нәтиҗә ясар өчен сорау бирә:

— Билгесез солдат һәйкәле халкыбыз язмышында нинди роль уйный? (Билгесез солдат һәйкәле — халкыбызның сугыш кырларындагы батырлыгын, патриотизмын һәм милли горурлыгын күрсәтә.)

### Укытучы өчен өстәмә материал

**Лирик әсәр** — эмоциональ, хис-кичерешләргә бай әсәр. Ул төгәл, сәнгатьле, аһәңле сөйләүне сорый, анда һәр сүз аерым бер мәгънәви һәм эмоциональ көчкә ия булырга тиеш. Шигъри сөйләмдә сурәт, тойгы, яңгыраш, ритм, аваз — барысы да әһәмиятле. Лирик әсәрләр кыска, кечкенә күләмле, күп нәрсәне әйтеп бетерми. Анда уйлап, аңлап бетерәсе җирләр дә, бер сүзгә салынган зур эчтәлек тә әһәмиятле. Бу үзенчәлекләр лириканы анализлау нигезендә ята.

Мәктәптә лириканы анализлау — шартлы гамәл. Укучылар белән тулы анализ ясау мөмкин түгел. Лирик әсәр анализлауның иң таралган юлы — «автор артыннан бару». «Бу юл шигырьдәге строфа арты строфаны күзәтергә, алардагы хисне һәм аны тудырган сәбәпне ачыкларга ярдәм итә, хисләр көчешен тоярга, шул көчешкә салынган мәгънәне аңларга булыша», — дип яза Д.Ф.Заһидуллина.

## 24 нче дәрес

**Тема:** Дөньяда бары тик яхшылык кына үлми.

**Планлаштырылган нәтиҗәләр:**

М е т а п р е д м е т — Бөек Ватан сугышы турында тарихи мәгълүмат бирү.

П р е д м е т — Чыңгыз Айтматовның тормыш юлы һәм иҗаты турында белешмә бирү, «Анам кыры» әсәрен өйрәнү.

Ш ә х е с к ә к а г ы л ы ш л ы — укучыларда туган илгә, халкыбыз батырлыгына мәхәббәт хисләре тәрбияләү.

**Материал:** дәреслек (1 нче кисәк, 113—115 нче битләр).

**Җиһазлау:** мультимедиа проекторы, экран, слайдлар: Чыңгыз Айтматов портреты, сугыш чоры фотосурәтләре, китапларыннан күргәзмә.

## Д ә р е с  б а р ы ш ы:

### I. Мотивлаштыру-ориентлаштыру

***1. Дәресне оештыру***

Исәнләшү, хәлләр сорашу, яхшы кәеф теләп, дәресне башлау. Психологик уңай халәт булдыру.

***2. Актуальләштерү***

1) Алдагы дәрестә бирелгән өй эшен тикшерү: укучыларның шигырьне яттан сөйләүләрен тыңлау.

2) Укучылар «Билгесез солдат һәйкәле янында» темасына язып килгән хикәяләрен укыйлар.

— Билгесез солдат һәйкәле халкыбыз язмышында нинди роль уйный?

***3. Уку мәсьәләсен кую***

Укытучы бүген дәрестә Чыңгыз Айтматов иҗаты белән танышачакларын һәм «Анам кыры» әсәрен өйрәнәчәкләрен әйтә.

### II. Уку мәсьәләсен өлешләп чишү

1. Автор белән танышу.

1) Укытучы язучының китапларын күрсәтеп, тормышы һәм иҗаты белән таныштыра.

2) Бер укучы дәреслектән Чыңгыз Айтматов турында белешмәне укый.

3) Укытучы, сораулар ярдәмендә, укучыларның аңлавын тикшерә.

— Чыңгыз Айтматовның хикәяләре ничәнче елда басыла башлый?

— Язучы кайсы уку йортларын тәмамлый?

— Әсәрләре тәрҗемә ителгәнме?

— Кайсы әсәре иҗатчыга танылу алып килә?

— Чыңгыз Айтматовның нинди мактаулы исемнәре бар?

2. Сүзлек белән эш.

1) Укытучы сүзләрне укый, укучылар аның артыннан кабатлыйлар. Авыр сүзләрне аерым укучылардан кабатлаттыра.

2) Укытучы русчасын әйтә, укучылар тәрҗемәсен әйтәләр.

3) Укучылар чылбыр буенча яңа сүзләр белән сүзтезмәләр яки

җөмләләр төзеп әйтәләр.

3. «Анам кыры» әсәренең беренче өлешен уку.

1) Яңа текстны укырга әзерләү: сүзлекчә белән эшләү (дөрес әйтелешне тыңлау, кабатлау, тәрҗемә итү — башта үзләре уйлаганча, аннары дөреслеген тикшерәләр яки тәрҗемәсен китаптан карыйлар).

2) Яңа текстны тыңлау (тәрҗемәсез, анализсыз гына).

— Текстта нәрсә турында сүз бара?

3) Текст буенча сорауларга җавап бирү:

— Тулганайның кемнәре сугышка китә? Алар исәнме?

— Тулганай нинди хисләр кичерә?

— Тулганай ни өчен Җир-анага ялвара? Аны ни борчый?

4. Текст буенча план төзү.

1) Еракта сугыш бара.

2) Тулганай ирен һәм балаларын сугышка озата.

3) Кара кәгазьләр.

4. «Анам кыры» әсәренең икенче өлешен уку.

1) Өзекне рольләргә бүлеп уку.

2) Сүзлек өстендә эш.

3) Җир-ананың кешеләргә мөрәҗәгатен китаптан табып уку.

5. Дәреслектә 115 нче биттән 4—5 нче биремнәрне телдән эшләү.

6. Җир-ана «кешеләрнең сугышсыз яши алулары — кешеләрнең үз иркендә, үз ихтыярында» дигән фикер белдерә. Әлегә сүзтезмәгә карата укучылар фикерен тыңлау.

**III. Рефлексив бәяләү**

1. — Дәрескә куелган уку мәсьәләсе чишелдеме? — Ни өчен әсәр «Анам кыры» дип атала? Нинди образлар белән очраштык? Әсәрнең темасын, жанрын ачыклау.

2. Дәрескә гомуми бәя. Укучыларга билге кую.

3. Өй эше: а) әсәрне сәнгатьле укырга;

ә) әби-бабайлардан сорашып, сугыш китергән авырлыклар турында белешмә әзерләргә;

б) Җир-ана, Тулганай образларына характеристика бирергә.

4. Алдагы дәрескә проблема кую.

Укытучы, дәресне тәмамлаганчы, йомгаклап, нәтиҗә ясар өчен сораулар бирә:

— Чыңгыз Айтматов «Анам кыры» әсәре аша кешеләргә нәрсә әйтергә тели?

— Ана һәм Җир-ана арасында нинди уртаклыклар бар? Ике ананы да нәрсә борчый?

### Укытучы өчен өстәмә материал

Чыңгыз Төрекул улы Айтматов (1928 нче елның 12 нче декабре — 2008 нче елның 10 нчы июне) — кыргыз язучысы. Кыргыз һәм рус телләрендә язган.

Атасы Түрәкол — партия хезмәткәре, 1938 нче елны атып үтерелә. Чыңгыз эне-сеңелләре белән Караколда, бабасы — элеккеге 1 нче гильдия сәүдәгәр — Хәмзә Габделвәлиев йортында үсә.

14 яшьтә, ир-атлар барысы да сугышта чакта, Чыңгыз авыл советы секретаре булган. 1948 нче елда сигезьеллык мәктәпне бетереп, Җамбул шәһәрендәге ветеринария техникумына укырга кергән. Аны гел «бишле»гә тәмамлау сәбәпле, Бишкәктәге авыл хуҗалыгы институтына имтихансыз кабул ителгән, институтны 1953 нче елда тәмамлаган. 1952 нче елда Чыңгызның хикәяләре матбугатта басыла башлаган.

Чыңгыз Айтматов М.Горький исемендәге Әдәбият институты каршындагы югары әдәби курсларны (Мәскәү) тәмамлый. 1988 — 1990 нчы елларда «Иностранная литература» журналының баш мөхәррире, 1990 — 1994 нче елларда — СССР һәм РФның Люксембургтагы илчесе, 1994 нче елдан башлап, Франция һәм Бенилюкс илләрендә Кыргызстан Республикасы илчесе. 1966 —1989 нчы елларда — СССР Югары Советы депутаты, 1989 — 1992 дә — СССР халык депутаты.

### 25 нче дәрес — кабатлау, йомгаклау дәресе

**Тема:** Без азатлык алып биргән көннәр,
Хәтерләми икән кем генә!

**Планлаштырылган нәтиҗәләр:**

Метапредмет — өйрәнелгән материалны искә төшереп, гомумиләштереп куллана белү.

Предмет — «Әтинең зур бүреге иртә киелде...» бүлегендә өйрәнгән материалны кабатлау, үзләштерү дәрәҗәсен билгеләү.

Шәхескә кагылышлы — патриотик тәрбия бирү, туган илне, туган җирне яратырга өйрәтү.

**Материал**: дәреслек (1 нче кисәк, 74—115 нче битләр).

**Җиһазлау**: әлеге бүлектә үтелгән язучылар-ның, рәссамнарның портретлары, төрле әсәрләргә туры килә торган рәсемнәр, аерым битләрдә — тестлар.

**Эпиграф:**

Батырлык һәм тәвәккәллек — ул әхлаклылык һәм ихтыяр

көче, алар һәр кешегә билгеле бер очракта гына түгел, ә көндәлек тормышта, эштә дә кирәк.

*В.А.Сухомлинский*

**Дәрес барышы:**

**I. Мотивлаштыру-ориентлаштыру**

***1. Дәресне оештыру***

Исәнләшү. Хәлләрне сорашу. Уңай психологик халәт булдыру.

***2. Актуальләштерү***

1) Өй эшен тикшерү: алдагы дәрестә өйрәнгән шигырьне сәнгатьле укуларын тыңлау; укучыларның монологларын тыңлау; татарча газета-журналлар турында әңгәмә оештыру.

2) Өстәмә уку өчен бирелгән әсәрләр турында сөйләшү, укучыларның фикерләрен тыңлау.

3) Өйрәнелгән әсәрләр буенча презентацияләр карау.

***3. Уку мәсьәләсен кую***

Дәреснең максаты — бүлекне йомгаклау, тест сорауларына мөстәкыйль рәвештә җавап бирү.

**II. Уку мәсьәләсен өлешләп чишү**

1. Портретлар ярдәмендә, бу бүлектә өйрәнелгән язучыларның исемнәрен хәтердә яңарту.
2. Төрле рәсемнәр ярдәмендә, укылган әсәрләрнең эчтәлеген кабатлау.
3. Тест сорауларына җавап бирү.

**III. Рефлексив бәяләү**

1. Рефлексив кабатлау: тест сорауларына җавапларны тикшерү.
2. Укучыларның үзләренә билге куюы. (Журналга билге тест җавапларын тикшергәч куела.)
3. Өй эше: дәреслектә өстәмә уку өчен бирелгән берәр әсәрне укып килергә.

## 26 нчы дәрес

**Тема:** Җиңүне якынайткан җыр.

**Планлаштырылган нәтиҗәләр:**

М е т а п р е д м е т — сугыш, аның гади халык, балалар җилкәсенә алып килгән авырлыгын аңлау.

П р е д м е т — Клара Булатованың тормыш юлы һәм иҗаты турында белешмә бирү, «Башым иям» шигырен өйрәнү.

Ш ә х е с к ә к а г ы л ы ш л ы — якыннарыңа, туганнарыңа карата ихтирам, мәрхәмәтлелек хисләре тәрбияләү.

**Материал:** дәреслек (118—120 нче битләр).

**Җиһазлау:** К.Булатова портреты, мультимедиа проекторы, слайдлар, видеоязмалар, К.Булатова китаплары.

## Д ә р е с б а р ы ш ы:

**I. Мотивлаштыру-ориентлаштыру**

***1. Дәресне оештыру***

Уңай психологик халәт тудыру.

***2. Актуальләштерү***

1) Өй эшен тикшерү: өстәмә уку өчен бирелгән текстларның эчтәлеге турында фикер алышу.

2) Укытучы, юнәлдерүче сораулар биреп, укучылар белән халкыбызның сугыш кырларында күрсәткән батырлыгы турында әңгәмә оештыра.

— Сугыш турында укыган әсәрләрне исегезгә төшерегез.

— Сез сугышта катнашкан кайсы язучыларны беләсез?

***3. Уку мәсьәләсен кую.***

Укытучы бүген дәрестә сугыш темасы турында сөйләшүне дәвам итәчәкләрен, шагыйрә Клара Булатова иҗаты белән танышачакларын әйтә.

**II. Уку мәсьәләсен өлешләп чишү**

1. Автор белән танышу.

1) Укытучы, шагыйрәнең китапларын күрсәтеп, аның тормышы һәм иҗаты белән таныштыра.

2) Бер укучы дәреслектән Клара Булатова турындагы белешмәне укый.

3) Укытучы, сораулар ярдәмендә, укучыларның аңлавын тикшерә.

118 нче биттәге биографик белешмәгә нигезләнеп, сораулар бирелә. Укучылар үзләре дә сораулар төзиләр.

4) Шагыйрәнең басылып чыккан китап исемнәре атала, дәфтәрләргә теркәлә.

2. Сүзлек белән эш.

1) Укытучы сүзләрне укый, укучылар аның артыннан кабатлыйлар. Авыр сүзләрне аерым укучылардан кабатлаттыра.

2) Укытучы русчасын әйтә, укучылар тәрҗемәсен әйтәләр.

3) Укучылар чылбыр буенча яңа сүзләр белән сүзтезмәләр яки җөмләләр төзеп әйтәләр.

3. «Башым иям» шигырен уку.

1) Укытучы шигырьне сәнгатьле укый.

2) Шигырьне укучылар үзлекләреннән укыйлар.

3) Берничә укучы шигырьне кычкырып укый.

4) Укучылар шигырьне тәрҗемә итәләр.

5) Сорауларга җавап бирү:

— Шигырь нәрсә һәм кемнәр турында?

— Шигырьдәге лирик герой кем? Ул кайсы вакыйгалар турында сөйли?

— Шигырь нинди хисләр белән укыла? (Сагыш — бала чагы сугыш елларына туры килсә дә, автор аны сагынып искә ала, куаныч, борчылу һ.б.) Кайсы хисләр өстенлек итә? Без нинди шигырьләрне шулай укыйбыз?

— Сугыш елларында балалар мәктәпләрдә укыймы? Шигырьдә бу турында нәрсә әйтелә? (Мисалга шигырьдән өзекләр китерелә.)

— Лирик герой мәктәп тормышын ничек сурәтли? Укучылар нәрсә белән һәм нәрсәләрдә язганнар? Аларның дәфтәрләре булганмы?

— Балалар сугыштагы аталарын ничек, нәрсә белән куандырырга тырышканнар? Шул урынны табып, укып күрсәтү.

— Баларның күңелләрен нәрсә тынычландырган, нәрсә аларның җаннарына «ул чак күпме җылы салган»? (Тукай, Такташ, Пушкин шигырьләре.)

— Түбәндәге юлларны ничек аңлыйсыз?

«Салкында да безнең җаннар туңмаганнар
Ач-ялангач өшеп үскән шул заманда»...

— Әлеге әдәби сурәтләү чарасы ничек атала? (Антитеза.)

6) Шигырьнең соңгы ике строфасын яңадан кычкырып уку. Фикер алышу.

— Шигырьдә сүз нинди җыр турында бара? Ул җыр нинди көчкә ия? Сугыш турындагы җырларны исегезгә төшерегез.

**III. Рефлексив бәяләү**

1. Укучылар К.Булатованың биографиясен тагын бер кат исләренә төшерәләр. Шагыйрәнең балачагы сугыш елларына туры килүен ассызыклау, «Башым иям» шигыренең эчтәлеге белән бәйләү.

2. Бәяләү. Укучыларга, дәрестә катнашканнары бәяләнеп, билгеләр куела.

3. Өй эше: а) шигырьне сәнгатьле укырга өйрәнергә;

ә) шигырьне ятларга;

б) «Җиңү бәйрәме» темасына кечкенә хикәя язарга.

4. Алдагы дәрескә проблема кую.

Укытучы, дәресне тәмамлаганчы, йомгаклап, нәтиҗә ясар өчен сораулар бирә:

— Сугыш балаларга ничек тәэсир иткән?

### Укытучы өчен өстәмә материал

Шагыйрә Клара Булатова 1936 нчы елның 18 нче мартында Сарман районы Татар Карамалысы авылында туган. Аның әтисе дә, әнисе дә укытучылар була, шуңа күрә Кларага, бала чактан ук, әти-әниләре белән бергә бер төбәктән икенче төбәккә күчеп йөрергә һәм төрле авыл мәктәпләрендә укырга туры килә. 1944 нче елда ул Сарман районының Югары Чыршылы авылында беренче класска керә, өченче класстан Ләке авылы җидееллык мәктәбендә укый, урта белемне Сарман урта мәктәбендә 1954 нче елда алып чыга. Шул ук елның көзеннән К.Булатова хезмәт юлын башлый — Түбән Ләшәү мәктәбендә башлангыч классларда укыта, аннан соң төзелештә эшли; Әлмәттәге көнкүреш комбинатында — кассир, «Төзүчеләр» клубында оештыручы була. 1962 — 1965 нче елларда ул яңадан мәктәптә — Әлмәт районының Колшәрип авылында тел-әдәбият, тарих укыта. К.Булатованың шигъри иҗаты да нәкъ шул чорда тернәкләнеп китә. Әле мәктәп елларында ук аерым шигырьләре матбугатта күренгән яшь шагыйрә актив рәвештә Әлмәттәге әдәби түгәрәккә йөри һәм, 1956 нчы елдан башлап, «Татарстан яшьләре», «Совет Татарстаны» газеталарында, «Пионер» («Ялкын»), «Азат хатын», «Совет әдәбияты» («Казан утлары») журналларында аның күп кенә шигырьләре дөнья күрә. Бераздан аерым шигъри цикллары «Идел» альманахы, «Яшь үрентеләр» кебек күмәк җыентыкларда басыла.

Ул Казан дәүләт университетының татар теле һәм әдәбияты бүлеген тәмамлый. Аннан ул башы-аягы белән мәктәпкә чума һәм үзенә яңа бер дөнья ача — балалар дөньясы. Балалар күңеле аның җанына яктылык биреп, шигырьләренә нур өсти.

Клара ханымның шигырьләре туган якка, газиз туфрагына тирән мәхәббәт белән сугарылган. Шагыйрә туган ягының гүзәл табигатенә, иксез-чиксез хәзинә байлыкларына, тырыш, хезмәт сөючән, батыр, фидакарь халкына мәдхия җырлый.

## 27—28 нче дәресләр

**Тема:** Тынычлыкның туган көнен
Бәйрәм итә бүген илем.

**Планлаштырылган нәтиҗәләр:**

Метапредмет — Бөек Ватан сугышы, аның гади халыкка китергән авырлыклары турында тарихи мәгълүмат бирү.

Предмет — Нур Әхмәдиевнең тормыш юлы һәм иҗаты турында белешмә бирү, «Җиңү көне» шигырен өйрәнү.

Шәхескә кагылышлы — якыннарына, туганнарына карата ихтирам, мәрхәмәтлелек хисләре тәрбияләү.

**Материал:** дәреслек (121—132 нче битләр).

**Җиһазлау:** Н.Әхмәдиев портреты, мультимедиа проекторы, слайдлар, видеоязмалар, Н.Әхмәдиев китаплары.

### Дәрес барышы:

**I. Мотивлаштыру-ориентлаштыру**

***1. Дәресне оештыру.***

Уңай психологик халәт тудыру.

***2. Актуальләштерү***

1) Өй эшен тикшерү: К.Булатованың «Башым иям» шигырен яттан сөйләү, «Җиңү бәйрәме» хикәясен уку.

2) Укытучы, юнәлдерүче сораулар биреп, укучылар белән сугышның халыкка китергән авырлыклары турында әңгәмә оештыра.

***3. Уку мәсьәләсен кую.***

Укытучы бүген дәрестә сугыш темасы турында сөйләшүне дәвам итәчәкләрен, язучы һәм шагыйрь Нур Әхмәдиев иҗаты белән танышачакларын әйтә.

**II. Уку мәсьәләсен өлешләп чишү**

Авторның иҗаты белән таныштырыла, аның «Җиңү көне» шигыре укыла.

1. Автор белән танышу.

1) Презентация ярдәмендә язучының тормышы һәм иҗаты белән танышу.

2) Бер укучы дәреслектән Нур Әхмәдиев турындагы белешмәне укый.

3) Укытучы, сораулар ярдәмендә, укучыларның аңлавын тикшерә.

4) 123 нче биттәге 1, 2 нче биремнәрне үтәү. Биографик белешмәгә нигезләнеп, сораулар бирелә. Укучылар үзләре дә сораулар төзиләр.

5) Җиңү хәбәре халыкка нинди хисләр алып килде икән? Җиңү бәйрәмен сурәтләү.

2. Шигырьне укырга әзерләнү.

1) Сүзлек эше. Укытучы сүзләрне укый, укучылар аның артыннан кабатлыйлар. Авыр сүзләрне аерым укучылардан кабатлаттыра.

2) Укытучы русчасын әйтә, укучылар тәрҗемәсен әйтәләр.

3) Укучылар чылбыр буенча яңа сүзләр белән сүзтезмәләр яки җөмләләр төзеп әйтәләр.

3. «Җиңү көне» шигырен уку.

1) Укытучы шигырьне сәнгатьле укый.

2) Шигырьне укучылар үзлекләреннән укыйлар.

3) Берничә укучы шигырьне кычкырып укый.

4) Укучылар шигырьне тәрҗемә итәләр.

Укытучы сораулар бирә:

— Шигырь нәрсә һәм кемнәр турында?

— Шигырь нинди хисләр белән укыла? (Шатлык, өмет.)

Кабатланулар булган строфаларны табып, төрләрен билгеләү. Риторик сорау булган җөмләне табып уку, фикер алышу.

5) «Кемгәдер ул салют булып кергән, соңгы ату булгандыр — кемгәдер» юлларын кулланып, автор *җиңү* сүзен атамый. Бу — шигырьгә зур көч, үзенчәлек бирә.

4. — Җиңү көне кайчан бәйрәм ителә? Сезнең ул тантанада булганыгыз бармы?

5. Хис-кичереш, фикерләрне шигырьне укыр алдыннан белдергән фикер белән чагыштыру.

6. «Минем туган көнем хикәясе»н укырга әзерләү: сүзлекчә белән эшләү. Сүзләрне кабатлау, алар белән сүзтезмәләр төзү.

7. Әсәрне чылбырлап уку. Һәр абзацны тәрҗемә итү яки, эчтәлекне аңлаганны тикшерү өчен, сораулар бирү.

8. Хикәяне өлешләргә бүлү, һәр өлешкә исем бирү, план итеп, дәфтәрләргә язып кую. Укучылар, гади җөмләләр белән, һәр бүлекнең кыскача эчтәлеген сөйлиләр.

9. Дәреслекнең 131—132 нче битендәге биремнәрне үтәү, сорауларга җавап бирү. Укучылар үз фикерләрен башта русча әйтергә мөмкиннәр, аннары татарчага тәрҗемә итәләр.

**III. Рефлексив бәяләү**

1. — Дәрескә куелган уку мәсьәләсе чишелдеме? 1946 нчы елның 14 нче декабре язучы өчен нинди көн? (Туган көне.)

— Тарихны хәтердә яңартсак, 1946 нчы ел илебез өчен кайсы ягы белән истә калган дип уйлыйсыз? (Сугыштан соңгы авыр еллар. Тол калган хатыннар, әтиләрен югалткан ятим балаларның ачлык-ялангачлыктан тилмергән вакыты.)

— Бу еллар яшәү өчен авыр булса да, ватандашларыбыз көр күңеллелек, игелеклелек, эш сөючәнлек сыйфатларын җуймаган.

— Ничек уйлыйсыз: ул вакытта халыкта туган көн бәйрәмен билгеләп үтү гадәте булды микән? (Юк, ул вакытта сирәк кешеләр генә туган көнен бәйрәм иткән, күпләр исә мондый бәйрәмне оештыруның тәртибен дә белмәгән.)

2. Бәяләү. Укучыларга, дәрестә катнашканнары бәяләнеп, билгеләр куела.

3. Өй эше: а) шигырьне сәнгатьле укырга өйрәнергә;

ә) хикәянең кыскача эчтәлеген сөйләргә өйрәнергә;

б) «Минем туган көнем» темасына кечкенә хикәя язарга.

## 29 — 30 нчы дәресләр

**Тема:** Шәфкатьлелек бизи кешене!

**Планлаштырылган нәтиҗәләр:**

М е т а п р е д м е т — текст белән эшләү, иң әһәмиятлесен таба белергә өйрәнү.

П р е д м е т — Факил Сафинның тормыш юлы һәм иҗаты турында белешмә бирү, «Тулганай» әсәрен өйрәнү.

Ш ә х е с к ә к а г ы л ы ш л ы — якыннарыңа, туганнарыңа карата ихтирам, мәрхәмәтлелек хисләре тәрбияләү.

**Материал:** дәреслек (132—140 нчы битләр).

**Җиһазлау:** Ф.Сафин портреты, мультимедиа проекторы, слайдлар, видеоязмалар, Ф.Сафинның басма китаплары.

### Д ә р е с б а р ы ш ы:

**I. Мотивлаштыру-ориентлаштыру**

***1. Дәресне оештыру.***

Уңай психологик халәт тудыру.

***2. Актуальләштерү***

1) Өй эшен тикшерү: укучылар үзләренең туган көннәрен ничек уздырулары турында сөйлиләр.

2) Укытучы, юнәлдерүче сораулар биреп, укучылар белән сугышның халыкка китергән авырлыклары турында әңгәмә оештыра.

3) Һәр дәрестә, яңа бүлекне укый башлаганчы, автор турында, алда укылган бүлекләр эчтәлеге буенча кыска әңгәмә.

***3. Уку мәсьәләсен кую.***

Укытучы бүген дәрестә сугыш темасы турында сөйләшүне дәвам итәчәкләрен, язучы Факил Сафин иҗаты белән танышачакларын әйтә. Бергәләп, дәрескә бурычлар кую.

**II. Уку мәсьәләсен өлешләп чишү**

1. Авторның биографиясе белән танышу.

1) Презентация ярдәмендә, язучының тормышы һәм иҗаты белән танышу.

2) Бер укучы дәреслектән Факил Сафин турындагы белешмәне укый.

3) Укытучы, сораулар ярдәмендә, укучыларның аңлавын тикшерә.

Биографик белешмәгә нигезләнеп, сораулар бирелә. Укучылар үзләре дә сораулар төзиләр.

Бу дәресләрнең һәркайсында повестьның яңа бер бүлеге укыла.

2. Яңа текстны укырга әзерләү: сүзлекчә белән эшләү (дөрес әйтелешне тыңлау, кабатлау, тәрҗемә итү — башта үзләре уйлаганча, аннары дөреслеген тикшерәләр яки тәрҗемәсен китаптан карыйлар). Яңа сүзләр белән сүзтезмәләр, җөмләләр төзү.

3. Һәр абзацны уку, тәрҗемә итү.

4. Дәреслектәге биремнәрне үтәү, сорауларга җавап бирү (136, 140 нчы бит).

— Малайларның әтиләре көчек турында белгәч куанамы? Җавабыгызны дәлилләгез. (Әсәрдән моны сурәтләгән урыннарны табып уку.) Камил белән Фирүз көчекне нинди теләк белән үзләрендә калдырырга уйлыйлар? Чыннан да көчек малайларга бакча саклар өчен генә кирәк буламы?

— Әсәрдәге һәр герой өчен Тулганай аерым теләк, хыял, истәлекләр ролен уйный. Шуны ачыклар өчен, таблицаны тутырыйк.

| Камил, Фирүз | Әниләре | Әтиләре |
|---|---|---|
| Бакчаны саклау — малайлар өчен көчекне калдыру сәбәбе генә. Нигездә малайларның этле булу теләге ята. | Көчек балачакта умарталыкларын саклаган этне хәтерләтә. Шуңа күрә көчеккә Тулганай кушаматы бирелә. | Бакчаны сакларга булса — ярый, дигән фикер белән ризалаша. |

— Әниләренең эт турында «каргышы төшәр» сүзләрен ничек аңлыйсыз? Нәрсә ул каргыш?

**III. Рефлексив бәяләү**

1. — Дәрескә куелган уку мәсьәләсе чишелдеме? Факил Сафин турында нәрсәләр белдегез? «Тулганай» әсәренең исеме нәрсә белән бәйле?

2. Бәяләү. Укучыларга, дәрестә катнашканнары бәяләнеп, билгеләр куела.

3. Өй эше: а) хикәяне сәнгатьле укырга өйрәнергә;

ә) хикәянең кыскача эчтәлеген сөйләргә;

б) кичергән зур шатлыклары турында кечкенә хикәя язарга.

## 31 нче дәрес

**Тема:** Таң булып нур сибә Ватаным.

**Планлаштырылган нәтиҗәләр:**

М е т а п р е д м е т — сугыш, аның гади халык, балалар җилкәсенә алып килгән авырлыгын аңлау.

П р е д м е т — Разил Вәлиевнең тормыш юлы һәм иҗаты турында белешмә бирү, «Ватаным» шигырен өйрәнү.

Ш ә х е с к ә  к а г ы л ы ш л ы — туган ил белән горурлану, аның тарихы белән кызыксыну, туган җиргә мәхәббәт хисе тәрбияләү.

**Материал:** дәреслек (141—143 нче битләр)

**Җиһазлау:** Р.Вәлиев портреты, мультимедиа проекторы, слайдлар, видеоязмалар, Р.Вәлиевнең китаплары.

### Д ә р е с  б а р ы ш ы:

**I. Мотивлаштыру-ориентлаштыру**

***1. Дәресне оештыру.***

Уңай психологик халәт тудыру.

***2. Актуальләштерү***

1) Өй эшен тикшерү: укучылар үзләре кичергән зур шатлык турында язып килгән хикәяләрен укыйлар.

2) Укытучы, юнәлдерүче сораулар биреп, укучылар белән халкыбызның сугыш кырларында күрсәткән батырлыгы турында әңгәмә оештыра.

— Сугыш турында укыган әсәрләрне исегезгә төшерегез.

— Сез сугышта катнашкан кайсы язучыларны беләсез?

***3. Уку мәсьәләсен кую.***

1. Мәкальләр уку, аңлату һәм дәреснең темасын ачыклау.

(Экранда — слайд: Ватан, туган җир турында мәкальләр.)

* Ватанга хезмәт — үзеңә хезмәт.
* Иле ныкның биле нык.
* Иленнән аерылган — канаты каерылган.
* Туган җирдәй җир булмас,
  Туган илдәй ил булмас.
* Туган илең — туган анаң.
* Туган илнең кадерен читтә йөрсәң белерсең.

— Димәк, дәрестә сүз нәрсә турында барачак? (Ватан, туган ил турында.)

Алдагы сыйныфларда Ватан турында өйрәнелгән әсәрләр искә төшерелә.

Бүгенге дәрестә Р.Вәлиевның тормыш юлы, иҗаты белән танышу һәм аның «Ватаным» дигән шигырен уку турында әйтелә.

**II. Уку мәсьәләсен өлешләп чишү**

1. Автор белән танышу.

1) Укытучы, шагыйрьнең китапларын күрсәтеп, аның тормышы һәм иҗаты белән таныштыра.

2) Бер укучы дәреслектән Разил Вәлиев турындагы белешмәне укый.

3) Укытучы, сораулар ярдәмендә, укучыларның аңлавын тикшерә.

141 нче биттәге биографик белешмәгә нигезләнеп, сораулар бирелә. Укучылар үзләре дә сораулар төзиләр.

— Язучылык эшеннән тыш ул тагын нинди хезмәтләр башкарган?

2. Сүзлек белән эш.

1) Укытучы сүзләрне укый, укучылар аның артыннан кабатлыйлар. Авыр сүзләрне аерым укучылардан кабатлаттыра.

2) Укытучы русчасын әйтә, укучылар тәрҗемәсен әйтәләр.

3) Укучылар чылбыр буенча яңа сүзләр белән сүзтезмәләр яки җөмләләр төзеп әйтәләр.

3. «Ватаным» шигырен уку.

1) Укытучы шигырьне сәнгатьле укый.

2) Шигырьне укучылар үзлекләреннән укыйлар.

3) Берничә укучы шигырьне кычкырып укый.

4) Укучылар шигырьне тәрҗемә итәләр.

4. Дәреслектәге сорау һәм биремнәрне үтәү (142—143 нче битләр).

— Шигырь нәрсә турында?

— Шигырь нинди хисләр белән укыла? (Мәхәббәт, горурлык.)

— Түбәндәге юлларны ничек аңлыйсыз?

«Кешеләр күтәрде Ватанны,
Кешене күтәрде Ватаным...»

— Ни өчен автор «Ватан» сүзен һәр строфада куллана? (Бу — шигырьнең көчен билгели, аһәңлелек бирә.)

— «Батырлар утларга керделәр» җөмләсен ничек аңлыйсыз?

— Сорасалар, сез кайсы батырлар исемен атар идегез?

5. Шигырьнең соңгы ике юлын яңадан кычкырып уку. Фикер алышу.

6. Шигырь буенча сораулар төзү, җавап бирү (парларда эшләү).

— Батырлар ни өчен утларга кергән? (Тексттан табып, җавап бирәләр.)

— Ни өчен лирик герой җиргә нык басып йөри? (Иленең хуҗасы булганга.)

— Ватанны кем күтәрә? (Кешеләр.)

7. — Беренче строфада «сугыш» сүзенең синонимын табыгыз.

**III. Рефлексив бәяләү**

1. — Дәрескә куелган кайсы уку мәсьәләсе чишелде? Разил Вәлиев турында нәрсәләр әйтә аласыз? «Ватаным» шигыре сезгә ошадымы?

2. Бәяләү. Укучыларга, дәрестә катнашканнары бәяләнеп, билгеләр куела.

3. Өй эше: а) шигырьне сәнгатьле укырга өйрәнергә;

ә) шигырьне ятларга;

б) бүлекне (автор, әсәрләрне) искә төшерергә.

### Укытучы өчен өстәмә материал

Р.Вәлиевның әсәрләре 1960 нчы елларда басыла башлый. Төп жанры — шигърият. Разил Вәлиев — гражданлык хисләрен ачык белдерүче шагыйрьләрдән. Аның «Зәңгәр кабырчыклар (1971), «Яшен тамыры» (1977), «Ядкарь» (1987), «Бер алманы бишкә бүләек» (1992), «Кышкы учак» (1994), «Сүзләрдән дисбе» (1996) шигырь җыентыклары; «Эт кояшы», «Яшисе килә» (1982) һ.б. повестьлары һәм «Мирас» (1990) романы дөнья күрде.

Разил Вәлиевнең иҗаты драматургия белән дә бәйле. Аның «Әйдә, барыйк, кызлар карыйк!» (1988 — 1989) , «И машина, машина, җитте минем башыма» (1990), «Куркыныч уен» («Шомбай», 1989) һ.б. пьесалары 4 томда басылып чыккан «Сайланма әсәрләр»дә (1999 — 2000) урын алды. Р.Вәлиев пьесаларына куелган спектакльләр К.Тинчурин исемендәге драма һәм комедия театрында, шулай ук республиканың башка театрларында уңыш казанды.

Разил Вәлиев, киңкырлы эшчәнлеге өчен, «Планетада цивилизацияне, яшәешне һәм мәдәниятне саклауга һәм үстерүгә керткән хезмәтләре өчен» халыкара көмеш медаль белән бүләкләнде.

### 32 нче дәрес — кабатлау, йомгаклау дәресе

**Тема:** Җиңү көне җиңел бирелмәде...

**Планлаштырылган нәтиҗәләр:**

Метапредмет — өйрәнелгән материалны искә төшереп, гомумиләштереп куллана белү.

Предмет — әлеге бүлектә өйрәнгән материалны кабатлау, үзләштерү дәрәҗәсен билгеләү.

Шәхескә кагылышлы — патриотик тәрбия бирү, туган илне, туган җирне яратырга өйрәтү.

**Материал:** дәреслек (1 нче кисәк, 118—143 нче битләр).

**Җиһазлау:** К.Булатова, Н.Әхмәдиев, С.Хәким, Ф.Сафин, Р.Вәлиев портретлары, төрле әсәрләргә туры килә торган рәсемнәр, аерым битләрдә тестлар.

### Дәрес барышы:

**I. Мотивлаштыру-ориентлаштыру**

***1. Дәресне оештыру***

Исәнләшү. Хәлләрне сорашу. Уңай психологик халәт булдыру.

***2. Актуальләштерү***

1) Өй эшен тикшерү: алдагы дәрестә өйрәнгән шигырьне сәнгатьле укуларын тыңлау; укучыларның монологларын тыңлау.

2) Өйрәнелгән әсәрләр буенча презентацияләр карау.

***3. Уку мәсьәләсен кую.*** Дәреснең максаты — бүлекне йомгаклау, мөстәкыйль рәвештә тест сорауларына җавап бирү.

**II. Уку мәсьәләсен өлешләп чишү**

1. Портретлар ярдәмендә, бу бүлектә өйрәнелгән язучыларның исемнәрен хәтердә яңарту.

2. Төрле рәсемнәр ярдәмендә, укылган әсәрләрнең эчтәлеген кабатлау.

3. Тест сорауларына җавап бирү.

**III. Рефлексив бәяләү**

1. Рефлексив кабатлау: тест сорауларына җавапларны тикшерү.

2. Үзбәя (укучыларның үзләренә билге куюы). Журналга билге тест җавапларын тикшергәч куела.

3. Өй эше: а) дәреслектә өстәмә уку өчен бирелгән берәр әсәрне укырга;

ә) сорауларга язмача җавап бирергә;

б) «Җиңү» бүлеге буенча тестларга җавап бирергә.

## 33 нче дәрес

**Тема:** Бәхет эзләгәндә.

**Планлаштырылган нәтиҗәләр:**

М е т а п р е д м е т — тарихи вакыйгаларга нигезләнеп, әсәр геройлары яшәгән чорга характеристика бирү.

П р е д м е т — Шәриф Камалның тормышы һәм иҗаты белән танышу, «Буранда» хикәясен уку.

Ш ә х е с к ә к а г ы л ы ш л ы — геройларның яшәү кыйбласы аша нәтиҗәләр ясау һәм укучыларда әниләргә карата шәфкатьлелек, миһербанлылык хисләре тәрбияләү.

**Материал:** дәреслек (2 нче кисәк, 8—10 нчы битләр).

**Җиһазлау:** мультимедиа проекторы, экран, слайдлар: язучының портреты, әсәрләреннән китаплар күргәзмәсе, иллюстрация, дәреслек, мәкальләр, плакат (хис төрләре), магнитофон, әниләргә багышланган әсәрләр.

## Дәрес барышы:

**I. Мотивлаштыру-ориентлаштыру**

***1. Дәресне оештыру***

Дәресне башлау. Психологик уңай халәт тудыру.

***2. Актуальләштерү***

1) Өй эшен тикшерү: өстәмә уку өчен бирелгән әсәрнең эчтәлеге буенча әңгәмә оештыру. Укучыларга әсәр эчтәлеген аңларга ярдәм итү.

2) Укытучы, юнәлдерүче сораулар биреп, укучылар белән әниләр, аларның һәркем өчен дә кадерле булуы турында әңгәмә оештыра.

— Әдәбиятта әниләр темасы бик күп әсәрләрдә чагыла. Ни өчен кешегә әнисе кадерле икән? (Укучыларның фикерләре.)

— Әниләргә багышланган нинди әсәрләр беләсез? («Сак-Сок» бәете, легендалар, «Анам кыры» (Ч.Айтматов) һ.б.)

***3. Уку мәсьәләсен кую***

Укытучы бүген дәрестә язучы Шәриф Камал иҗаты белән танышачакларын әйтә.

Дәреснең темасы — Шәриф Камалның «Буранда» хикәясе белән таныша башлау.

Темадан чыгып, дәрескә уку мәсьәләсен укучылар белән бергәләп кую.

1) Шәриф Камалның тормыш юлы, иҗаты белән танышу.

2) «Буранда» хикәясенең беренче бүлеген уку, аңлау.

**II. Уку мәсьәләсен өлешләп чишү**

1. Язучының иҗаты, тормыш юлы турында мәгълүмат.

1) — Шәриф Камал турында ишеткәнегез бармы?

2) Язучы турында презентация карау яки укытучының портрет, китапларын күрсәтеп сөйләве.

3) Дәреслектәге биографик белешмә белән укучыларның танышуы. Сорауларга җавап бирү: укучылар үзләре сораулар төзиләр, парларда җавап бирәләр.

4) Сүзлек өстендә эш.

5) Хронологик таблица төзү.

6) Дәреслектән 2, 3 нче биремнәрне эшләү.

2. «Буранда» хикәясенең беренче бүлеген уку.

1) — Хикәя дип нинди әсәр атала? (Кечкенә вакыйгаларны үз эченә алган кечкенә күләмле чәчмә әсәр.)

2) — Хикәягә анализ ясау алымнарын да искә төшерик. (Вакыйгаларны барлау, вакыйгаларның охшашларын гомумиләштереп,

ике өлешкә калдыру, һәр өлешне аерым-аерым өйрәнү, өлешләре арасында бәйләнеш эзләү, өлешләр бәйләнешеннән эчтәлек табу, әсәрнең темасын, проблемасын, идеясен табу.)

3) 1 нче абзацны укытучының сәнгатьле укуы, укучылар, күз йөртеп, карап баралар, тыңлыйлар.

— Хикәя ничек башлана? Нинди образлар белән очрашабыз?

4) Укучылар әсәрне чылбыр буенча укыйлар. Һәр абзацка аңлатма бирелә, тәрҗемә ителә. Укылган өлеш буенча сорауларга җавап бирәләр.

5) Әсәрнең кайбер абзацларының һәр җөмләсен уку, сүзлекчәне кулланып, сүзгә-сүз русчага тәрҗемә итү.

6) Һәр абзац белән танышып чыккач, дәреслектәге сораулар һәм биремнәр белән эшләү.

3. Беренче өлеш буенча план төзү.

1) Мостафаның дустына керүе.

2) Юлга әзерләнү.

4. Беренче өлешкә исем куярга, сөйләргә.

5. — Бүлектәге образларга тукталыйк. Образларга характеристика биргәндә, без нәрсәләргә игътибар итәбез?

— Иң элек, бүлектәге образларны ике төркемгә бүләбез: төп һәм ярдәмче образлар, актив һәм пассив образлар (актив образлар — Мостафа, Хөсәен, Гайшә; ярдәмчеләр — бала елау, көчле буран, төн үтеп, яктыру).

6. Беренче өлештәге фразеологизмнарны рус теленә тәрҗемә итү һәм аңлауга ирешү.

7. Магнитофон язмасында җыр тыңлау: «Синең куллар» (И.Шакиров башкаруында).

**III. Рефлексив бәяләү**

1. — Дәрескә куелган уку мәсьәләсе чишелдеме?

### Тест

1. Шәриф Камал ничәнче елда туган?
— 1878;
— 1886;
— 1884.
2. Шәриф Камал кайда туган?
— Башкортстан Республикасында;
— Мордва Республикасында;
— Казанда.
3. Шәриф Камал кайда белем ала?

— «Мөхәммәдия» мәдрәсәсендә;
— Авыл мәдрәсәсендә;
— «Күл буе» мәдрәсәсендә.
4. «Буранда» әсәре ничәнче елда язылган?
— 1912;
— 1902;
— 1909.
5. Шәриф Камал кем ул?
— Шагыйрь;
— укытучы;
— язучы, драматург.
2. Дәрескә гомуми бәя. Укучыларга билге кую.
3. Өй эше: а) беренче өлешне сәнгатьле укырга;
ә) укылган өлешнең эчтәлеген сөйләргә;
б) Шәриф Камалның тормышын һәм иҗаты турында сөйләргә.
4. Алдагы дәрескә проблема кую. Укытучы, дәресне тәмамлаганчы, йомгаклап, нәтиҗә ясар өчен сораулар бирә:
— Ни өчен дәреснең темасы «Бәхет эзләгәндә» дип атала? (Шәриф Камалның тормышы белән бәйләп аңлатырга.)
— Мостафа кая ашыга?
— Бала елавы Мостафага ничек тәэсир итә? (Бала елау Мостафага әнисен искә төшерә.)

### Укытучы өчен өстәмә материал

**Шәриф Камал** (Шәриф Камалетдин улы Байгилдиев) — татар әдәбияты классигы, язучы һәм драматург.

Шәриф Камал 1884 нче елда Мордва Республикасының Рузаевка районы Татар Пешләсе авылында туа. Ләбәжә һәм Түбән Пешлә мәдрәсәләрендә белем ала. 16 яшендә атасы белән ачуланышып, Петербург-Казан тимер юл төзелешенә китеп урнаша. Аннары Истанбулдагы дарелмөгаллиминдә (педагогия институты) укуын дәвам итә. Икенче курстан соң, Шәриф Каһирәгә китә, андагы университетның ирекле тыңлаучысы була. Матди кыенлыкларга, 1905 нче елда Россиягә әйләнеп кайта. Санкт-Петербургта яшәүче абыйсы Гыймади Байгилдиев белән бергә мөгаллимлек кыла, соңыннан «Нур» газетасында хезмәт итә: мәкаләләр яза, тәрҗемә белән шөгыльләнә, шигырьләр иҗат итә. 1906 нчы елда «Садә» («Аваз») исемле шигырьләр мәҗмугасы дөнья күрә. Моңарчы Ш.Камалның әсәрләре белән «Шура» журналы аша таныш булган шагыйрь, иганәче, алтынчы Закир Рәмиев чакыруы буенча, әдип 1910 нчы елда Оренбургка китә. Анда бертуган Закир һәм Шакир Рәмиевләр нәшер иткән «Вакыт» матбугатында хисапчы, корректор, әдәби хезмәткәр булып эшли. Бер үк вакытта әлеге

газета һәм «Шура» журналы битләрендә актив рәвештә үзенең әсәрләрен бастыра. Сәхнә әсәрләре дә дөнья күрә: «Акчарлаклар» (1914), «Хаҗи әфәнде өйләнә» (1915). Соңгы пьесаны зур уңыш белән Габдулла Кариев «Сәйяр»дә сәхнәләштерә. Бу әсәр революциягә кадәрге татар комедиясенең өлгесе булып санала.

Язучының Октябрь инкыйлабына кадәрге иҗаты татар әдәбиятының тематик колачын һәм сәнгатьчә сурәтләү алымнарын сизелерлек киңәйтеп җибәрә. Ш.Камалның татар әдәбиятында кыска хикәя жанрын үстерүгә керткән өлеше аеруча зур. Тирән психологизм, эмоциональ-лирик моң, мәгънәви тирәнлек, композицион җыйнаклык һәм тыгызлык — әдипнең әсәрләренә әнә шул сыйфатлар хас. Кыска хикәя остасы буларак, ул А.Чеховтан өйрәнсә, күләмле әсәрләр авторы буларак М.Горькийны үзенең остазы дип саный.

Шәриф Камал 1925 нче елдан — Казанда. Биредә ул соцреализм рухында әсәрләр яза: «Матур туганда», «Таң атканда» романнары, «Таулар», «Ут», «Козгыннар оясында», «Томан арты» пьесалары. М.Шолоховның «Күтәрелгән чирәм»ен тәрҗемә итә.

1934 нче елда СССР Язучылар берлегенә алына. «Халык дошманнары» Кәрим Тинчурин, Кави Нәҗми, Гомәр Гали белән «элемтә тоткан өчен», ВКП(б)дан чыгарыла. 1950 нче елда Островский урамындагы квартиры әдипнең музей йорты ителә.

## 34 нче дәрес

**Тема:** Исән чакта белү кирәк икән
Әти-әниләрнең кадерен.

**Планлаштырылган нәтиҗәләр:**

Метапредмет — укыган әсәрне бүгенге көн, көндәлек тормыш белән бәйләнештә күзаллый белү. Әдәби деталь турында теоретик төшенчә бирү.

Предмет — Шәриф Камалның «Буранда» хикәясен өйрәнү.

Шәхескә кагылышлы — укучыларда өлкән буынга, әниләргә кече яшьтән шәфкатьлелек, миһербанлылык хисләре тәрбияләү.

**Материал:** дәреслек (2 нче кисәк, 10—16 нчы битләр).

**Җиһазлау:** мультимедиа проекторы, экран (такта), Шәриф Камал портреты, иллюстрация, дәреслек, мәкальләр.

### Дәрес барышы:

**I. Мотивлаштыру-ориентлаштыру**

***1. Дәресне оештыру***

Дәресне башлау. Психологик уңай халәт тудыру.

***2. Актуальләштерү***

1) Өй эшен тикшерү:

а) Шәриф Камалның тормышы һәм иҗаты буенча сорауларга җавап бирү;

ә) әсәрнең эчтәлеге буенча әңгәмә оештыру. Укучыларга әсәр эчтәлеген аңларга ярдәм итү. Беренче бүлектәге төп вакыйгалар искә төшерелә, эчтәлеге сөйләнелә.

***3. Уку мәсьәләсен кую***

— Бүгенге дәреснең темасы — Шәриф Камалның «Буранда» хикәясен укуны дәвам итү.

1) Темадан чыгып, дәрескә уку мәсьәләсен укучылар белән бергәләп кую.

2) «Буранда» хикәясен уку, аңлау, анализлау.

3) Әдәби деталь турында теоретик төшенчәне истә калдыру.

**II. Уку мәсьәләсен өлешләп чишү**

1. Шәриф Камалның «Буранда» хикәясен укуны дәвам итү.

1) Укучылар әсәрне чылбыр буенча укыйлар. Һәр абзацка аңлатма бирелә, тәрҗемә ителә. Укылган өлеш буенча сорауларга җавап бирәләр.

2) Әсәрнең кайбер абзацларының һәр җөмләсен уку, сүзлекчәне кулланып, сүзгә-сүз русчага тәрҗемә итү.

3) Һәр абзац белән танышып чыккач, дәреслектәге сораулар һәм биремнәр белән эшләү.

4) Әдәби деталь, әдәбиятта психологизм турында теоретик төшенчәне уку, истә калдыру.

2. Хикәя буенча план төзү:

а) Мостафаның дустына керүе;

ә) юлга әзерләнү;

б) буран булуга карамастан, юлга чыгуы, уйлары;

в) әнисенең үлеме.

3. Ярдәмче (кечкенә) вакыйгаларны табу:

а) бала елау;

ә) көчле буран;

б) төн үтеп, яктыру.

— Ярдәмче вакыйгалар әсәрдә нинди роль үти? Алар Мостафага ничек тәэсир итә?

а) Бала елау — Мостафага әнисен искә төшерә, аны шул төн үзгәртә. Чөнки ул моңарчы гамьсез, кешедән көлә торган, кеше

сөйләгәнгә ышанмый, тыңламый торган салкын җанлы кеше була. Яшь ана Гайшә төне буе бала янында була, аны юата, тынычландырырга тели, җитмәсә ире, кунагы өчен дә борчыла. Мостафа, минем әнием дә шулай, төннәрен йокламыйча, мине юаткандыр, борчылгандыр, яраткандыр, дип уйлый башлый.

ә) Буран — бер көчәя, бер тынгандай була, аннан тагын көчәя. Буран геройның авыр хисләрен, анасы турында уйларын көчәйтә.

б) Таң ату — Мостафаның авыр хисләреннән арынуы, хатасын аңлавы һәм тизрәк, бүген үк, әнисе янына кайтып, аннан гафу үтенергә теләве.

Ярдәмче вакыйгалар метафора ролен үтиләр.

4. Мостафага һәм әнисенә бәя бирү.

Мостафа — салкын бәгырьле, анасын рәнҗеткән бәхетсез, мескен кеше. Әнисе бала җанлы, мәрхәмәтле, кичерә белүче, гомер буе Мостафаны сагына, ярата, чөнки бала ана өчен бик кадерле.

5. Хикәянең төзелешенә игътибар итү.

— Әсәр ничек башлана, ахыры ничек бетә? Аларның аермасы һәм охшашлыгы нәрсәдә?

— Хикәянең башында яшь бала елый, аны юатучы әнисе бар, ахырда — Мостафа елый. Ул инде зур кеше, ләкин анасы өчен ул барыбер бала, аны инде юатучы юк.

6. Әсәрдә арттыру алымын табу. Буран котыруы, төн буе бала елау, авыр уйлар, ананың үлеме дә — бер көндә булган хәлләр. Билгеле, автор хикәяне башка төрле итеп үзгәртә алыр иде. Ләкин ул аны үзе теләгәнчә язган. Авторның тормыштагы чынбарлыкны хыялдагычага үзгәртеп, арттырып сурәтләвен «романтизм» диләр. (*Романтизм* сүзенең аңлатмасы тактада языла.)

7. Татар халкында аналар турында матур, тирән мәгънәле гыйбарәләр, мәкальләр бар. Әйдәгез, шуларны укып, аңлатма биреп карыйк әле. (Плакатта язылган мәкальләрне укучы үзе белгәнчә аңлата.)

* Ана — бөек исем. *(Һ.Такташ)*

* Ана күңеле балада, бала күңеле далада.

* Анага бала алтыда да бала, алтмышта да бала. (Хикәя белән дә бәйләргә мөмкин.)

* Җәннәт — аналарның аяк астында.

* Анаңны рәнҗетсәң, бәхетсез булырсың.

8. Интернет челтәреннән Алсу Әбелханова башкаруында «Әти-әниләрнең кадерен белик» җырын тыңлау.

**III. Рефлексив бәяләү**

1. — Дәрескә куелган уку мәсьәләсе чишелдеме?

— Әсәрнең эчтәлеге нәрсә турында? (Әсәрнең эчтәлеге Мостафаның хисләре, кичерешләре турында.)

— Бу әсәр белән язучы нәрсә әйтергә теләгән? Авторның идеясен табыйк. (Автор, әниегезне беркайчан да рәнҗетмәгез, мәңге бәхетсез булырсыз, һәм бу бәхетсезлектә сезгә беркем дә ярдәм итә алмас, ди.)

2. Бәяләү. Укучыларга, дәрестә катнашканнары бәяләнеп, билгеләр куела.

3. Өй эше: а) 2—3 нче өлешне укырга, план буенча сөйләргә;

ә) дәреслекнең 11 нче битендәге рәсемдә тасвирланган вакыйгаларны сөйләргә;

б) Шәриф Камалның «Буранда» новелласы турында укырга, фикер алышырга.

4. Алдагы дәрескә проблема кую.

Укытучы, дәресне тәмамлаганчы, йомгаклап, нәтиҗә ясар өчен сораулар бирә:

— Әсәрнең темасын хикәянең исеменнән табыйк. Буран метафора буларак кулланылган. Ул геройның хисләрен көчәйтә, дидек. Тагын нинди мәгънә белдерә микән?

— Буран кешене юлда адаштыра, һәм кеше бәхетсезлеккә дучар була. (Өшергә, туңып үләргә дә мөмкин.) Әсәрнең темасы — тормыш юлында адашкан ялгыз кешенең бәхетсезлеге, мескенлеге.

— Бу әсәр безне нәрсәгә өйрәтә?

— Әсәр безне әниләрне беркайчан да авыр сүзләр әйтеп рәнҗетмәскә, аларны хөрмәт итәргә, миһербанлы, шәфкатьле булырга өйрәтә.

## 35 — 36 нчы дәресләр

**Тема:** Тетрәндергеч еллар авазы.

**Планлаштырылган нәтиҗәләр:**

М е т а п р е д м е т — әсәрдәге вакыйгалар һәм геройлар аша шәхес культы фаҗигасен ачу; гаделсезлекләрне күрә, аңлый һәм дөрес бәяли белергә өйрәтү.

П р е д м е т — Ибраһим Салахов иҗаты белән танышу, «Колыма хикәяләре» циклыннан «Ана тавышы» өзеген анализлау.

Ш ә х е с к ә к а г ы л ы ш л ы — халкыбызның үткәненә, тарихына аңлы караш булдыру, әхлак тәрбиясе бирү; аналарга тирән мәхәббәт, кешелеклелек, кече күңеллелек, миһербанлылык хисләре тәрбияләү.

**Материал:** дәреслек (2 нче кисәк, 16—19 нчы битләр).

**Җиһазлау:** мультимедиа проекторы, экран (такта), репрессия еллары турында язылган, язучы иҗатын чагылдырган китаплар, газета-журнал материаллары, китаплар күргәзмәсе; Интернеттан алынган материаллар.

**Эпиграф:**

Китап битләрендә гасырлар бер йодрыкка сыя.
Йодрыктан тарих битенә кан тама.

*Марсель Галиев*

**Д ә р е с б а р ы ш ы:**

**I. Мотивлаштыру-ориентлаштыру**

***1. Дәресне оештыру***

Дәресне башлау. Психологик уңай халәт тудыру.

***2. Актуальләштерү***

Өй эшен тикшерү:

1. Шәриф Камалның «Буранда» хикәясенә ясалган рәсем буенча чыгышларны тыңлау.

2. Укытучы, юнәлдерүче сораулар биреп, укучылар белән репрессия еллары турында әңгәмә кора.

— Репрессияләнгән язучылардан кемнәрне беләсез?

— Язучылар ни өчен кулга алынган?

— Гурий Тавлин иҗатын искә төшереп сөйләгез.

— Укучылар, сезнең, елга ярына басып, дулкыннарга карап торганыгыз бармы? Ярсу җилләр бу дулкыннарга килеп бәреләләр дә әле ярга китереп сылыйлар, әле елга эченә алып кереп китәләр, әле су тамчыларын зәңгәр күккә күтәрәләр. Без, кешеләр дә, тормыш диңгезенең дулкыннары бит. Язмыш җилләре безне дә әле — бер, әле икенче ярга китереп сылый, әле күккә күтәрә, әле язмышның караңгы төпкеленә батыра. Була шундый кешеләр: язмыш богауларыннан ычкына алмыйча, тәгъдир хөкеменә буйсыналар. Була шундый шәхесләр: үзенә язылган язмыш сынауларын җиңеп, сыгылмыйча, сынмыйча, алга — биеккә күтәреләләр. Мин Гури Тавлин белән Ибраһим Салаховны шундый шәхесләр дияр идем.

Ибраһим Салахов яшәп иҗат иткән чор шактый катлаулы, четерекле. Галимнәр Сталин репрессиясе яки шәхес культы еллары 1937 нче елдан башланган дип исәплиләр. Тарих белгечләре сүзләренә караганда, әлеге чор 1918 нче елдан ук башлана. Социалистик революция җиңгәч, Сталин илне революция дошманнарыннан азат итү максатын куя. Шул рәвешле, 60 миллион гаепсез кеше юк ителә. Ул система татар һәм төрки халыкларны күпләп юк итү эшенә керешә. 21 милләтне Җир йөзеннән себереп түгү, бигрәк тә төрки халыкларны бетерү — максат шундый! Сталин татар милләтен аеруча яратмаган, ул аларның уңган һәм булганлыкларыннан көнләшкән. Ул елларның вәхшилеге, шәхес культы фаҗигасе халык күңеленә мәңге төзәлмәслек яра булып сеңеп калган. Репрессияләр иң беренче чиратта милләтнең, халыкның зыялыларына — иҗтимагый фикердә һәм мәдәни хәрәкәттә абруйлы урын тоткан алдынгы карашлы катламнарына юнәлтелгән була. Татар халкының каймагы булган дәүләт, җәмәгать эшлеклеләре; язучылар, галимнәр, җырчылар юк ителә.

***3. Уку мәсьәләсен кую.***

Укытучы бүген дә дәрестә, үзенә язылган язмыш сынауларын җиңеп, сыгылмыйча, сынмыйча, алга — биеккә күтәрелүчеләр турында сөйләшүне дәвам итәчәкләрен әйтә.

Бүгенге дәреснең темасы — Ибраһим Салаховның тормыш юлы, иҗаты һәм «Колыма хикәяләре» циклыннан «Ана тавышы» өзеге белән танышу.

Темадан чыгып, дәрескә уку мәсьәләсен укучылар белән бергәләп кую.

а) Ибраһим Салаховның тормыш юлы, иҗаты белән танышу.

б) «Колыма хикәяләре» циклыннан «Ана тавышы» өзеген уку, аңлау.

**II. Уку мәсьәләсен өлешләп чишү**

1. Язучының иҗаты, тормыш юлы турында мәгълүмат.

1) — Ибраһим Салахов турында моңарчы ишеткәнегез бар идеме?

2) Язучының тормыш юлы, иҗаты турында презентация карау яки укытучының портрет, китапларын күрсәтеп сөйләве.

3) Укытучының тулыландырып сөйләве.

4) Хронологик таблица төзү.

2. — Язучы иҗатының иң бөек ноктасы — «Колыма хикәяләре» әсәре. 1956 нчы елның көзендә акланганнан соң, Ибраһим

Салахов әлеге елларында үзенең күргәннәре турында «тәрәзә капкачларын ябып, пәрдәне төшереп, ишекне бикләп» язарга мәҗбүр була. «Үзем язам, үзем, берәрсе сагалап йөрмиме дип, колак салам», — дип искә ала ул бу хакта. Әдипнең әсәре язылып бетми, ярты юлда кала, җир астына күмелә. Әсәре төгәлләнгәч, язучыга гарәп телендә язылган әсәрне кириллицага күчерергә кирәк була. Ул вакыт өчен бик куркыныч эштә И.Салаховка Пермь өлкәсе Барда районында яшәүче сабакташы Гайшә Гыйззәтуллина ярдәм итә. Әсәрнең моннан соңгы язмышы турында автор түбәндәгечә искә ала:

«Мин аларны төпләтеп, берсен — Казанга, икенчесен Уфага җибәрдем, ... өченчесен җир астына күмеп куйдым. Бәлки, бу тоелган гынадыр: төбенә кулъязмамны күмгәч, алмагач ачы алмалар бирә башлады кебек. Язларын бакча шау чәчәккә төренгәндә, алмагачым миңа хәсрәттән чәче агарган кеше булып күренде». Ул әлеге әсәрне «фаҗига» дип атый. Бу исем дә әсәрнең эчтәлегенә туры килә, дөрестән дә, хәвефле михнәткә, язмышка ишарә бар бу әсәрдә. Аерым кешенең язмышы гына түгел, бөтен татар милләтенең авыр язмышы чагыла монда!

1970 нче елларда әсәрне бастыру мөмкинлеге туа. Мәскәү янындагы Переделкино иҗат йортына баргач, И.Салахов күптәнге дусты Евгения Гинзбург белән очраша. Е.Гинзбург әлеге әсәрне Франциядә бастырып булуын әйтә. Ләкин язучы моңа риза булмый, чөнки әсәрнең башта үз илендә, үз туган телендә дөнья күрүен тели. Әсәрнең басылып чыгуы татар әдәбиятын үз итүчеләр өчен аерым бер сенсация — яңалык була. Дөресен әйткәндә, бу — Сталин репрессиясеннән иза чиккән бөек татар халкының хаксызга рәнҗетелүен сурәтләүче чын әсәр була.

Күренекле галим, әдәбият белгече Фоат Галимуллин болай язды: «Колыма хикәяләре» — хәзерге татар әдәбиятының горурлыгы. Шәхес культының халыкка алып килгән фаҗигасен бөтен тулылыгы белән күрсәткән, шул чор турында гаепләү шаһитнамәсе булырлык әсәрләр күп түгел».

1988 нче елда әсәр, «Тайгак кичү» исеме белән, «Казан утлары» журналында басылып чыга. Тәнкыйтьчеләр дә аны хуплап каршы ала, гомумән алганда, «шәхес культы корбаннарына һәйкәл» дип бәялиләр.

3. «Ана тавышы» өзеген уку.

1) 1 нче абзацны укытучының сәнгатьле укуы, укучылар, күз йөртеп, карап баралар, тыңлыйлар.

— Вакыйга ничәнче елда һәм кайда бара?

2) 1 нче абзацның һәр җөмләсен уку, сүзлекчәне кулланып, сүзгә-сүз русчага тәрҗемә итү.

3) 1 нче абзацның эчтәлеге буенча сорауларга җавап бирү: китаптан табып уку яки кыскача үз сүзләре белән әйтү.

— Тимер юл вокзалында нинди вакыйга була? «Халык дошманнары» нинди тавыш ишетәләр? Ул кемнең баласы?

4) Һәр абзац белән шул рәвешле танышып чыккач, дәреслектәге сораулар һәм биремнәр белән эшләү.

5) Укытучының вакыйганы аңлатып сөйләве. Әсәрнең автор язмышы белән охшаш булуын аңлату.

Без «Ана тавышы» өзеген җентекләп укыдык. Автор үз күзләре белән күргән вакыйгаларны сурәтли. Монда аерым кешеләр язмышы да, татар халкының җан тетрәткеч аяныч хәле дә сурәтләнә.

«Ана тавышы» өзегендәге чегән хатынының язмышы аеруча тетрәндергеч. Аннан соң 40 ел вакыт узса да, язучы аны онытмый. Кайвакыт, әлеге вакыйганы төшендә күреп, шабыр тиргә батып уянып китә. Вакыйга Уфа шәһәрендә тимер юл вокзалында була. Халык дошманы буларак гаепләнеп, чегән хатыны Земфира кулга алына. Аның гаебе расланмаса да, хатынны Колыма көтә. Ананың кулында сөеп туймас «кошчыгы» талпына. Ул баласын саклап калу өчен бөтен нәрсәне дә эшләргә риза, тик аңа тимәсеннәр генә. Тик конвой башлыгы кансыз, ул баланы дежур милиционерга тапшырырга куша. Солдат чегән хатынының баласын алырга сузыла. Шул арада ана аның кулын тешли. Хатынны төртеп егалар, ул перронга барып каплана, сабый кычкырып елап җибәрә. Конвой башлыгы хатынны тагын бер тибеп әйләндерә. Бер кулы белән баласын күкрәгенә кысып, икенче кулы белән биштәрен кочаклаган ана яшел вагонга таба чаба. Ул вагонга менәргә маташа, ә баласын проводница тотып тормакчы була. Ә чегән хатыны конвой башлыгының хәйләсен аңламый. Баланы детприёмникка алып китәләр. Шундук ишек ябыла, хатынның: «Мишутка!» — дип кычкырганы гына ишетелеп кала.

Вагон алга чаба, аның белән бергә ананың елау, сыкрау, каргау, акыру, ярсу тавышы да ияртә. Тик аны беркем дә ишетергә теләми. Бары тик тоткыннарның гына йөрәкләре өзелә, җаннары тырнала, күзләренә — йокы, авызларына бер тәгам ризык та керми. Хатын ирекка ыргыла: ишеккә тибә, тырный, елый,

үкерә, ыңгыраша, каргый, суга. Өч- дүрт сәгатьтән соң, ул тынып кала: чөнки үз-үзенә кул салу — бердәнбер котылу чарасы була.

**2 нче дәрес**

1. Чегән хатыны образына характеристика бирү.

Чегән хатыны Земфира кыю, чибәр, ул үзенең бәясен белә. Чегәннәргә хас булганча, ул ирек ярата, тоткынлыкны, баласыннан аерылуны күтәрә алмый. Ул үзенең баласын күз карасыдай күрә, аны саклый, яклый. Тик кансызлык, әхлаксызлык каршында ул коелып төшә. Күкрәк баласы ана куеныннан аерылырга тиешме?! Шушы аерылу, юксыну, чарасызлык аркасында, ана үз-үзенә кул салырга мәҗбүр була. Без аны куркак, әхлаксыз ана димәс идек, тоталитар системага каршы ул берүзе генә көрәшә алмый, аның башка чарасы юк.

Әлеге кансызлыктан чегән хатыннары гына түгел миллионлаган гаиләләр иза чиккән, балалар ятим калган, милләтнең асыл ирләре, затлы ханымнары юкка чыккан! (Нәтиҗәләр ясала, укучыларның фикерләре тыңлана.)

2. Сорауларга җавап бирү.

— Укучылар, сез чегән хатынының гамәлен хуплыйсызмы? Ул дөрес эшләдеме?

— Укучылар, фикерләрегез төрле, һәм ул шулай булырга тиеш тә. Чегән хатынының үлеме — аның кансыз җәмгыятькә каршы протесты. Ул көченнән килгәннең барысын да эшли, тик кешелексез җәмгыятьне берүзе җиңә алмый. Нинди генә хәлдә дә кеше үзенең кешелеклелеген югалтмаска тиеш.

— Төрмә һәм юл конвойлары турында ниләр әйтер идегез?

— Алар кешелеклелек төшенчәсен үзләштермәгәннәр, җансыз роботка әйләнгәннәр, бары тик боерыкларны гына үтәргә тырышканнар.

— Ә тоткыннарның җыелма образы турында ниләр әйтер идегез?

— Тоткыннар — хокуксыз, үз фикерләрен әйтсәләр, аларны котылгысыз үлем көтә. Нинди генә шартларда да исән калу, бер-береңә ярдәм кулы сузарга тырышу, юату — аларга хас сыйфатлар.

— Тоткыннарны яшәүгә өмет, кешелеклелек, кече күңеллелек, миһербанлылык берләштерә. Нинди генә шартларда да кеше булып кала белү — иң күркәм сыйфатларның берсе!

— Ә бүгенге көндә кешеләр арасында мөнәсәбәтләр нинди? Алар бер-берсенә ярдәмчелме? Кансызлык, тупаслык күренешләре сезне борчыймы? (Җаваплар алына, нәтиҗәләр ясала.)

3. Дәреснең эпиграфына балаларның игътибарын юнәлтү, рус теленә тәрҗемә итү, укучыларның фикерләрен тыңлау.

**III. Рефлексив бәяләү**

1. — Дәрескә куелган уку мәсьәләсе чишелдеме?

1) — Ибраһим Салахов турында нәрсәләр белдегез? Тест сорауларына җавап бирегез: язучының тормыш юлы турында сорауларга дөрес җавапны сайлагыз.

**Тест**

1. Ибраһим Салаховның туган җире:
а) Татарстанның Кукмара районы;
ә) Оренбург өлкәсенең Мостафа авылы;
б) Казахстанның Күкчәтау шәһәре.
2. Ибраһим Салаховның туган көне:
а) 1910 нчы ел, 11 нче март;
ә) 1911 нче ел, 30 нчы август;
б) 1925 нче ел, 25 нче март.
3. 1928 — 1931 нче елларда кайда укый?
а) Казан педагогия техникумы;
ә) Казан дәүләт педагогия институты;
б) Арча педагогия училищесы.
4. 1932 — 1935 нче елда кая китә?
а) укырга;
ә) армиягә;
б) эшкә.
5. «Халык дошманы» дип кайчан кулга алына?
а) 1937 нче елның 25 нче октябре;
ә) 1938 нче елның 11 нче сентябре;
б) 1934 нче елның 15 нче марты.
6. Сталин концлагерьларыннан кайчан азат ителә?
а) 1954 нче елның 15 нче мартында;
ә) 1956 нчы елның 23 маенда;
б) 1947 нче елның 25 нче октябрендә.

2. Дәрескә гомуми бәя. Укучыларга билге кую.

3. Өй эше:
а) әсәрне сәнгатьле укырга өйрәнергә, тәрҗемәсен белергә;
ә) әсәр буенча сораулар төзергә;
б) 7 нче сыйныф дәреслегеннән Гурий Тавлин иҗатын искә төшерергә. Аның язмышы белән Ибраһим Салахов язмышы арасында нинди уртаклык бар? Мисал белән дәлилләргә.

4. Алдагы дәрескә проблема кую.

Укытучы, дәресне тәмамлаганчы, йомгаклап, нәтиҗә ясар өчен сорау бирә:

— «Колыма хикәяләре» әсәрендә нинди тема күтәрелә? (Әсәр тарихи темага, репрессия темасына багышланган. Без өйрәнгән бүлектә чегән хатынының баласыннан аерылу вакыйгасы сурәтләнә.)

— Ибраһим Салаховның «Колыма хикәяләре» — хаксызга җәберләнгән миллионнарча корбаннарның якты истәлегенә багышланган иң уңышлы әсәрләрнең берседер, мөгаен. «Мин киләчәк буыннар без кичергәннәрдән сабак алсыннар өчен яздым. Сак булыгыз, бу явызлык бүтән кабатланмасын! Онытмагыз!» — ди И.Салахов үзенең истәлекләрендә. Моның белән бары тик килешәсе генә кала.

Беркемгә дә яшәү җиңел түгел,
Хакыйкать ул бик тирәндә ята.
Яшәү мәгънәсенә төшеник без,
Узганнарга кабат кайта-кайта,
Ялгышларны бәреп вата-вата.

### Укытучы өчен өстәмә материал

Сталин режимы милли интеллигенциянең каймагын, күренекле вәкилләрен, «халык дошманы» буларак, кулга алган. Тикшерү һәм хөкем карары чыгару өчен, һәр республикада, һәр өлкәдә өч кешедән торган махсус «өчлекләр» булдырылган. Репрессия корбанына әйләнгән шәхес, «үзенең гаебен танып», гаепләү актына имза куярга мәҗбүр булган.

Болар арасында күренекле татар язучылары Г.Ибраһимов, К.Тинчурин, М.Галәү, Ф.Кәримнәр һ.б. Һәм 40 үлемне җиңеп, исән-сау килеш туган илләренә әйләнеп кайтучылар арасында А.Гыйләҗев, Х.Туфан, И.Салаховлар да бар. Ә бит шушы чорда 40 язучының гомере вакытсыз өзелгән!

Сталин репрессиясеннән иза чикмәгән бер генә авыл, бер генә шәһәр, бер генә посёлок та калмаган. Йорт-җирләреннән, туган нигезләреннән, ата-аналарыннан, гаиләләреннән, балаларыннан аерылган бер гаепсез кешеләр Себергә, Колымага, Казахстанның сусыз далаларына, Соловкига, Ак диңгез буйларына үлемгә озатылганнар. Алар үзләренең ни сәбәпле гаепләнүләрен генә аңлый алмаганнар. Авыр кол хезмәтеннән аларның баш миләре кайнаган, кыйнау-рәнҗетүләрдән тәмам сәламәтлекләрен югалтканнар, инвалидка әйләнгәннәр. Сталинизм барлык милләтләрнең дә уртак кайгысына, аяныч фаҗигасенә әверелгән.

И.Салахов 1911 нче елның 30 нчы агустында Казахстанның Күкчәтау шәһәрендә эшче гаиләсендә туа. Әмма аның нәсел шәҗәрәсе Татарстанга барып тоташа. Язучының әти-әнисе Низами һәм Маһиҗамал — чыгышлары белән Татарстанның Балтач җиреннән. Казакъ далаларына алар бәхет эзләп чыгып киткәннәр.

Күкчәтау җидееллык мәктәбен тәмамлаганнан соң, 1928 нче елда, зур өметләр белән, Казанга килә. Педагогия техникумына укырга керә. Монда ул мәртәбәле остазлар: Җ.Вәлиди, М.Корбангалиев, С.Габәши, С.Сәйдәшевлардан белем ала. Педагогия техникумында укыганда ук, Ибраһим «Пионер каләме» («Ялкын») журналында, «Яшь ленинчы» («Сабантуй») газетасында үзенең мәкаләләрен бастыра башлый.

Күренекле шәхесләр белән аралашу, 30 нчы еллар татар матбугатында актив катнашу И.Салаховның тәҗрибәсе артуга, каләменең шомара баруына китерә. Аның бер-бер артлы «Ярату» пьессасы, «Дуэль», «Мәхәббәт һәм өмет» повестьлары, «Постта» шигырьләр җыентыгы дөнья күрә.

Авторның «Колыма хикәяләре» әсәреннән күренгәнчә, шәхес культы башлангач, ул Г.Ибраһимов белән Кави Нәҗми арасында элемтәче булуда гаепләнеп, кулга алына. Әдәбият мәйданында үсеп, танылып кына килгәндә, ул 1937 нче елда, көтмәгәндә, репрессиягә эләгә. 10 елдан артык гомерен, «халык дошманы» булып, төрмәләрдә үткәрә.

И.Салахов озак вакытлар Сталинга тугрылыклы булып кала. Кулга алынгач та әле болай фикер йөртә: «Сталин бу хәлләрне белмидер. Белсә, безне коткарыр». Беркатлы гади егет үзенең «кешеләрне юк итү машинасы»на эләккәнен аңлап җиткерә алмый. Сталин корбанына әйләнгәнен дә соңрак төшенә.

Кулга алынуына 8 ай дигәндә, аңа суд була. Суд бары тик 2 минут кына киңәшә дә хөкем карарын чыгара. Димәк, котылу юлы юк, барысы да хәл ителгән!

«Төрмәдәге бет, кандала канны эчсә дә түзәргә була, тик җанны гына телгәләмәсеннәр», — дип яза ул. Төрмә, лагерьлардан кайткач та, аны җиңел тормыш көтми. Хәтта иң якын кешеләре: әти-әнисе, сеңлесе тарафыннан да рәнҗетелә. Хатыны, кечкенә малае белән өйдән куып чыгарылгач, ул Кызылъяр авылы сельпосы ашханәсендә буфетчы булып эшли. Хатыны Маһруй белән өй җиткергәч, тормыш бераз җайланып китсә дә, аны алда зур сынаулар көтә.

1956 елның яңгырлы, суык, шыксыз бер көне күп газапларны җиңгән И.Салаховка, ниһаять, әйтеп бетергесез зур шатлык — аклану кәгазен китерә. СССР Югары судының Хәрби коллегиясе язучының эшен яңадан карап, 1937 нче елгы хөкем карарын юкка чыгара.

## 37 нче дәрес

**Тема:** Ана күңеле — балада.

**Планлаштырылган нәтиҗәләр:**

Метапредмет — укыганнардан нәтиҗә ясап, тормышта куллану.

Предмет — Сибгат Хәкимнең тормышын һәм иҗатын, «Әнкәй» шигырен өйрәнү.

Шәхескә кагылышлы — өлкән буынга мәрхәмәтлелек хисләре тәрбияләү.

**Материал:** дәреслек (20—22 нче битләр).

**Җиһазлау:** С.Хәким портреты, мультимедиа проекторы, слайдлар, видеоязмалар, С.Хәким китаплары.

### Дәрес барышы:

**I. Мотивлаштыру-ориентлаштыру**

***1. Дәресне оештыру***

Уңай психологик халәт тудыру.

***2. Актуальләштерү***

1) Өй эшен тикшерү: «Ана тавышы» хикәясе турында фикер алышу.

2) Әниләр турында укыган әсәрләрне искә төшерү.

***3. Уку мәсьәләсен кую***

1) Укытучы бүген дәрестә әниләр темасы турында сөйләшүне дәвам итәчәкләрен, шагыйрь Сибгат Хәким иҗаты белән танышачакларын әйтә.

2) Темадан чыгып, дәрескә уку мәсьәләсен укучылар белән бергәләп кую;

а) С.Хәкимнең биографиясен өйрәнү;

ә) «Әнкәй» шигырен уку, анда күтәрелгән проблемаларны ачыклау.

**II. Уку мәсьәләсен өлешләп чишү**

1. Автор белән танышу.

1) Укытучы, шагыйрьнең китапларын күрсәтеп, аның тормышы һәм иҗаты белән таныштыра.

2) Бер укучы дәреслектән Сибгат Хәким турындагы белешмәне укый.

3) Укытучы, сораулар ярдәмендә, укучыларның аңлавын тикшерә.

20 нче биттәге биографик белешмәгә нигезләнеп, сораулар бирелә. Укучылар үзләре дә сораулар төзиләр.

2. Сүзлек белән эш.

1) Укытучы сүзләрне укый, укучылар аның артыннан кабатлыйлар. Авыр сүзләрне аерым укучылардан кабатлаттыра.

2) Укытучы русчасын әйтә, укучылар тәрҗемәсен әйтәләр.

3. «Әнкәй» шигырен уку.

1) Укытучы шигырьне сәнгатьле укый.

2) Шигырьне укучылар үзлекләреннән укыйлар.

3) Берничә укучы шигырьне кычкырып укый.

4) Укучылар шигырьне тәрҗемә итәләр.

5) 21—22 нче биттәге сорауларга җавап бирү, биремнәрне үтәү. Өстәмә сорауларга җавап бирү:

— Шигырь нәрсә турында? Лирик герой кемгә мөрәҗәгать итә?

— Автор әнисе белән бәйле нинди мизгелләрне күз алдына китерә?

— Лирик геройның әнисе сезнең күз алдыгызга нинди булып килеп баса?

4. Шигырь нинди хисләр белән укыла? (Ярату, сагыну хисләре.)

5. Шигырьдән рифмалашкан юлларны табып, укып күрсәтергә.

6. Мәкаль һәм әйтемнәрнең мәгънәсен аңлату:

* Ана җылысы — кояш җылысы.

* Баланың бармагы авыртыр, ананың йөрәге авыртыр.

* Ана өчен баладан газиз нәрсә булмас.

* Ана куены туннан җылырак.

* Яктылык — кояш янында, яхшылык — ана янында.

* Алтмышка җитсен бала, ана өчен һаман да бала.

**III. Рефлексив бәяләү**

1. — Дәрескә куелган уку мәсьәләсе чишелдеме? С.Хәким турында нәрсәләр белдегез? «Әнкәй» поэмасы нәрсә турында?

2. Дәрескә гомуми бәя. Укучыларга билге кую.

3. Өй эше: а) С.Хәкимнең иҗаты турында сөйләргә өйрәнергә;

ә) шигырьне сәнгатьле укырга өйрәнергә;

б) «Минем әнием» темасына хикәя әзерләп килергә.

### Укытучы өчен өстәмә материал

Сибгат Хәким — халык иҗаты, халык җырлары һәм Тукай поэзиясе традицияләре җирлегендә яза башлаган шагыйрьләрнең берсе. Аның беренче шигырьләре утызынчы еллар башында «Атака», «Совет әдәбияты» журналлары һәм «Кызыл яшьләр» газетасы битләрендә

дөнья күрә, сугышка кадәр лирик шигырьләре тупланган «Беренче җырлар» исемле китабы һәм шигъри остазы Г.Тукайга багышланган «Пар ат» (1938—1939), «Шагыйрьнең бала чагы» (1940) исемле поэмалары басылып чыга. Гомумән, Тукай образы, Тукай темасы шагыйрь иҗатында зур урын алып тора. Алтмышынчы-җитмешенче елларда, мәсәлән, бу темага ул махсус шигъри цикл («Тукай дәфтәре») һәм «Кырыгынчы бүлмә» (1971) исемле мәгълүм поэмасын иҗат итә.

Ватан сугышы шагыйрьнең гуманистик тойгыларын, патриотик хисләрен тирәнәйтүгә, гражданин-шәхес буларак чыныгуына, җитлегүенә хәлиткеч йогынты ясый. Сугыш темасы аның бөтен иҗаты буенча кызыл җеп булып сузыла. Бу олы тема эпик колачлыгы һәм фәлсәфи тирәнлеге белән «Курск Дугасы» (1948), «Дала җыры» (1948), «Бакчачылар» (1952), «Дуга» (1968) һәм «Күги» (1983) кебек поэмаларында аеруча калку гәүдәләнә.

Шагыйрь игътибарын даими биләп торган мөһим темаларның тагын берсе — туган җир. Үзе туып үскән Казан арты төбәгенә, аның табигатенә, кешеләренә мәхәббәт хисе шагыйрьнең бөтен иҗатын озатып бара. Бу тема әдипнең күпсанлы лирик шигырьләрендә, җырларында, «Үрләр аша» (1964), «Васыятьләр» (1969), «Дәверләр капкасы» (1974) кебек поэмаларында чагылыш таба.

Сибгат Хәким — дистәләгән җырлар авторы. «Юксыну» (Ш.Мәҗитов музыкасы), «Фазыл чишмәсе», «Таң атканда» (халык көйләре), «Күңелем Ленин белән сөйләшә» (Х.Вәлиуллин музыкасы), «Башка берни дә кирәкми», «Кайда да йөрәктә» (М.Мозаффаров музыкасы), «Өзелгәнсең сиреньнән» (Н.Җиһанов музыкасы), «Бу кырлар, бу үзәннәрдә», «Кем уйлаган» (Җ.Фәйзи музыкасы), «Бер тауда ун чишмә» (Ә.Фәттах музыкасы) кебек җырлар үз вакытында халык арасында зур популярлык казандылар.

Үзе исән чагында Сибгат Хәкимнең Казан һәм Мәскәү нәшриятларында татар телендә һәм рус теленә тәрҗемәдә 60лап китабы басылып чыга. Шулардан 25е — рус телендә, 1се — башкортчага тәрҗемәдә. Вафаты елында аның әдәби мирасыннан үзе сайлап әзерләп калдырган ике томлык әсәрләр җыелмасы нәшер ителә.

Сибгат Хәким олы шагыйрь исемен актив җәмәгать эше белән тыгыз бәйләп бара. Татарстан Югары Советы депутаты (1963 — 1967), Казан шәһәр советы башкарма комитеты депутаты була (1955 — 1957), Татарстан Югары судында халык утырышчысы хезмәтен башкара (1954 — 1958). Ул 1954 елдан гомеренең ахырына кадәр Татарстан Язучылар берлеге идарәсендә әгъза булып тора, шулай ук озак еллар Татарстан Язучылар берлеге каршындагы берлеккә әгъзалар кабул итү комиссиясенә җитәкчелек итә, «Казан утлары» журналы редколлегиясе составында эшли.

## 38 нче дәрес

**Тема:** Җырларымда телим...

**Планлаштырылган нәтиҗәләр:**

М е т а п р е д м е т — экологик тәрбия идеяләре турында фикер алышу.

П р е д м е т — Сибгат Хәкимнең «Җырларымда телим...» шигырен уку.

Ш ә х е с к ә к а г ы л ы ш л ы — туган якка, табигатькә ихтирам тәрбияләү, өлкән буын кешеләренең фикерләрен тыңларга өйрәнү.

**Материал:** дәреслек (23—24 нче битләр).

**Җиһазлау:** С.Хәким портреты, мультимедиа проекторы, слайдлар, видеоязмалар, С.Хәким китапларыннан күргәзмә.

### Д ә р е с б а р ы ш ы:

**I. Мотивлаштыру-ориентлаштыру**

***1. Дәресне оештыру***

Уңай психологик халәт тудыру.

***2. Актуальләштерү***

Өй эшен тикшерү: Сибгат Хәкимнең иҗаты турында сөйләү, «Минем әнием» темасына язылган хикәяләрне тыңлау.

***3. Уку мәсьәләсен кую***

Бүгенге дәрестә Сибгат Хәким иҗаты турында сөйләшүне дәвам итәчәкләрен, шагыйрьнең «Җырларымда телим...» шигыре белән танышачакларын әйтү.

**II. Уку мәсьәләсен өлешләп чишү**

1. «Җырларымда телим» шигыре белән танышу.

1) Сүзлек эше.

2) Укытучы шигырьне сәнгатьле укый.

3) Шигырьне тыңлау, ишетеп аңлауны тикшерү, фикер алышу.

4) Берничә укучы шигырьне кычкырып укый.

5) Укучылар шигырьне тәрҗемә итәләр.

2. Эчтәлек буенча әңгәмә.

— Ни өчен лирик герой һәр елны авылга кайта? Авылның ямен нәрсәдә күрә?

— Илһамны арыш кырларыннан җыеп буламы? Лирик герой нәрсә әйтергә тели?

— «Йөрәгемнең дәвасы» сүзен ничек аңлыйсыз?

3. Дәреслектәге сораулар һәм биремнәрне үтәү.

4. Шигырь нинди хисләр белән укыла? (Ярату, юксыну.)

5. «Җырларымда телим...» җырын тыңлау, фикер алышу.

**III. Рефлексив бәяләү**

1. — Дәрескә куелган уку мәсьәләсе чишелдеме? Нәтиҗә чыгару.

2. Дәрескә гомуми бәя.

— Син үзеңнең дәрескә катнашуыңнан ризамы? Җавапларыңны ничек бәяләр идең?

Укучыларга, дәрестә катнашканнарын бәяләп, билгеләр куела.

3. Өй эше: а) шигырьне яттан өйрәнергә;

ә) Сибгат Хәкимнең тормыш юлы, аның иҗаты турында презентация әзерләргә;

б) дәфтәрдә үзеңнең яки күз алдыңа китергән авылның рәсемен ясарга.

4. Алдагы дәрескә проблема кую.

— Без һәрвакытта да әниләребезгә игътибарлы, шәфкатьле булып кала алабызмы?

## 39 нчы дәрес

**Тема:** Әнкәйләрдән күргән игелек.

**Планлаштырылган нәтиҗәләр:**

Метапредмет — гаилә кыйммәте төшенчәсен формалаштыру.

Предмет — Роберт Миңнуллинның тормышын һәм иҗатын, «Әнкәй» шигырен өйрәнү.

Шәхескә кагылышлы — гаилә, кеше кадере, әтиәни кадерен белергә өйрәтү.

**Материал:** дәреслек (24—26 нчы битләр).

**Җиһазлау:** Р.Миңнуллин портреты, мультимедиа проекторы, слайдлар, видеоязмалар, Р.Миңнуллинның басма китаплары.

### Дәрес барышы:

**I. Мотивлаштыру-ориентлаштыру**

***1. Дәресне оештыру***

Уңай психологик халәт тудыру.

***2. Актуальләштерү***

1) Өй эшен тикшерү: укучыларның С.Хәкимнең «Җырларымда телим...» шигырен сөйләвен тыңлау, киңәшләр бирү.

***3. Уку мәсьәләсен кую***

1. Укытучы бүген дәрестә аналар темасы турында сөйләшүне дәвам итәчәкләрен, шагыйрь, язучы Роберт Миңнуллин иҗаты белән танышачакларын әйтә.

2. Темадан чыгып, дәрескә уку мәсьәләсен укучылар белән бергәләп кую.

а) Роберт Миңнуллинның биографиясен өйрәнү;

ә) «Әнкәй» шигырен уку, анда күтәрелгән проблемаларны ачыклау.

**II. Уку мәсьәләсен өлешләп чишү**

1. Автор белән танышу.

1) Презентация ярдәмендә язучының тормышы һәм иҗаты белән танышу.

2) Бер укучы дәреслектән Роберт Миңнуллин турындагы белешмәне укый.

3) Укытучы, сораулар ярдәмендә, укучыларның аңлавын тикшерә.

4) Биографик белешмәгә нигезләнеп, сораулар бирелә. Укучылар үзләре дә сораулар төзиләр.

2. Сүзлек белән эш.

1) Укытучы сүзләрне укый, укучылар аның артыннан кабатлыйлар. Авыр сүзләрне аерым укучылардан кабатлаттыра.

2) Укытучы русчасын әйтә, укучылар тәрҗемәсен әйтәләр.

3) Укучылар чылбыр буенча яңа сүзләр белән сүзтезмәләр яки җөмләләр төзеп әйтәләр.

3. «Әнкәй» шигырен уку.

1) Укытучы шигырьне сәнгатьле укый.

2) Берничә укучы шигырьне кычкырып укый.

4. Җырны Зөһрә Сәхәбиева башкаруында тыңлау.

5. Сорауларга җавап бирү:

— Сөн елгасы кайда урнашкан? Исегезгә төшерегез. Әле урын Роберт Миңнуллин тормышы белән ничек бәйле?

— Шигырь нинди хисләр белән укыла? (Ярату, сагыну.)

— Шигырьдә кабатланып килүче юлларны табыгыз. Бу күренеш ничек атала? («Әнкәй безне Сөннән алып кайткан, Сөн суында юган иң элек» — рефрен)

— «Биш бала үстек — бер йодрык» сүзләрен ничек аңлыйсыз?

— Икенче строфадан антонимнарны табып, дәфтәрләрегезгә язып куегыз.

— Дүртенче строфадан синонимнарны табып, дәфтәрләрегезгә язып куегыз.

— Шигырьдән рифмалашкан сүзләрне табып укыгыз.

**III. Рефлексив бәяләү**

1. — Сезгә авторның тормыш юлы һәм шигырь эчтәлеге аңлашылдымы?

2. Бәяләү. Укучыларга, дәрестә катнашканнары бәяләнеп, билгеләр куела.

3. Өй эше: а) шигырьне сәнгатьле укырга өйрәнергә;

ә) Роберт Миңнуллинның өстәмә уку өчен бирелгән шигырен укырга;

б) телдән яки кәгазьдә әниеңнең рәсемен ясарга.

### Укытучы өчен өстәмә материал

Татарстанның халык шагыйре Роберт Мөгаллим улы Миңнуллин 1948 нче елның 1 нче августында Башкортстанның Илеш районындагы Нәҗәде авылында туа. Бер елдан соң аларның гаиләсе Кыпчак авылына күчеп килә. Әтисе Мөгаллим, анда берничә ел эшләгәннән соң, үзенең туган авылы Шәммәткә кайтып төпләнә. Булачак шагыйрьнең балачагы, үсмер еллары Сөн буенда уза.

Бүгенге көндә шагыйрь Сөннән шактый ерак яшәсә дә, аның күпчелек шигырьләре белән танышканда, шундый бер хис туа: ул Сөннән беркайчан да аерылмаган, һәрвакыт шул тирәдә яшидер сыман; һәрхәлдә, үзе өзелеп яраткан Сөн елгасын берөзлексез үзе белән бергә — йөрәгендә, күңел түрендә йөртәдер сыман тоела.

Балалар өчен язылган әсәрләрендә Роберт Миңнуллинның осталыгы, таланты аеруча ярылып ята, һәм бу өлкәдә шагыйрь аеруча зур уңышлар казана. Шагыйрь үсеп килүче буынның таләпләрен аңлап, балачакның матур хатирәләрен үтемле итеп тасвирлау мөмкинлегенә ия. Әйтерсең, автор әле һаман балачакта яши. Шагыйрь балалар дөньясын якыннан белә, аны шул ук нәниләргә җиткерү өчен төрле ысул һәм әдәби алымнардан уңышлы файдалана.

Р.Миңнуллин күп кенә шигырьләрендә табигатькә, кош-кортлар, хайваннар дөньясына мөрәҗәгать итә, аларны җанландыра. Ул гади вакыйгаларның үзенчәлекле мизгелен тотып ала һәм сәнгатьчә сурәтли.

Роберт Миңнуллинның балалар поэзиясендә төп герое — гади бала. Балаларны Роберт абый гел бәхетле итеп кенә күрергә тели. Шул изге максатка җиң сызганып хезмәт итә ул.

Әдип — Г.Тукай, М.Җәлил, А.Алиш исемендәге премияләргә һәм Г.Х.Андерсен исемендәге Халыкара Мактаулы Дипломга лаек булган шәхес. Роберт Миңнуллин — тәҗрибәле журналист, танылган җәмәгать һәм дәүләт эшлеклесе дә.

## 40 нчы дәрес

**Тема:** Туган җирләр
Әнкәй белән бергә...

**Планлаштырылган нәтиҗәләр:**

Метапредмет — гаилә кыйммәте төшенчәсен формалаштыру.

Предмет — Марсель Галиевның тормыш юлы һәм иҗаты турында белешмә бирү, «Су буеннан әнкәй кайтып килә» шигырен өйрәнү.

Шәхескә кагылышлы — укучыларда әниләргә мәхәббәт, гаилә, кеше кадере, әти-әни кадерен белергә өйрәтү.

**Материал:** дәреслек (2 нче кисәк, 29—30 нчы битләр).

**Җиһазлау:** мультимедиа проекторы, экран, талгын музыка, слайдлар: Марсель Галиев портреты, шигырь җыентыклары, әниләргә багышланган портретлар, рәсемнәр.

### Дәрес барышы:

**I. Мотивлаштыру-ориентлаштыру**

***1. Дәресне оештыру***

Дәресне башлау. Психологик уңай халәт тудыру.

***2. Актуальләштерү***

1) Алдагы дәрестә бирелгән өй эшен тикшерү.

2) Укытучы, юнәлдерүче сораулар биреп, укучылар белән әниләр турында әңгәмә кора.

— Әниләргә багышлап шигырь язган кайсы язучыларны беләсез?

— Әниләргә багышланган нинди җырлар тыңлаганыгыз бар?

— Кем ул лирик герой?

— Роберт Миңнуллин иҗатындагы Ана образы нинди?

3) Гаилә кыйммәте турында укучыларның фикерләрен тыңлау.

***3. Уку мәсьәләсен кую***

Бүгенге дәреснең темасы — Марсель Галиевның «Су буеннан әнкәй кайтып килә» шигырен уку.

Темадан чыгып, дәрескә уку мәсьәләсен укучылар белән бергәләп кую.

1) Марсель Галиевның тормыш юлы, иҗаты белән танышу.

2) «Су буеннан әнкәй кайтып килә» шигырен уку, аңлау.

**II. Уку мәсьәләсен өлешләп чишү**

1. Автор белән танышу

1) Укытучы, язучының китапларын күрсәтеп, тормышы һәм иҗаты белән таныштыра (презентацияләрдән файдалану).

2) Бер укучы дәреслектән Марсель Галиев турында белешмәне укый.

3) Укытучы, сораулар ярдәмендә, укучыларның аңлавын тикшерә.

— Марсель Галиев кайсы төбәктә туган?

— Марсель Галиев кайда белем алган?

— Ул кайсы редакциядә эшли?

— Марсель Галиевның шигырьләре нинди телләргә тәрҗемә ителгән?

2. Беренче өлешнең сүзлекчәсе белән эш.

1) Укытучы сүзләрне укый, укучылар аның артыннан кабатлыйлар. Авыр сүзләрне аерым укучылардан кабатлаттыра.

2) Укытучы русчасын әйтә, укучылар тәрҗемәсен әйтәләр.

3) Укучылар чылбыр буенча яңа сүзләр белән сүзтезмәләр яки җөмләләр төзеп әйтәләр.

3. Марсель Галиевның «Су буеннан әнкәй кайтып килә» шигырен сәнгатьле уку.

1) Укытучы сораулар бирә:

— Автор иҗат иткән әнкәй образы нинди булып күз алдына килә?

— Марсель Галиев иҗат иткән әнкәй образы белән Роберт Миңнуллин шигырендәге әнкәй образы арасында нинди уртак яклар бар?

— Шигырьнең көй авторы кем? Композитор турында ниләр әйтә аласыз? (Дәреслектән Луиза Батыр-Болгари тормышы, иҗаты белән танышу.)

2) Укытучы шигырьне сәнгатьле укып күрсәтә.

3) Шигырьне укучылар үзлекләреннән укыйлар.

4) Интернет челтәреннән Айдар Фәйзрахманов башкаруында җырны табып тыңлау.

5) Сүзлек өстендә эш.

6) Шигырьгә укытучы ярдәме белән анализ ясала.

Темасы: лирик геройның кичереше, әнкәй образы.

1 нче строфада лирик герой чишмәдән моңаеп кайтып килүче чал чәчле әнисен сурәтли.

2 нче строфада лирик герой әнисенең чишмә юлында узган гомерен, кыз вакытын искә ала.

3 нче строфада лирик герой тормышның алга баруын, әнисенең туган җир белән бергә үзгәрүен, олыгаюын искәртә.

4 нче строфада, 1 нче строфадагы кебек, лирик геройның чишмәдән моңаеп кайтып килүче чал чәчле әнисе сурәтләнә.

7) Шигырьдәге строфаларның кабатлануы ничек атала? (Рефрен.)

8) Шигырьнең тел-сурәтләү чараларын табыгыз.

Оксюморон — *җылы карлар.*

Метафора — *тал мамыгы ява.*

Кабатлау — *бик үзгәргән инде, үзгәргән.*

**III. Рефлексив бәяләү**

1. — Дәрескә куелган уку мәсьәләсе чишелдеме? Нинди образ белән очраштык? (Ана образы.)

— Шигырьгә көйне кем язган? (Луиза Батыр-Болгари.)

2. Бәяләү. Укучыларның дәрестә катнашулары бәяләнеп, билгеләр куела.

3. Өй эше: а) шигырьне сәнгатьле укырга өйрәнергә;

ә) шигырьне ятларга;

б) шигырь эчтәлеге буенча сораулар төзергә.

4. Алдагы дәрескә проблема кую.

Укытучы, дәресне тәмамлаганчы, йомгаклап, нәтиҗә ясар өчен сораулар бирә:

— Шигырьдәге Ана образы нинди? (Ана образы — шигърият тебезнең йөзек кашы. Лирик герой әнисен матур төсләр белән, яратып сурәтли.)

### Укытучы өчен өстәмә материал

**Рефрен** — бөтен бер строфаның яки кушымтаның кабатланып килүе.

## 41 нче дәрес

**Тема:** Кабатланмас әкият.

**Планлаштырылган нәтиҗәләр**:

Метапредмет — элеккеге авыл тормышы турында мәгълүмат бирү.

Предмет — «Кабатланмас әкият» шигырен өйрәнү.

Шәхескә кагылышлы — укучыларда туган илгә мәхәббәт, белем алуга омтылыш тәрбияләү.

**Материал:** дәреслек (2 нче кисәк, 30—33 нче битләр).

**Җиһазлау:** мультимедиа проекторы, экран, слайдлар: авыл тормышын сурәтләгән портретлар.

## Дәрес барышы:

**I. Мотивлаштыру-ориентлаштыру**

***1. Дәресне оештыру***

Дәресне башлау. Психологик уңай халәт тудыру.

***2. Актуальләштерү***

1) Алдагы дәрестә бирелгән өй эшен тикшерү.

2) Укытучы, юнәлдерүче сораулар биреп, укучылар белән халкыбызның тормыш-көнкүреше турында әңгәмә кора.

— Элеккеге авыл өен сурәтләп бирегез.

— Авыл өендә нинди йорт җиһазлары бар?

— Шишара нинди ризык ул?

***3. Уку мәсьәләсен кую***

Бүгенге дәреснең темасы — Марсель Галиевның «Кабатланмас әкият» шигырен уку.

Темадан чыгып, дәрескә уку мәсьәләсен укучылар белән бергәләп кую.

1) Марсель Галиевның тормышы, иҗаты белән танышу.

2) «Кабатланмас әкият» шигырен уку, аңлау.

**II. Уку мәсьәләсен өлешләп чишү**

1. Шигырь белән танышу

1) Укытучы шигырьне сәнгатьле укып күрсәтә.

2) Шигырьне укучылар үзлекләреннән укыйлар.

3) Укытучы, сораулар ярдәмендә, укучыларның аңлавын тикшерә.

— Шигырьдә нәрсә турында сүз бара?

— Малай яшәгән өй ничек сурәтләнә?

— Шигырьдә эти, әни образлары ничек тасвирлана?

— «Гадел-ярлы» дигән сүзне сез ничек аңлыйсыз?

2. Беренче өлешнең сүзлекчәсе белән эш.

1) Укытучы сүзләрне укый, укучылар аның артыннан кабатлыйлар. Авыр сүзләрне аерым укучылардан кабатлаттыра.

2) Укытучы русчасын әйтә, укучылар тәрҗемәсен әйтәләр.

3) Укучылар чылбыр буенча яңа сүзләр белән сүзтезмәләр яки җөмләләр төзеп әйтәләр.

4) Шигырьгә укытучы ярдәме белән анализ ясала.

Темасы: лирик геройның кичереше, шәхесләр язмышы.

1 нче строфада авыл өенең бер күренеше сурәтләнә.

2 нче строфада түр якта әнинең оек бәйләве, йомгак белән уйнап йөрүче песи тасвирлана.

3 нче строфада әтисенең пычак кайравы һәм малайның кулына әлифба алып укый башлавы сурәтләнә.

4 нче строфада малайның әлифба битләрен каравы, андагы геройларны күз алдан китерүе турында сүз бара.

5 нче строфада яңа мичтән чыккан арыш икмәгенең өйгә хуш исе таралуы турында сөйләнелә.

6 нчы строфада малайның әнисе кисеп биргән җылы икмәкне ашап, сөтне эчеп, җанына-тәненә сихәт күчүе турында әйтелә.

7 нче строфада лирик геройның шул чактагы авыл тормышына кире кайтырга теләве турында хәбәр ителә. Бу «әкият» чынга ашсын өчен, «дөнья алтынын» бирергә дә риза ул.

5) Шигырьдән тел-сурәтләү чараларын табыгыз.

**III. Рефлексив бәяләү**

1. — Дәрескә куелган уку мәсьәләсе чишелдеме? Нинди образлар белән очраштык? Аларның шигырьдәге рольләрен ачыклау (гадел-ярлы авыл, малай, малайның әнисе, малайның әтисе).

2. Бәяләү. Укучыларның дәрестә катнашулары бәяләнеп, билгеләр куела.

3. Өй эше: а) шигырьне сәнгатьле укырга өйрәнергә;

ә) шигырьне ятларга;

б) әниегез әзерләгән тәмле ризыклар турында сөйләргә.

4. Алдагы дәрескә проблема кую.

Укытучы, дәресне тәмамлаганчы, йомгаклап, нәтиҗә ясар өчен сораулар бирә:

— Лирик герой өчен нәрсәләр кадерле? Ни өчен?

— Малай яшәгән дөнья ничек сурәтләнә? Укыгыз. (Авыл тормышы, биредәге яшәеш малай өчен якын, кадерле. Биредә яшәлгән һәрбер көнне ул яратып искә ала.)

### Укытучы өчен өстәмә материал

**Лирик герой** — лирикада автор образын, автор аңын белдерүче ысулларның берсе; әсәрдә уй-хисләре, эчке халәте чагылыш тапкан шагыйрьнең хисләреннән тыш, күпчелек кешеләргә хас уй-кичерешләрне гәүдәләндерүче, бәян итүче образ.

## 42—43 нче дәресләр

**Тема:** Ата-анага бурычны бары тик Кеше булып кына түләп була.

**Планлаштырылган нәтиҗәләр:**

Метапредмет — драма, драматургия турында теоретик төшенчә бирү.

Предмет — Шәриф Хөсәеновның тормыш юлы һәм иҗаты турында белешмә бирү, «Әниемнең ак күлмәге» («Әни килде») әсәрен өйрәнү.

Шәхескә кагылышлы — якыннарыңа, туганнарыңа карата ихтирам, мәрхәмәтлелек хисләре тәрбияләү. Югары әхлакый сыйфатлар тәрбияләү.

**Материал:** дәреслек (33—38 нче битләр).

**Җиһазлау:** Ш.Хөсәеновның портреты, мультимедиа проекторы, слайдлар, видеоязмалар, Ш.Хөсәенов китаплары, «Әниемнең ак күлмәге» («Әни килде») әсәренең аерым басмасы.

### Дәрес барышы:

**I. Мотивлаштыру-ориентлаштыру**

***1. Дәресне оештыру***

Уңай психологик халәт тудыру.

***2. Актуальләштерү***

1) Өй эшен тикшерү: укучыларның сүзлекчәдәге сүзләрнең тәрҗемәләрен белүләрен тикшерү; Марсель Галиев иҗаты, шигырьләре турында фикер алышу, сораулар бирү һәм аларга җаваплар алу.

2) Укытучы, юнәлдерүче сораулар биреп, укучылар белән классик язучыларыбызның иҗатлары турында әңгәмә оештыра.

— Сез татар драматургларыннан кемнәрне беләсез? Алар турында нәрсәләр әйтә аласыз?

***3. Уку мәсьәләсен кую***

Укытучы бүген дәрестә төрле әдәби жанрларны өйрәнүне дәвам итәчәкләрен, драматург Шәриф Хөсәенов иҗаты белән танышачакларын әйтә.

**II. Уку мәсьәләсен өлешләп чишү**

1. Автор белән танышу.

1) Укытучы, язучының китапларын күрсәтеп, аның тормышы һәм иҗаты белән таныштыра.

2) Бер укучы дәреслектән Шәриф Хөсәенов турындагы белешмәне укый.

3) Укытучы, сораулар ярдәмендә, укучыларның аңлавын тикшерә. 33 нче биттәге биографик белешмәгә нигезләнеп, сораулар бирелә. Укучылар үзләре дә сораулар төзиләр.

2. Сүзлек белән эш.

1) Укытучы сүзләрне укый, укучылар аның артыннан кабатлыйлар. Авыр сүзләрне аерым укучылардан кабатлаттыра.

2) Укытучы русчасын әйтә, укучылар тәрҗемәсен әйтәләр.

3) Укучылар чылбыр буенча яңа сүзләр белән сүзтезмәләр яки җөмләләр төзеп әйтәләр.

3. Шәриф Хөсәеновның «Әниемнең ак күлмәге» («Әни килде») әсәрен рольләргә бүлеп уку.

1) Укытучы сораулар бирә:

— Әсәр нинди жанрда язылган?

— Әсәр кемнәр һәм нәрсәләр турында?

2) Ананың соңгы васыять сүзләрен сәнгатьле итеп укып күрсәтә.

4. Икенче дәрестә Шәриф Хөсәеновның биографиясе кабатлана, укучылар үзләре сораулар төзиләр, партадашлары җавап бирә.

«Әниемнең ак күлмәге» («Әни килде») әсәрен өйрәнүне дәвам итәләр. Әсәр белән эшләү алдагы дәрестәге тәртиптә бара.

5. Укучылар әсәрдән сурәтләү чараларын табалар.

6. Берничә укучы әсәрнең эчтәлеген үз сүзләре белән сөйли.

7. Биремнәр һәм сораулар эшләнелә.

Дәреслектән 4—6 нчы биремнәр эшләнелә. Укучылар биремнәрне үзләре укыйлар, авыр булса, тәрҗемә итәргә мөмкиннәр.

**III. Рефлексив бәяләү**

1. Укучылар дәреслектәге 7 нче биремне эшлиләр. Бу бирем эшләнгәндә, әсәрнең эчтәлеге тулысынча яңадан кабатланырга тиеш. (Аяз Гыйләҗевнең «Җомга көн кич белән...», Әмирхан Еникинең «Әйтелмәгән васыять», Туфан Миңнуллинның «Әниләр һәм бәбиләр», Фоат Садриевның «Таң җиле» һ.б. әсәрләрдә.)

2. Бәяләү. Укучыларга, дәрестә катнашканнары бәяләнеп, билгеләр куела.

3. Өй эше:

а) әсәрне сәнгатьле итеп укырга өйрәнергә;

ә) сүзлекчәдәге сүзләрнең татарчага тәрҗемәләрен яттан белергә;

б) әсәрдәге берәр образга үз сүзләре белән бәяләмә (характеристика) язарга.

4. Алдагы дәрескә проблема кую.

Укытучы, дәресне тәмамлаганчы, йомгаклап, нәтиҗә ясар өчен сораулар бирә:

— Драма әсәре, гадәттә, ничек тәмамлана? (Төрлечә тәмамлана. Драма әсәрләре һәрвакыт нәрсәгә булса да өйрәтә.)

## Укытучы өчен өстәмә материал

Язучы-драматург буларак, Ш.Хөсәенов киң катлау укучыга һәм тамашачыга үзенең «Профессор кияве» (1952) исемле комедиясе белән танылa. Шәһәр интеллигенциясе, эшче яшьләр тормышына нигезләп язылган һәм үзәккә гаилә, әхлак-мәхәббәт мәсьәләләрен алып, аларны илленче еллар татар драматургиясе өчен шактый яңача һәм тормышчан ситуацияләрдә хәл иткән бу әсәр 1952 нче елда пьесалар буенча уздырылган республика конкурсында икенче премиягә лаек була һәм шул ук елны Г.Камал исемендәге Татар дәүләт академия театры сәхнәсендә куела башлый (200гә якын спектакль). Озакламый комедияне Башкорт дәүләт драма театры, Башкортстандагы Баймак һәм Аургазы театрлары, Татарстанда — Минзәлә, Дагыстанда — Кумык, Себердә Хакас милли театрлары да үз репертуарларына кертәләр.

Драматургның шуннан соң иҗат иткән драма әсәрләреннән «Зөбәйдә — адәм баласы» (1961) трагикомедиясе һәм «Әниемнең ак күлмәге» (беренче исеме — «Әни килде», 1968) драмасы тагы да зуррак уңыш казана. «Әниемнең ак күлмәге» Татар академия театры сәхнәсендә генә дә 400гә якын уйнала, русчага һәм башка милли телләргә тәрҗемә ителеп, илнең кырыклап театры сәхнәсендә уңыш белән бара. Әдипнең «Бирнәле кыз» (1954), «Егерме ел үткәч» (1962) исемле кечкенә күләмле пьесалары да үз вакытында төрле театр сәхнәләрендә уйнала; «Егерме ел үткәч» дигәне, үзәк телевидение аша күрсәтелеп, Октябрь революциясенең илле еллыгы уңае белән «Искусство» нәшрияты чыгарган «Антология советской одноактной пьесы» дигән сайланма җыентыкка кертелә.

Ш.Хөсәеновның драма һәм комедияләре композицион яктан оста корылган булуы, образларның кискен фикри каршылыклар, конфликтлы ситуацияләр аша ачылуы һәм алынган проблемаларның заман рухында, сәнгатьчә үтемле хәл ителүе белән характерлы. Автор үзенең әсәрләрендә кешенең намус сафлыгы, максаты, кыйбласы, тормышта һәм җәмгыятьтә тоткан урыны — хезмәте турында сүз алып бара, кешеләр арасында очрый торган һәртөрле мещанлык күренешләренә каршы нәфрәт хисләрен белдерә.

Ш.Хөсәенов «Мәхәббәт сагышы» (1964) исемле повесть һәм юмористик, сатирик хикәяләр авторы буларак та билгеле.

Әдәби хезмәтләре өчен Ш.Хөсәенов 1979 нчы елда «Почёт Билгесе» ордены» белән бүләкләнде. Аңа шулай ук «Татарстанның атказанган врачы» дигән мактаулы исем бирелде.

## 44 нче дәрес

**Тема:** Әти-әни кадере.

**Планлаштырылган нәтиҗәләр:**

Метапредмет — язучы яшәгән чорга тарихи күзәтү ясау.

Предмет — Фоат Садриевның тормышы һәм иҗаты белән танышу, «Таң җиле» романыннан өзекләр уку.

Шәхескә кагылышлы — туган туфракның, газиз әти-әниеңнең изге икәнлекләренә төшендерү. Тормышта үз кыйблаңны билгеләүгә юнәлеш бирү. Кешелеклелек, намуслылык, мәрхәмәтлелек сыйфатлары тәрбияләү.

**Материал:** дәреслек (2 нче кисәк, 39—43 нче битләр).

**Җиһазлау:** мультимедиа проекторы, экран (такта), Фоат Садриев китаплары, слайдлар: язучының портреты, Интернет челтәреннән «Кояш чыккан җирдә» исеме астында Фоат Садриев чыгышы.

**Эпиграф:**

«Фоат Садриев — татарның Шолоховы».

*Зөлфәт*

### Дәрес барышы:

**I. Мотивлаштыру-ориентлаштыру**

***1. Дәресне оештыру***

Дәресне башлау. Психологик уңай халәт тудыру.

***2. Актуальләштерү***

1) Өй эшен тикшерү: Шәриф Хөсәеновның «Әни килде» драмасы турында әңгәмә оештыру.

2) Әдәбиятта ана образы бик күп әсәрләрдә чагыла. (Укучыларның фикерләре.)

— Әйе, шагыйрьме ул, язучымы — ана образына мөрәҗәгать итмичә калмый. Чөнки һәр кешенең йөрәк түрендә сакланган иң изге хисләрнең берсе ана турында. Без алдагы дәресләрдә

язучылар иҗатында ана образлары бирелешен карап үттек.

— Бүген без ана образы үзәктә торган һәм «Ел китабы» исеменә лаек булган, Г.Тукай исемендәге дәүләт бүләге иясе Фоат Садриевның «Таң җиле» әсәрен өйрәнербез.

*3. Уку мәсьәләсен кую*

Бүгенге дәреснең темасы — Фоат Садриевның «Таң җиле» әсәре белән таныша башлау. Темадан чыгып, дәрескә уку мәсьәләсен укучылар белән бергәләп кую.

1) Фоат Садриевның тормыш юлы, иҗаты белән танышу.

2) «Таң җиле» әсәренең 1 нче өлешен уку, аңлау.

**II. Уку мәсьәләсен өлешләп чишү**

1. Язучының иҗаты, тормыш юлы турында мәгълүмат.

1) Язучы турында презентация карау яки укытучының портрет, китапларын күрсәтеп сөйләве.

2) Укытучының тулыландырып сөйләве.

3) Интернет челтәреннән «Кояш чыккан җирдә» исеме астында Фоат Садриев сөйләвен тыңлау.

4) Хронологик таблица төзү.

5) Язучы иҗаты буенча сораулар төзү һәм парларда җавап бирү.

2. «Таң җиле» әсәренең беренче өлешен уку.

1) 1—2 нче абзацны укытучының сәнгатьле укуы, укучылар, күз йөртеп, карап баралар, тыңлыйлар.

— Кем турында сүз бара?

2) 1—2 нче абзацның һәр җөмләсен уку, сүзлекчәне кулланып, сүзгә-сүз русчага тәрҗемә итү.

3) 1—2 нче абзацның эчтәлеге буенча сорауларга җавап бирү.

— Вакыйга кайда бара? Ул нәрсәгә соклана? Туган җирне сагыну тойгысын сурәтләгән урынны табып укыгыз.

4) 3 нче абзацта без Фәритнең гаиләсе белән танышабыз. Эчтәлеге буенча сорауларга җавап бирү.

— Марат кем ул? «Портрет» төшенчәсен исегезгә төшерегез. Маратның портреты сурәтләнгән өзекне укыгыз. Әнисенең исеме ничек? Мәскәүдән кем килеп төшә? Ул нәрсәгә соклана? Китаптан табып укыгыз һәм рус теленә тәрҗемә итегез.

5) 4—5 нче абзацта Маратның кинәт авырып китүе турында сүз бара. Укучылар үзлектән укыйлар һәм сорауларга җавап бирәләр.

— Марат нинди авырулар белән авырый?

— Әти-әнисе аны савыктыру өченниләр эшлиләр?

— Медицина терминнарын дәреслектән табыгыз һәм дәфтәрегезгә язып куегыз.

6) Маратның савыгуын 6 нчы абзацтан уку.

— Ул ничә яше тулганда сәламәтләнә?

7) 7—8 нче абзацта Маратның яслегә йөри башлавы һәм кабат авырып китүе сурәтләнә.

8) Һәр абзац белән танышып чыккач, дәреслектәге сораулар һәм биремнәр белән эшләү.

9) Әти-әниләргә багышланган мәкальләр уку, мәгънәләрен аңлату.

**III. Рефлексив бәяләү**

1. — Дәрескә куелган уку мәсьәләсе чишелдеме? Фоат Садриев турында нәрсәләр белдегез? Дәреснең эпиграфына игътибарны юнәлтик: «Фоат Садриев — татарның Шолоховы». Язучы Зөлфәт фикерләре белән килешәсезме?

2. Дәрескә гомуми бәя. Укучыларга билге кую.

3. Өй эше: а) Фоат Садриевның тормышы һәм иҗатын турында сөйләргә;

ә) әсәрнең беренче өлешен укырга, план төзергә;

б) һәр укучыга үзенең гаиләсе турында чыгыш ясарга әзерләнеп килергә.

4. Алдагы дәрескә проблема кую.

Укытучы, дәресне йомгаклап, нәтиҗә ясар өчен сораулар бирә:

— Фоат Садриев бу бүлектә нинди тема күтәрә?

— Маратның гаиләсе турында фикерләрегезне әйтегез.

— Сез гаиләдә бер-берегезгә ничек ярдәм итәсез?

## Укытучы өчен өстәмә материал

***Фоат Садриевның тормыш юлына багышланган сораулар***

— Фоат Садриев кайчан туган? (10.03.1941)

— Туган авылы? (ТР Мөслим районы Олы Чакмак авылы.)

— Кайларда белем алган? (Үз авылларында —җидееллык, Шуган авылында урта мәктәпне тәмамлый.)

— Кайларда белемен арттыра? КДУның татар филологиясе факультетында.)

— 1981 — 1982 нче елларда нинди курсларда укып кайта? (Мәскәүдә РСФСР Мәдәният министрлыгы каршында 1 еллык Югары театр курсларына.)

**Драматургиясе**

— Беренче сәхнә әсәренең исеме ничек? («Оҗмах ишеге төбендә».)

— Беренче сәхнә әсәре кайда басылып чыга? (1970 нче елда «Идел» альманахында.)

— Драма әсәрләре кергән китап исемен атагыз. («Ач тәрәзәң», «Тозлы бал».)

— Драматург буларак кайсы театр коллективы белән хезмәттәшлек итә? (Әлмәт татар дәүләт театры.)

— Әлмәт театры аның нинди әсәрләрен сәхнәләштерә? («Их сез, егетләр!..», «Ач тәрәзәң...», «Кондырлы кодачасы», «Тозлы бал», «Син — сандугач, мин — каен», «Безнең авыл кызлары», «Яшьли сөйгән яр», «Хөршидә, Мөршидә, Рәшидә», «Аяз көнне яшен», «Безнең гомер язлары».)

**Прозасы**

— «Таң җиле» әсәре ничә тапкыр нәшер ителә? (2 тапкыр.)

— Кайсы әсәре өчен Г.Тукай исемендәге премия бирелә? («Бәхетсезләр бәхете».)

— Кайсы әсәре өчен Р.Төхфәтуллин исемендәге әдәби бүләк бирелә? («Таң җиле».)

— Кайсы әсәре, иҗатында башка сукмак эзләп, сентименталь агымда язылган әсәр? («Рәхмәт, әтием».)

## 45 — 46 нчы дәресләр

**Тема:** Ана — бөек исем.

**Планлаштырылган нәтиҗәләр:**

Метапредмет — тормышта үз кыйблаңны билгеләүгә юнәлеш бирү.

Предмет — Фоат Садриевның «Таң җиле» әсәрен уку.

Шәхескә кагылышлы — туган туфракның, газиз әниеңнең изге икәнлекләренә төшендерү. Кешелеклелек, намуслылык, мәрхәмәтлелек сыйфатлары тәрбияләү.

**Материал:** дәреслек (1 нче кисәк, 104—111 нче битләр).

**Җиһазлау:** мультимедиа проекторы, экран (такта), Фоат Садриевның «Таң җиле» романы, слайдлар.

### Дәрес барышы:

**I. Мотивлаштыру-ориентлаштыру**

***1. Дәресне оештыру***

Дәресне башлау. Психологик уңай халәт тудыру.

***2. Актуальләштерү***

1) Алдагы дәреснең өй эшен тикшерү.

2) Һәр дәрестә, яңа бүлекне укый башлаганчы, хикәянең авторы Фоат Садриев турында, алда укылган бүлекләр эчтәлеге буенча кыскача әңгәмә. Укучыларның үзләренең, гаиләләре, әти-әниләре фикерләре тыңлана.

— Алга таба вакыйгалар ничек барыр дип уйлыйсыз? (Укучыларның үз фикерләрен тыңлау, яңа бүлекне укырга кызыксыну уяту.)

***3. Уку мәсьәләсен кую***

Дәреснең темасын, дәрескә бурычларны бергәләп кую.

1) Бүгенге дәреснең темасы — Фоат Садриевның «Таң җиле» әсәреннән бүлекләрне укуны дәвам итү. Темадан чыгып, дәрескә уку мәсьәләсен укучылар белән бергәләп кую.

2) «Таң җиле» әсәренең бүлекләрен уку, аңлау.

**II. Уку мәсьәләсен өлешләп чишү**

Бу дәресләрнең һәркайсында әсәрнең яңа бер бүлеге укыла.

1. Яңа текстны укырга әзерләү: сүзлекчә белән эшләү (дөрес әйтелешне тыңлау, кабатлау, тәрҗемә итү — башта үзләре уйлаганча, аннары дөреслеген тикшерәләр яки тәрҗемәсен китаптан карыйлар). Яңа сүзләр белән сүзтезмәләр, җөмләләр төзү.

2. Яңа текстны тыңлау (тәрҗемәсез, анализсыз гына).

— Укучылар башта әйткән фикерләр туры киләме?

— Нәрсә турында сүз бара?

3. Һәр абзацны уку, тәрҗемә итү яки, эчтәлекне аңлаганны тикшерү өчен, гади сораулар бирү. Баштагы фикерләр белән дә чагыштырырга мөмкин.

4. Дәреслектәге сораулар һәм биремнәрне эшләү. Укучылар үз фикерләрен әйткәндә башта русча әйтергә мөмкиннәр, аннары татарчага тәрҗемә итәләр.

5. План төзү.

а) Нәсимә белән Фәритнең авылга кайтуы;

ә) әниләре Нуриасманың каршы алуы;

б) әти-әнинең уллары Марат белән очрашуы;

в) куанычтан башлары күккә тиюе;

г) бүләкләр.

Дәресләрдә телдән күп эшләнсә, укучылар, мәҗбүри бирем булмаса да, гади җөмләләр белән, укылган әсәрнең (бүлекнең) кыскача эчтәлеген сөйли алалар.

6. Ана белән улы Фәритнең очрашу-күрешү өзеген уку.

7. Маратның теле ачылган өлешне рольләргә бүлеп уку.

8. Автор ананы, аның кулларын нәрсәләр белән чагыштыра? «Чагыштыру» төшенчәсен искә төшерү.

9. Әсәрдә авыру баланы терелтүнең серләрен Нуриасма ничек аңлата? Тексттан табып уку.

**III. Рефлексив бәяләү**

1. — Дәрескә куелган уку мәсьәләсе чишелдеме?

— Һәр дәрес башында куелган уку мәсьәләсе үтәлдеме, максатка ирештекме — йомгак ясыйбыз.

3. Өй эше: а) бүлекнең үзегезгә ошаган урынын сөйләргә;

ә) «Ана — бөек исем» темасына кечкенә хикәя язып килергә;

б) план буенча кыскача сөйләргә өйрәнергә.

4. Алдагы дәрескә проблема кую.

Укытучы, дәресне йомгаклап, нәтиҗә ясар өчен сораулар бирә:

— Укылган бүлекләр сезгә ошадымы? Ни өчен?

— Әсәр нинди проблема күтәрә?

— Нинди образ сезгә нык тәэсир итте?

— Ни өчен язучы әсәрне «Таң җиле» дип атый?

— Әдәбиятка традиция буенча ак әби, ак апа образлары килә. Шуларның дәвамы булган Нуриасма әби дә бар. Ул гомере буе аклыкка, сафлыкка, таңга табынып яши. Аның үлеме дә таң алдыннан була.

## 47 нче дәрес — кабатлау дәресе

**Тема:** Кая барсам — әнкәй күңелдә.

**Планлаштырылган нәтиҗәләр:**

М е т а п р е д м е т — укыганны гомумиләштерә, нәтиҗә ясый, иң мөһим мәгълүматны аерып ала белү.

П р е д м е т — укыганнарны гомумиләштереп кабатлау.

Ш ә х е с к ә  к а г ы л ы ш л ы — бу бүлектә укылган әсәрләрне, теоретик төшенчәләрне истә калдыру; бу әсәрләрдә күтәрелә торган проблема — кеше кадере, әти-әни кадерен белергә өйрәтү, гаилә кыйммәте төшенчәсен аңлау, әниләргә ихтирам хисләре тәрбияләү.

**Материал:** дәреслек (2 нче кисәк), Интернет челтәреннән алынган мәгълүматлар.

**Җиһазлау:** мультимедиа проекторы, экран, презентация, тестлар, китаплар күргәзмәсе, «Әнкәй», «Әнкәмнең догалары» җырлары, Зөлфәтнең — «Туган туфрак», А.Минһаҗеваның «Кеше» шигырьләре.

**Дәрес барышы:**

**I. Мотивлаштыру-ориентлаштыру**

***1. Дәресне оештыру***

1) Исәнләшү. Уңай психологик халәт тудыру.

2) Өй эшен тикшерү.

Укучылар «Ана — бөек исем» темасына язган хикәяләрен укыйлар.

***2. Актуальләштерү***

1. «Әнкәй» җырын тыңлау.

Җыр буенча фикер алышу.

— Җырның жанры нинди? Сагышлымы, моңлымы, шатлыклымы?

— Җыр сездә нинди фикерләр уята?

— Бу җыр сезгә әниләргә багышлап язылган, ана образы зур урын алган кайсы әсәрләрне күз алдына китерә?

— Әйе, шагыйрьме ул, язучымы — ана образына мөрәҗәгать итмичә калмый, дидек. Чөнки һәр кешенең йөрәк түрендә сакланган иң изге хисләрнең берсе — ана турында. Без сезнең белән язучылар иҗатында ана образлары бирелешен карап үттек. Ә хәзер шигырьләрдән бирелгән өзекләргә игътибарны юнәлтик. (Экрандагы өзекләрне уку.)

**Дәресне оештыру вариантлары:**

1) Һәр әсәрнең эчтәлеген бергәләп искә төшерү, язучының әйтергә теләгән фикерен ассызыклап үтү.

2) Төркемнәргә бүленеп, һәр төркемнең бер әсәрне яклавы — төп фикерне ачу, алдан әзерләнеп, чыгыш ясавы.

3) Бу бүлектә өйрәнгән әсәрләрнең бер-берсе белән бәйләнешен ачыклау. Һәркайсының бүлекнең төп темасын ничек ачуын күрсәтү.

4) Шигырьләр уку.

5) Төркемнәргә бүленеп, викторина, ярыш, ТЗК формасында бу әсәрләрне үзләштерү дәрәҗәләрен билгеләү.

6) А.Минһаҗеваның «Кеше» шигырен уку.

Тугач та ул иң элек
Акны күрә.
Үсеп җиткәч, төшләрендә —
Аклы күлмәк.
Бик бәхетле көннәрендә
Ак, ак кия!
Кәләш чагы хатирәсе —

Ап-ак чия.
Хыялы һаман да болын —
Ак чәчәкле!..
Тик кылганнар йөгерешә —
Ак чәчләре...
Инде сүзләр: үлеме дә
Актан, имеш...
Кара түгел, яшәү кала
Ап-ак килеш,
Ап-ак килеш.

7) «Әнкәмнең догалары» җыры белән дәрес тәмамлана.

## 48 нче дәрес

**Тема:** Күңелсездән көлке чыкмас.

**Планлаштырылган нәтиҗәләр:**

М е т а п р е д м е т — сатира жанры турында теоретик төшенчә бирү.

П р е д м е т — беренче сатирик журналлар турында мәгълүмат бирү. Галиәсгар Камалның тормышын, иҗатын өйрәнү.

Ш ә х е с к ә к а г ы л ы ш л ы — әхлак (кешелеклелек, юмартлык) хисләре тәрбияләү.

**Материал:** дәреслек (52—55 нче битләр).

**Җиһазлау:** мультимедиа проекторы, слайдлар, сатирик журналлар, Г.Камал портреты, китаплары.

### Д ә р е с б а р ы ш ы:

**I. Мотивлаштыру-ориентлаштыру**

***1. Дәресне оештыру***

Исәнләшү. Уңай психологик халәт тудыру.

***2. Актуальләштерү***

1) Өй эшен тикшерү.

2) «Ана — бөек исем! Нәрсә җитә ана булуга!» бүлегендә укыган әсәрләрне искә төшерү, сорауларга җавап бирү.

***3. Уку мәсьәләсен кую***

1) Укытучы укучылардан сатира жанрын искә төшерүләрен сорый. Сатираның, аның билгеләре, үзенчәлекләре, юмордан аермалы яклары искә төшерелә. Рус әдәбиятыннан нинди сатирик әсәрләр белән таныш булулары турында сорый.

2) Бүгенге дәреснең темасы — сатирик журнал, газеталар белән танышу, сатираның атасы булган Г.Камал иҗаты белән таныша башлау. Темадан чыгып, дәрескә уку мәсьәләсен укучылар белән бергәләп кую.

**II. Уку мәсьәләсен өлешләп чишү**

1. Беренче сатирик журналлар белән танышу.

1) Дәреслектәге материал белән танышу (52—53 нче битләр).

2) Татар телендә чыккан беренче сатирик журналлар рәсемнәре урнаштырылган слайдлар карау. Журналларның тышлыклары, язуларына, рәсемнәренә игътибар итү.

2. Сатирага билгеләмә бирү, теория белән танышу.

1) Сатирага хас үзенчәлекләрне тагын бер кат кабатлау.

2) — Рус әдәбиятында сатира жанрында эшләгән кайсы язучыларны беләсез? Рус телендә чыккан сатирик басмаларның исемнәрен атау.

3. Беренче сатирик журналларның исемнәрен, чыккан елларын дәфтәрләргә язып кую. Сатира өлкәсендә эшләгән, басмаларны чыгару өчен көч түккән танылган татар сатирикларының исемнәрен теркәп кую.

4. Автор белән танышу.

1) Укытучы, язучының китапларын күрсәтеп, тормышы һәм иҗаты белән таныштыра; презентацияләрдән файдаланып, сатира өлкәсендәге эшчәнлеге турында сөйли.

2) Бер укучы дәреслектән Г.Камал турында белешмәне укый.

3) Укытучы, дәреслектәге сораулар ярдәмендә, укучыларның аңлавын тикшерә (55 нче бит).

— Драматург Г.Камал, сатирик буларак, татар әдәбиятына нинди өлеш кертә?

— Г.Камалның башка өлкәдәге эшчәнлеген искә төшерү. (Г.Камал театр эшлеклесе, журналист, художник, карикатурист та була, шулай ук татар милли театрын оештыра һәм аны үстерүгә зур өлеш кертә.)

4) Г.Камалның тормыш юлын һәм иҗатын чагылдырган хронологик таблица тутырырга. Бирем башкарылгач, укучылар биографиягә нигезләнеп сораулар төзиләр һәм парларда эшлиләр.

**III. Рефлексив бәяләү**

1. Укучылар беренче сатирик журналлар турында сөйлиләр. Бу бирем эшләнгәндә, укучылар татар телендә чыккан беренче сатирик басмаларның исемнәрен, анда эшләүче сатириклар ту-

рында кабатлыйлар.

2. — Дәрескә куелган уку мәсьәләсе чишелдеме? Беренче сатирик басмалар турында нәрсәләр белдегез? Г.Камал турында нәрсәләр белдегез?

3. Бәяләү. Укучыларга, дәрестә катнашканнары бәяләнеп, билгеләр куела.

4. Өй эше: а) беренче сатирик журналлар турында сөйләргә;

ә) сатирик темага рәсем ясап карарга;

б) Г.Камалның иҗаты турында сөйләргә өйрәнергә.

5. Алдагы дәрескә проблема кую. Укытучы, дәресне тәмамлаганчы, йомгаклап, нәтиҗә ясар өчен сорау бирә:

— Сатира алымы әдәбиятта ни өчен кулланыла, аның вазифасы нәрсәдә? (Сатира ярдәмендә язучылар кешеләрнең начар сыйфатларына ишарә ясап, алардан көлгәннәр.)

## Укытучы өчен өстәмә материал

**Беренче татар сатирик журналларын өйрәнү мәсьәләләре**

Беренче рус революциясе тәэсирендә, татар телендә басылган тәүге газета-журналлар белән беррәттән, бер-бер артлы сатирик басмалар барлыкка килә.

1905 — 1906 нчы еллар эчендә иң элек 6 журнал чыга. Болардан дүртесе: «Чикерткә», «Чүкеч», «Карчыга», «Яз» — Оренбургта, «Уклар» — Уральскида, «Туп» Әстерханда нәшер ителә. 1908 нче елның августыннан 1909 нчы елның июненә кадәр Казанда 10 номеры чыгып калган «Яшен», Тукай язганча, «...бөтен дөньяны кара кайгы болытлары каплаган» вакытта «күз камаштыра торган якты нурлары илә ялтырады». 1910 нчы елның мартында чыга башлаган «Ялт-Йолт» гамәлдә «Яшен»нең дәвамы булды. 1918 нче елның июненә кадәр аның 123 саны чыкты. 1911 нче елда Троицкида «Акмулла» журналы оештырыла һәм 1916 нчы елның башында 50 нче саныннан соң туктала. Ниһаять, 1915 нче ел башыннан Оренбургта тагын бер сатирик журнал — «Кармак» чыга башлый һәм 1917 нче елның сентябренә кадәр 60 саны дөнья күрә. Шулай итеп, 1906 — 1917 нче елларда татар телендә барлыгы 10 сатирик журнал чыккан.

Билгеле, Октябрьгә кадәрге сатирик матбугат болар белән генә чикләнми. 1909 — 1910 нчы елларда «Казан мөхбире» газетасында «Без» исемле көлке сәхифәләре (барлыгы 25 сан) биреп барыла. 1917 нче елның июленнән алып 1918 нче елның июненә кадәр Ташкентта татар телендә «Чаян» журналы (25 сан), 1917 нче елның декабреннән 1918 нче елның мартына кадәр Алма-Атада «Садак» журналы (5 номер) күбәйтеп таратыла. Шулай ук мәдрәсәләрдә алдынгы карашлы шәкертләр та-

рафыннан кулъязма сатирик журналлар чыгару тәҗрибәсе булган. Мәсәлән, 1905 нче елда Казандагы «Мөхәммәдия» мәдрәсәсендә «Ук» һәм «Мылтык» исемле көлке журналлары чыгарыла. Уфаның «Галия» мәдрәсәсендә 1907 нче елда «Яшен» исемле сатирик журнал аваз сала. Шулай ук биредә «Парлак» (1913), «Борау» (1917) исемле кулъязма сатирик журналлар дөнья күрә.

«Карчыга» журналының нәшире һәм мөхәррире булган Шакир Мөхәммәдев иң элек үзен әдәбиятта сатирик әсәрләре белән таныта.

1905 — 1907 нче елларда берничә саннары гына чыгып калган «Уклар» (Уральск) һәм «Карчыга» (Оренбург) журналлары беренче сатирик басма үрнәге һәм татар сатирик журналистикасына нигез салучы булып тора. Биредә сатирик басма үз йөзендә формалаша. Беренче сатира жанрлары, сатирик тел һәм стилистик образ тудыру чаралары барлыкка килә. Танылган сатириклар Г.Тукай һәм Ш.Мөхәммәдевләр бу журналларда үз каләмнәренең көчен сыныйлар. Үз иҗатларына гына түгел, бербөтен сатира басмаларының тарихына нигез салалар.

«Чикерткә» — татар телендә нәшер ителгән беренче көлке журналларыннан. 1906 нчы елның 23 нче апрелендә Оренбургта «Саранча» — «Чикерткә» исеме белән, рус һәм татар телләрендә бер дәфтәргә төпләнеп чыга башлый. «Чикерткә» — шуның татар телендәге өлеше. Журнал 1906 нчы елның 22 нче октябрендә нәшер ителгән шул 5 нче саныннан соң чыгудан бөтенләй туктый. Журналның гомуми мөхәррире — Павел Александров дигән укытучы, татарча өлешендәге рәсемнәрен «Навайка» псевдонимлы һәвәскәр рәссам ясаган.

«Чүкеч» — 1906 нчы елның июнь аеннан Оренбургта чыга башлаган һәм 1910 нчы елның мартына кадәр дәвам иткән көлке журналы. Барысы 78 сан чыга. Нәшире һәм мөхәррире — Тимерша Соловьев (1875 — 1947). 1906 елның октябреннән 1907 нче елның июленә кадәр журналга Мәхмут Алмаев мөхәррирлек итә. Берара Зариф Бәшири дә мөхәррир булып тора. Актив язылучыларга М.Алмаев, З.Бәшири, Н.Думави керә.

«Туп» — 1907 нче елның март-апрель айларында Әстерханда чыккан көлке журналы. Нәшире сәүдәгәр Иримбитов, рәсми мөхәррире — Хәбибулла Гомәрзадә (Гомәрев), асыл (чын) мөхәррире — Мәхмүт Галәү-Мәрҗани (ул елларда типографиядә хәреф җыючы), рәсемнәре мөгаллим Шәһит Бәйди (Гайфи) тарафыннан эшләнә. Журналның беренче саны таралып беткәнче конфискациягә эләгә, өченче саны да конфискацияләнгәч, журнал бөтенләй чыгудан туктый.

«Яшен» — юмор-сатира журналы. 1908 нче елның 3 нче августында чыга башлый. Журналның беренче санында Тукайның:

Ялтырый милли болытларның арасыннан «Яшен»,
Бәлки, рәхмәт яңгырыдыр — яшьнәсен ул, яшьнәсен!

Юл табар золмәткә калганнар — төшерсен шәүләсен!
Таш йөрәкләр һәм «Яшен» күргән укыр «ләхәүлә»сен, —
дигән шигъри юллары белән ачыла. Соңыннан (1911 — 1912 нче елларда) шагыйрьнең ике кисәк булып чыккан «Яшен ташлары» китабына кергән көлкеләре башта шушы журналда басылганнар. Нәшире, мөхәррире һәм рәссамы — Г.Камал, басылуы Кәримовлар матбагасында иде.

«Ялт-Йолт» — 1910 нчы елның 15 нче мартыннан 1918 нче елның июненәчә Казанда чыккан көлке журналы, «Яшен» журналының дәвамы. Заманында юмор-сатира журналларыннан алдынгысы булып килде. Барысы 123 сан. Рәсми мөхәррире Әхмәт Урманчиев булса да, журнал тулысынча Г.Тукай, Г.Камаллар җитәкчелегендә чыкты дияргә була. Нәшире — «Юл» нәшрияты.

«Кармак» — 1915 нче елның 15 нче гыйнварыннан Оренбургта аена 2 тапкыр чыга башлаган юмор-сатира журналы. Мөхәррире — Мәхмүт Мәрҗани (М.Галәү), «Белек» көтебханәсе. Журналны чыгаруда Шәехзадә Бабич, Кәбир Бәкер, Шәриф Камал кебек танылган язучылар да катнаша. Журналның яшәү дәвере беренче бөтендөнья сугышы барган авыр кичерешле, борчулы елларга туры килгәнгә, артык зур шөһрәт казана алмады. Журнал 1917 нче ел азагына 66 нчы саны чыкканнан соң тукталды.

Сатирик журналлар иң элек яшәп килүче стройга, җәмгыятькә каршылык йөзеннән барлыкка килә. Әйтәсе фикерне сатира чараларына төрмичә әйтү ул чорда мөмкин эш булмый. Сатираның көче дә нәкъ аның әчке көчендә, каршылыгында чагыла. Автор әйтәсе килгән уй-фикерен төрле чаралар аша, төрле формаларга төреп, укучыга җиткерә.

***Рәсимә Галиева,***
*Казан федераль университеты доценты,*
*филология фәннәре кандидаты*

## 49—50 нче дәресләр

**Тема:** Хәйләсез дөнья — файдасыз.

**Планлаштырылган нәтиҗәләр:**

М е т а п р е д м е т — театр сәнгате аша эстетик зәвык тәрбияләү.

П р е д м е т — Галиәсгар Камалның «Банкрот» комедиясен өйрәнү. Сарказм турында теоретик төшенчәне аңлату.

Ш ә х е с к ә  к а г ы л ы ш л ы — хезмәткә мәхәббәт, үз эшең белән горурлану хисләрен үстерү. Акча артыннан куу юлындагы кешелексезлек һәм түбәнлек сыйфатларын аңлату.

**Материал:** дәреслек (55—64 нче битләр).

**Җиһазлау:** Г.Камал портреты, мультимедиа проекторы, слайдлар, видеоязмалар, Г.Камал китаплары, Интернет челтәреннән «Банкрот» спектакле.

**Дәрес барышы:**

**I. Мотивлаштыру-ориентлаштыру**

***1. Дәресне оештыру***

Уңай психологик халәт тудыру.

***2. Актуальләштерү***

Өй эшен тикшерү: Г.Камалның иҗаты, аның сатира өлкәсендәге эшчәнлеген ассызыклап, сатира жанры, беренче сатирик журналлар турында сөйләү. Теләк буенча укучыларның сатирага караган рәсемнәрен тәкъдим итү.

***3. Уку мәсьәләсен кую***

1. Бүгенге дәрестә Г.Камал иҗаты турында сөйләшүне дәвам итәчәкләрен, аның сатирик рухта иҗат иткән «Банкрот» пьесасы белән танышачакларын әйтү.

2. Темадан чыгып, дәрескә уку мәсьәләсен укучылар белән бергәләп кую:

1) «Банкрот» әсәрен уку, анда күтәрелгән проблемаларны ачыклау;

2) Г.Камалның иҗатында сатира алымын күзәтү, аны куллану үзенчәлеген билгеләү.

**II. Уку мәсьәләсен өлешләп чишү**

Бу дәресләрнең һәркайсында әсәрнең яңа бер бүлеге укыла.

1. Беренче дәрестә әсәрне укырга әзерләү: сүзлекчә белән эшләү (дөрес әйтелешне тыңлау, кабатлау, тәрҗемә итү — башта үзләре уйлаганча, аннары дөреслеген тикшерәләр яки тәрҗемәсен китаптан карыйлар). Яңа сүзләр белән сүзтезмәләр, җөмләләр төзү.

2. Текстны рольләргә бүлеп уку (тәрҗемәсез, анализсыз гына). Дәреслекнең 58 нче һәм 59 нчы биттендәге сораулар һәм биремнәрне эшләү.

3. Укытучы укучыларга сораулар бирә:

— Өзек нинди вакыйгадан башланып китә? Вакыйгалар кайсы чорда һәм кайда бара?

— Төп геройның исеме ничек? Аңа нинди сыйфатлар хас?

— Гөлҗиһан нинди герой? Кунак өстәле әзерләү күренешендә аның нинди сыйфатлары ачыла?

4. Һәр яңа өзекне укыгач, эчтәлек буенча сораулар бирелгәннән соң, бүлеккә исем куела.

1) Парларда эшләү: укучылар үзләре бүлекләрнең эчтәлеге буенча сораулар төзи, партадашлары җавап бирә.

2) Башта бүлекнең планы төзелә, аннары аңа исем бирелә.

**Икенче дәрестә** әсәр белән эшләү беренче дәрестәге кебек дәвам ителә.

1. Укытучы укучыларның текстны аңлау-аңламауларын тикшерә, сораулар бирә. Дәреслекнең 61 нче битендәге сорауларга җавап бирү.

2. Укучылар һәр өзекнең эчтәлеген үз сүзләре белән сөйлиләр.

3. «Банкрот» комедиясе турындагы текстны уку, сорауларга җавап бирү, фикер алышу.

4. Сорау-җавап формасында әсәргә анализ ясау.

1) Әсәрнең жанрын билгеләү, фикерне дәлилләү. (Комедия, чөнки автор иҗтимагый тормыштагы, көнкүрештәге тискәре күренешләрдән көлеп, кеше характерының көлкеле якларын күрсәтә.)

— Әсәрдә автор сатирик рухта нинди иҗтимагый күренешләрне сурәтли? (Байларның акча коллыгына бирелүләрен.)

— Г.Камал кешеләрнең нинди тискәре сыйфатларыннан көлә, нәрсәне фаш итә? (Кешеләрнең алдакчы, комсыз, саран булуын фаш итә.)

2) «Банкрот» комедиясендә Г.Камал нинди теманы күтәреп чыга (Акча, кешеләрнең акчага сатылуы, акча өчен һәртөрле ялган, бозыклыкка әзер булулары.)

3) «Банкрот» комедиясендә нинди проблемалар күтәрелә? (Кешеләр өчен акчаның бар нәрсәдән дә өстен булуы.)

4) Теоретик төшенчәләр белән эшләү. Конфликт турындагы теоретик төшенчәне бер укучы укый. Укытучы ярдәмендә, укучылар әсәрдәге төп һәм ярдәмче конфликтларны табып аңлаталар.

5) Комедиянең сюжетын, композициясен ачыклау. (Пьеса өч пәрдәдән гыйбарәт. Вакыйгалар Казанда — Сираҗетдин Туктагаев йортында бара.)

6) Образлар системасы белән эшләү. Әсәрнең төп герое булган Сираҗетдингә характеристика бирелә. (Үзен генә кайгыртучы, акча дигәндә оятын җуйган, комагай, икейөзле аферист. Шул ук вакытта ул бик тапкыр, максатчан, аның сәүдә эшенә сәләте бар.) Укучылар әсәрдән Сираҗетдинне характерлаган өзекләрне табып укыйлар.

Укучылар бер баганага — уңай герой, икенче баганага тискәре герой исемнәрен язалар.

— Сезнең тормышта әлеге типтагы кешеләрнең кайсын күргәнегез бар?

— Укучылар, ничек уйлыйсыз: Сираҗетдин образы аша автор нинди фикер әйтергә тели? (Автор кешенең акчага, байлыкка омтылуын, акча алдында кол булуын күрсәтә, байлык өчен хәтта җинаять кылырга да әзер булуын ача.)

7) Әсәрнең идея-эстетик кыйммәтен, тәрбияви ролен ачыклау. (Автор комедиядә күптөрле әхлакый мәсьәләләр куя, шуларны чишү юлларын эзли.)

8) Интернет челтәреннән табып, «Банкрот»спектаклен карау.

9) Г.Камалның «Банкрот» һәм А.Островскийның «Свои люди — сочтёмся» әсәрләрен чагыштыру.

А.Островский һәм Г.Камал иҗаты купецлар темасы белән охшаш. Г.Камалның «Банкрот» һәм А.Островскийның «Свои люди — сочтемся» дигән комедияләре сюжеты һәм төзелеше белән бер-берсенә охшаган, әмма монда кабатлау юк, охшашлык кына бар. Мәсәлән, Большов белән Туктагаев арасында охшашлык зур, ләкин Сираҗетдин Большовның күләгәсе түгел, ул промышленность чоры купецы һәм Большовтан хәйләкәррәк.

**III. Рефлексив бәяләү**

1. — Дәрескә куелган уку мәсьәләсе чишелдеме? Һәр дәрес башында куелган уку мәсьәләсе үтәлдеме, максатка ирештекме — йомгак ясыйбыз.

— Пьесада бүген дә актуаль булган нинди проблемалар күтәрелә? (Акча бәрабәренә намусларын саткан кешеләрдән көлүе белән әсәр бүгенге көнгә дә аваздаш. Чөнки җәмгыятебездә бүген дә мондый кешеләрне очратып була.)

— Г.Камалны сатира остасы дип әйтеп буламы? Фикерегезне дәлилләгез.

2. Бәяләү. Укучыларга, дәрестә катнашканнары өчен, бәяләнеп, билгеләр куела.

3. Өй эше: а) Сираҗетдин турында сөйләргә әзерләнергә;

ә) Г.Камалның сатирик эшчәнлеге турында сөйләргә («Банкрот» комедиясе мисалында);

б) «Сәйяр» труппасы турында проект эше әзерләргә.

4. Алдагы дәрескә проблема кую. Укытучы, дәресне тәмамлаганчы, йомгаклап, нәтиҗә ясар өчен сорау бирә:

— Дәрестә татар спектакле, театры тарихында зур урын алган кайсы шәхес исемнәрен очраттыгыз? (Г.Камал, Г.Кариев, М.Сәлимҗанов һ.б.)

## Укытучы өчен өстәмә материал

**Сюжет элементлары**

*Экспозиция*

Сираҗетдин Туктагаев газетада бер сәүдәгәрнең ничек талануы турындагы хәбәрне укып, «үземезчә газеталар чыкмаса, мин әле ул фикерне кайдан уйлап чыгыра алыр идем» дип, бурычка алган товарларының бәясен киметеп түләү максаты белән, банкротлыкка чыгу өчен, шактый хәтәр хәйләгә килә. Янәсе, Мәскәү сәүдәгәрләренә түләргә, дип, ул читек кунычларына кырык тугыз мең сум акча урап кия. Хатыны Гөлҗиһан аңа кирәк-яраклар җыя. Нәгыймә карчык та әз-мәз акча таммасмы дип килә. Шуннан юлга дога кылып, Сираҗетдин, саубуллашып, чыгып китә. Юлда Сираҗетдинне «талыйлар», һәм ул «акылдан яза».

*Төенләнеш*

Гөлҗиһан, хатыннар җыеп, мәҗлес үткәрергә әзерләнеп йөргән чагында, Җамалиның (Сираҗетдиннең бертуганы) килеп керүе һәм энесенең поездда талануын, акылдан язуын хәбәр итүе.

*Вакыйгалар үстерелеше*

Сираҗетдин «җүләр» ролен шулкадәр оста уйный, хәтта Мәскәүдән килгән доверенныйлар да аның акча урлатуына шикләнмиләр. Җамали белән Камали, кибетне алып калу һәм, шулай ук, үз кесәләренә аз «кагылу» максаты белән, без бары тик ун процентын гына түли алабыз, диләр. Доверенныйларның моңа риза буласылары килми һәм, Сираҗетдиннең акылдан шашуын дәлилләү өчен, доктор чакыралар.

Туктагаевның юләрләнү хәбәре таралу белән, хезмәтчеләр буйсынмый башлыйлар, хатыны Гөлҗиһан да, иренең чынлап юләрләнүенә ышанып бетмәсә дә, аның белән тормау, бүтән иргә чыгу турында уйлый, приказчик Мөһәммәтҗан да «абыстай әле артык карт түгел, акчасы булса, аның белән торырга мөмкин» дип уйлый.

*Кульминацион нокта*

Сираҗетдинне тикшергән вакытта, Сираҗетдин докторга, эшне бозмасын өчен, акча бирергә уйлый һәм, җаен туры китереп, аңа зур гына суммада акча «төртә». Доктор акчаны аламы, әллә инде Сираҗетдинне «сатамы»?

*Чишелеш*

Сираҗетдин докторның «тылсымы» ярдәмендә «акылга килә». Доктор исә моны зур акча хисабына эшли. Нәтиҗәдә, Сираҗетдин, шушы оста үткәрелгән афёрасы ярдәмендә, йөз дә сигез мең сум табыш ала. Шуннан Сираҗетдин: «Бер минут эчендә — йөз дә сигез мең сум файда! Хатынны җибәрәм, яшь хатын алам, йорт салам! Типтерәм дөньясында!» — ди. Шулай итеп, конфликт чишелә, вакыйга тәмамлана.

*Темасы*

Акча

*Проблемасы*

Кешеләр өчен акчаның бар нәрсәдән дә өстен булуы.

*Идеясе*

Автор кешенең акчага, байлыкка омтылуын, акча алдында кол булуын күрсәтә, байлык өчен хәтта җинаять кылырга да әзер булуын ача. Сираҗетдиннәр җәмгыятендә бар нәрсәне сатып алып була, «намус», «вөҗдан» кебек төшенчәләр онытылган, кешеләр түбән җанга әйләнгән, һәрнәрсә күрәләтә алдауга корылган, тормыш законы булып әверелгән.

Г.Камал — татар драматургиясендә комедия жанрына нигез салган язучы. Аның «Банкрот» комедиясендә XX йөз башындагы татар сәүдә буржуазиясенең акча артыннан куу юлындагы кешелексезлеге һәм түбәнлеге оста тасвирлана. Татар сәүдәгәрләренең, наданлыклары аркасында, бөлеп, банкротлыкка чыгуы ул вакытларда шактый киң таралган була. Г.Камалның «Банкрот» комедиясендә вакыйганы бик оста тасвирлап, көлкеле күрсәтүе, образларның кайсы катлам вәкиле буларак нинди сыйфатларга ия булуы тирә-як чынбарлыкны ничек кабул итүенә бәйләнгән.

Сираҗетдин Туктагаевның прототибы — Казан байларыннан Минһаҗетдин Апакаев дигән сәүдәгәр. Ул да шулай, акылдан шашкан булып, бурыч түләүдән котыла. Ләкин аның котылуы Сираҗетдиннекеннән үзгәрәк була: аны психбольницага салалар, зур взятканы ул шундагы врачларга биреп чыга. Әмма Г.Камал бу детальләргә игътибар итми. Ул әлеге образда гомумән байларның алдакчы һәм комсыз кешеләр булуын фаш итә.

Сираҗетдин Туктагаев — комедиянең төп герое. Автор аны «тыштан бик изге күренә торган сәүдәгәр» дип атый. Чыннан да, ул тыштан шактый итагатьле, динле, инсафлы булып күренә. Ә чынлыкта — гел үзе өчен генә кайгыртучы, акча дигәндә оятын җуйган, комагай, икейөзле аферист. Шәхес буларак ул үзенә җәлеп итә. Мәсәлән, ул бик максатчан, эшчән кеше. «Әле мин белгәндә генә Сираҗи кышкы суыкта бер кат юка бишмәт белән калтырап туңып йөри торган бер кибетче малай иде, — дип сөйли Нәгыймә карчык. — Аз арада гына баеды да китте». Димәк, аның сәүдә эшенә сәләте бар. Шулай ук аны тапкыр түгел дип тә әйтеп булмый, — әнә ничек оста оештыра ул алдашуны. Үзен чолгап алган эшмәкәрләрнең дә, доктор кебек «зыялыларның» да холык-фигылен яхшы аңлый, аларның кимчелекләрен бик белеп файдалана.

Бер кешегә шундый капма-каршы сыйфатларны туплап биреп, драматург образны җанлы, тормышчан итә һәм сатирик көчен арттыра. Юләргә салышкан кешенең кыланышлары болай да көлке тудыра. Ләкин бу очракта бу кыланулар бик җитди төс ала, чөнки максат бик зурдан — йөз дә сигез мең тәңкәне кулга төшерү. Шуңа күрә дә Сираҗетдиннең

«җүләрләнүе» сатирик көлү уята. Әгәр дә Сираҗетдиннең максаты изгедә, мәсәлән, ярлы-мескеннәргә ярдәм итүдә булса, эш башкача булыр иде. Ә монда максат бик тар, бик шәхси. Моны Сираҗетдиннең «сәламәтләнгәч», ягъни алдашуларын төгәлләгәч әйткән сүзләре ачып сала: «Эш пеште! — дип куана ул. — Бер минут эчендә — йөз дә сигез мең сум файда. Хатынны җибәрәм, яшь хатын алам, йорт салам, афтамабил алам! Типтерәм дөньясында!»

Үз корсагын гына кайгыртып яшәгән мондый кешенең маймыл кебек кыланышларыннан мыскыллап көләргә генә мөмкин. Сираҗетдин — комсызлык корбаны, түбән җанлы, эче һәм тышы этлек белән тулы, динсез адәм.

Шунысын да искәртеп үтәргә кирәк: Сираҗетдиндә кешеләргә ышанмау, үзен алардан өстен тоту сыйфаты ачык күренә. Бу Туктагаевларның бер-берсенә мөнәсәбәтендә дә ачык чагыла. Тыштан караганда, алар бер-берсенең сәламәтлеген, тормышын чын күңелдән кайгыртып торалар. Ә чынлыкта исә Сираҗетдин үзенең авантюрасын туган энеләреннән дә яшерә. Димәк, туганлык мөнәсәбәтләренең дә ялган булуы фаш ителә.

Сираҗетдин үзенең наданлыгын белемле булып күренергә тырышуы белән яшермәкче була. Бу аның алынма сүзләрне бозып әйтүендә күренә: «ничава», «судба», «апасны». Моның белән автор шул җәмгыятьнең белемсезлеген күрсәтә.

Гомумән, бу образ ярдәмендә автор җәмгыятьнең явыз чиренә әйләнә барган комсызлыктан, сәүдәгәр даирәсендә киң җәелгән кимчелекләрдән ачы көлә.

Язучы бөлү, банкротлыкка чыгу күренешен сатирик планда бирә һәм шул рәвешле үзенчәлекле сюжет төзи. Гомумән, «Банкрот» комедиясендә XX йөз башындагы татар сәүдә буржуазиясенең акча артыннан куу юлындагы кешелексезлеге һәм түбәнлеге сәнгатьчә оста тасвирланган.

*Гөлназ Җәлилова сайтыннан*

## 51 нче дәрес

**Тема:** Һәр заманның үз герое була.

**Планлаштырылган нәтиҗәләр:**

Метапредмет — язучы яшәгән чорга бәя бирү, тарихны аңлау.

Предмет — Гамил Афзалның тормыш юлы һәм иҗаты белән танышу, «Юл газабы» хикәясен өйрәнү.

Шәхескә кагылышлы — китап укуга, белем алуга омтылыш тәрбияләү. Язучы һөнәренә мәхәббәт тәрбияләү.

**Материал:** дәреслек (2 нче кисәк, 76—79 нчы битләр).

**Җиһазлау:** мультимедиа проекторы, экран (такта), презентация, китаплар күргәзмәсе, сүзлекләр; Интернеттан алынган материаллар.

**Дәрес барышы:**

**I. Мотивлаштыру-ориентлаштыру**

***1. Дәресне оештыру***

— Исәнмесез! Кәефләрегез ничек? Барыбызга да хәерле көннәр, уңышлар теләп, дәресне башлыйк.

***2. Актуальләштерү***

Өй эшен тикшерү: әгәр сез Җиһангир урынында тәхеткә утырсагыз, нинди эшләр башкарыр идегез? Укучылар әзерләп килгән презентацияләрне карау, нәтиҗә.

***3. Уку мәсьәләсен кую***

Темадан чыгып, дәрескә уку мәсьәләсен укучылар белән бергәләп кую.

1) Гамил Афзалның тормыш юлы, иҗаты белән танышу.
2) «Юл газабы» хикәясен уку, аңлау.

**II. Уку мәсьәләсен өлешләп чишү**

1. Язучының иҗаты, тормыш юлы турында мәгълүмат.
2. Тормыш юлын хронологик тәртиптә язып, схема төзетү.
3. Сүзлек эше. Дәреслектә бирелгән *ялыгу, кылану, бермәлне, берзаманны, җенләнү, сигезаяк, бөдрә, дустанә, җанлы, шаккатып, яулау* сүзләренең тәрҗемәсе белән танышу.
4. «Юл газабы» хикәясен уку.

1) 1 нче абзацны укытучының сәнгатьле укуы, укучылар, күз йөртеп, карап баралар, тыңлыйлар. Калган өлешләрне укучыларның үзләреннән укытып аңлауга ирешү.

План төзү:

а) язучы белән танышу;
ә) Мюнхгаузен маҗаралары;
б) укытучы Риза абый;
в) кулга «моңлы саз» алдым;
г) «сыйныф шагыйре» исемен яулау;
д) укытучы булу хыялы.

2) 1 нче абзацның һәр җөмләсен уку, сүзлекчәне кулланып, сүзгә-сүз русчага тәрҗемә итү.

3) Укытучы, юнәлдерүче сораулар биреп, укучылар белән әсәрнең автор язмышы белән охшаш булуын ачыклата. (Әсәр нәрсә

турында? Әсәрдә төп герой кем? Риза абый кем ул? Хикәяләүченең киләчәк тормышында Риза абый нинди роль уйнаган?)

4) Эш дәфтәрендәге биремнәрне үтәү.

5) Эпиграфны уку, фикер алышу.

**III. Рефлексив бәяләү**

1. — Дәрескә куелган уку мәсьәләсе чишелдеме?

1) — Гамил Афзал турында нәрсәләр белдегез? Хикәяне ничек тәмамлар идегез? Хикәяләүче теләгенә ирешерме?

2) Тест сорауларына җаваплар бирегез: язучының тормыш юлы турында сорауларга дөрес җавапны сайлагыз.

**Тест**

1. Гамил Афзалның туган җире:
а) Татарстанның Баулы районы Исергәп авылы;
ә) Оренбург өлкәсенең Мостафа авылы;
б) Татарстанның Актаныш районы Такталачык авылы.
2. Гамил Афзалның туган көне:
а) 1927 нче ел, 25 нче май;
ә) 1921 нче ел, 23 нче май;
б) 1930 нчы ел, 30 нчы май.
3. Гамил Афзал кайсы китабы өчен Татарстанның Габдулла Тукай исемендәге Дәүләт бүләгенә лаек була?
а) «Кар сулары» китабы өчен;
ә) «Вөҗдан сүзе» исемле китабы өчен;
б) «Айлы кичләр» сайланма әсәрләр китабы өчен.
4. Гамил Афзал күбрәк кайсы жанрга игътибарын юнәлтә?
а) сатирик;
ә) драматик;
б) лирик.
5. «Юл газабы» хикәясе кайсы жанрга карый?
а) драма;
ә) эпик;
б) лирик.
Нәтиҗә.

3. Дәрескә гомуми бәя. Укучыларга билге кую.

4. Өй эше:
а) «Юл газабы» хикәясен сәнгатьле укырга өйрәнергә, тәрҗемәсен белергә;
ә) план буенча сөйләргә өйрәнергә;
б) язучы һөнәре турында хикәя язарга.

### Укытучы өчен өстәмә материал

1937 нче елда Гамил Афзал Троицк шәһәрендәге татар педагогия техникумына укырга керә. Ләкин, беренче курсны тәмамлагач, каты авырып китеп, укуын ташларга мәҗбүр була. Шактый озак вакыт хастаханәдә дәваланып ята, аннан терелеп чыккач, янәдән укырга керү мөмкинлеген тапмыйча, эшкә урнашырга карар кыла. 1940 — 1949 нчы елларда ул Магнитогорскидагы металлургия комбинатының механика цехында кара эшче, слесарь, сцепщик-такслажчы, строгальщик булып эшли. Кыен-авыр еллар булуына карамастан, әдәби иҗат эшен дә онытмый; шигырьләр язуын дәвам иттерә, эшче яшьләрдән драма түгәрәге төзеп, шәһәр клубларында, җәйге эстрада сәхнәләрендә, мәдәният сарайларында спектакльләр, концертлар куеп йөри, әдәбият-сәнгать кичәләре оештыра.

1949 нчы елда, янә сәламәтлеге начараю сәбәпле, Г.Афзал заводтагы эшеннән китә, берничә ел тулай торакта комендант, «Большевик» дигән бер промартельдә тегү цехы мөдире булып эшли, аннары, аягын паралич сугып, тагы хастаханәгә эләгә. 1954 нче елның язында ул, «II группа инвалид» дигән язу тотып, хастаханәдән чыга. Гамил Афзал алдына үзенең киләчәк тормышын ничек кору турында четерекле мәсьәлә килеп баса. Озак уйланулардан соң ул, ниһаять, Башкортстан якларына — апасы белән җизнәсе янына кайтырга карар кыла.

Башкортстанның Калтасы районы Шәрип һәм Заболотский авылларында яшәгән еллар (1954 — 1964) Г.Афзалның физик һәм рухи яктан терелүе-ныгуы өчен дә, иҗатының яңача ачылып китүе өчен дә ифрат шифалы тәэсир ясый. Озакламый, Г.Афзалның балаларга атап язган бер шәлкем шигырьләре республика конкурсында бүләккә лаек була, ә 1957 нче елда балалар өчен «Кар сулары» һәм 1958 нче елда зурлар өчен «Вөҗдан сүзе» исемле беренче ике китабы басылып чыга. Халыкчан юмор белән сугарылган, эчтәлеге белән гаҗәеп заманча һәм үзенчәлекле яңгыраган бу шигырьләр укучылар һәм әдәби җәмәгатьчелек тарафыннан татар поэзиясендә бер яңалык булып кабул ителә. Шуннан соң шагыйрьнең бер-бер артлы шигырь җыентыклары басыла башлый, ул тиз арада халык арасында зур популярлык казанып өлгерә.

Илленче-алтмышынчы елларда Г.Афзал башлыча юмор-сатира жанрында активрак эшли, җитмешенче еллардан башлап, аның иҗатында фәлсәфи лирика өстенлек ала башлый. Шулай ук ул юмористик һәм сатирик рухта язылган хикәяләре белән дә танылa.

1965 нче елдан Г.Афзал Әлмәт шәһәрендә яши башлый. 1957 — 2000 нче еллар арасында әдипнең өч дистәдән артык китабы дөнья күрә. 1977 нче елда, «Айлы кичләр» шигъри җыентыгы һәм «Борылам да карыйм...» циклына кергән шигырьләре өчен, ул Татарстан

Республикасының Г.Тукай исемендәге Дәүләт премиясенә лаек була. Татар әдәбиятын үстерү өлкәсендәге хезмәт уңышлары өчен, «Почёт Билгесе» ордены белән (1981) бүләкләнә, 1992 нче елда, Татарстан Президенты М.Ш.Шәймиев Указы белән, аңа «Татарстан Республикасының халык шагыйре» дигән шәрәфле исем бирелә. Ул — шулай ук, Әлмәт язучылар оешмасының Р.Төхфәтуллин исемендәге һәм Чаллыдагы «Аргамак» журналының С.Сөләйманова исемендәге әдәби бүләкләре лауреаты, Татарстанның атказанган мәдәният хезмәткәре.

Гамил Афзал 2003 нче елның 20 нче августында Әлмәт шәһәрендә вафат була.

*Әдипләребез: Библиографик белешмәлек: 2 томда: 1 том / төз. Р.Даутов, Р.Рахмани. — К.: Татар. кит. нәшр., 2009. — 751 б.*

## 52 нче дәрес

**Тема:** Сүз күңелдә очкын булып көйри.

**Планлаштырылган нәтиҗәләр:**

Метапредмет — сатирик шигырь, ирония турында теоретик төшенчә бирү.

Предмет — Гамил Афзалны юмор остасы буларак өйрәнү, «Тәвәккәл әби» шигырен аңлап уку, юмор аша язучы теләгән фикерне табарга өйрәнү.

Шәхескә кагылышлы — әхлак тәрбиясе бирү.

**Материал:** дәреслек (2 нче кисәк, 79—81 нче битләр).

**Җиһазлау:** мультимедиа проекторы, экран (такта), презентация, китаплар күргәзмәсе, сүзлекләр; Интернеттан алынган материаллар.

**Эпиграф:** Юморга бай булган кебек Гамил Афзал,
Һәр кеше дә бай түгел шул, ах жаль, ах жаль.

*Салих Баттал*

### Дәрес барышы:

**I. Мотивлаштыру-ориентлаштыру**

***1. Дәресне оештыру***

— Исәнмесез! Кәефләрегез ничек? Барыбызга да хәерле көннәр, уңышлар теләп, дәресне башлыйк.

***2. Актуальләштерү***

Өй эшен тикшерү: язучы һөнәре турында фикер алышу, укучылар язып килгән хикәяләрне тыңлау.

*3. Уку мәсьәләсен кую*

Дәреснең темасы — «Сүз күңелдә очкын булып көйри»: Гамил Афзалның тормышы, иҗаты һәм «Тәвәккәл әби»шигыре.

Дәрескә уку мәсьәләсен куйыйк: язучы турында күбрәк белергә, шигырьне укырга, аңларга.

**II. Уку мәсьәләсен өлешләп чишү**

1. Язучының иҗаты, тормыш юлы турында мәгълүмат.

2. Дәреслектән теоретик төшенчәләрне табып уку (сатирик шигырь, ирония).

3. Сүзлекчә белән эш.

— Сүзлек белән танышкач, исеменә карап, шигырь нәрсә турында дип уйлыйсыз?

4. Интернет челтәреннән Фоат Галимуллин укуында «Тәвәккәл әби» шигырен тыңлау.

5. Шигырьне укучылар сәнгатьле итеп укый.

6. Эчтәлек буенча фикер алышу.

7. — Шигырьне өлешләргә бүлегез. Һәр өлешкә исем бирегез.

1) Гайни әбинең печәнгә китүе;

2) Әбинең дала уртасында печән «табуы»;

3) Печән төягәндә, каравылчының килеп чыгуы;

4) Каравылчының әбине куркытуы.

8. — Шигырьнең кайсы өлеше сездә көлү тудырды? Сатирик элементларны табыгыз.

9. — Гайни әби нинди? Автор аның кайсы сыйфатларыннан көлә? Тексттан табып укыгыз.

10. Шигырьне анализлау.

11. Эш дәфтәрендәге биремнәрне үтәү.

**III. Рефлексив бәяләү**

1. — Дәрескә куелган уку мәсьәләсе чишелдеме? Гамил Афзал турында нәрсәләр белдегез? Дәреснең эпиграфына игътибарны юнәлтик:

«Юморга бай булган кебек Гамил Афзал,<br>
Һәр кеше дә бай түгел шул, ах жаль, ах жаль», —<br>
дигән Салих Баттал фикерләре белән килешәсезме?

2. Дәрескә гомуми бәя.

Укучыларга билге кую.

3. Өй эше: а) Гамил Афзалның тормышы һәм иҗаты турында сөйләргә;

ә) «Тәвәккәл әби» шигырен сәнгатьле итеп укырга;

б) шигырьнең эчтәлеген хикәя итеп сөйләргә.

4. Алдагы дәрескә проблема кую.

Укытучы, дәресне йомгаклап, нәтиҗә ясар өчен сорау бирә.

— Гамил Афзалның «Тәвәккәл әби» шигыренең эчтәлеге нидән гыйбарәт?

— Ул кешеләр характерындагы кимчелекләрне, ямьсез күренешләрне тәнкыйтьли. Әхлаксыз эш-гамәлләрне фаш итә.

**Укытучы өчен өстәмә материал**

Гамил Афзал

**Юл газабы**

Янып торган сүзләрәзләдем мин,
Ашкынулы хисләр кичердем;
Аяз көндә язган сүзләремнең
Ак аһәңен эчеп исердем.

Кайда килеп туктар юл азагы,
Ел үтәсе юлны ай үтәм.
Бөтен гомерем минем — юл газабы,
Аннан татлы газап бар микән!

## 53 нче дәрес

**Тема:** Озын сүзнең кыскасы.

**Планлаштырылган нәтиҗәләр:**

Метапредмет — пародия, эпиграмма турында теоретик төшенчә бирү һәм аларны тормыш белән бәйләү.

Предмет — З.Нури иҗаты белән таныштыру, пародияләрен һәм эпиграммаларын укып нәтиҗә ясау, бүлекне йомгаклау.

Шәхескә кагылышлы — дәреслекне аңлау, аны яклау һәм дәреслек белән яшәү мәгънәсен аңлату.

**Материал:** дәреслек (2 нче кисәк, 89—91 нче битләр).

**Җиһазлау:** авторның портреты, презентация, китаплары, эпиграммалары, пародияләре.

**Дәрес барышы:**

**I. Мотивлаштыру-ориентлаштыру өлеше**

***1. Дәресне оештыру***

Исәнләшү, дәресне башлау. Хәлләрен, нинди кәеф белән килүләрен сорашу. Психологик уңай халәт тудыру.

***2. Актуальләштерү***

1) Өй эшен тикшерү: алдагы дәрестә бирелгән өй эше сорала.

а) ***Гамил Афзалның*** «Тәвәккәл әби» шигыренең эчтәлеген сөйләү.

ә) Узган дәрестә бирелгән материалны искә төшерү, сораулар бирү.

— Гамил Афзал сатирик поэзиянең нинди жанрларына мөрәҗәгать итә? (Фельетон, мәсәл, җыр, эпиграмма, диалог, монолог һәм башкалар.)

— Шигырьләрендә нәрсәләрне тәнкыйтьли?

***3. Уку мәсьәләсен кую.***

а) З. Нуриның тормыш юлы һәм иҗаты белән танышу.

ә) Язучының пародиясен һәм эпиграммаларын укып нәтиҗә ясау.

**II. Уку мәсьәләсен өлешләп чишү**

1. Сүзлек эше.

Дәреслектә бирелгән сүзләрне уку. Аңлашылмаган яңа сүзләрне сүзлек дәфтәренә язу. Сүзләрне уку.

2. Автор турында белешмә бирү.

Биографиясе белән таныштыру, сорауларга җавап бирү.

3. Иҗаты белән танышу.

1) Үзенә язган пародиясе белән танышу.

— Пародия нәрсә турында?

2) Дәреслектәге сорауларга җавап бирү.

«Пародия» төшенчәсе турында сөйләшү.

— Пародиянең шигырьдән аермасы нәрсәдә?

4. Әсәрнең сюжетына караган сораулар.

Зәки Нуриның эпиграммалары белән танышу, аларны уку.

— Нәрсә ул эпиграмма?

— Аларда нәрсә чагыла?

— Рус әдәбиятында эпиграммалар язучыны беләсезме?

— Зәки Нуриның эпиграммалары кемгә багышланган?

— Әлеге шагыйрьләрне беләсезме?

— Эпиграммалар нәрсә турында? (Тормыш, хакыйкать турында.)

— Автор эпиграммаларында нәрсәләрне чагылдырырга тырышкан? (Тормыштан алынган дөреслекне.)

5. Тормыштагы дөреслек турында сөйләшү.

— Нәрсә ул дөреслек?

— Сезнең өчен дөреслек мөһимме?

— Сезнеңчә, безнең заманда дөрес яшәүче кеше нинди булырга тиеш?

— Дөрес яшәү мәгънәсен югалтмас өчен, нинди гамәлләр эшләргә кирәк?

— Сез хакыйкать, дөреслек өчен көрәшергә әзерме?

— Тормыштагы дөреслек, ачы елмаю сезнең өчен нәрсә ул?

6. Теоретик төшенчәләр: эпиграммалар, пародия, рус әдәбиятында пародияләр һ.б. Авторның сөйләм теле. Авторның язу стиле. Строфа үзенчәлеге.

7. Бүлекне йомгаклау.

— Бу бүлектә нинди яңа белемнәр алдыгыз?

— Нинди авторлар белән таныштыгыз?

— Сезгә иң ошаган автор кем?

— Бу бүлектә иң яратып укыган әсәрегез? Ни өчен?

— Бу бүлекне тәмамлагач, сездә нинди фикерләр туды?

8. Дәреслектәге сорауларга җаваплар бирү.

**III. Рефлексив бәяләү**

1. Нәтиҗә чыгару.

2. Дәрескә гомуми бәя. Укучыларга билге кую.

3. Өй эше: а) үзеңә ошаган эпиграмманы ятларга;

ә) дәреслектәге 5 нче сорауга язмача җавап бирергә;

б) «Дөрес яшәү мәгънәсе нәрсәдә?» темасына сочинение язып килергә.

4. Алдагы дәрескә проблема кую.

— Тормышта дөреслек кирәкме?

— Дөрес яшәү ни өчен кирәк?

— Дөреслек белән ялганның аермасы нәрсәдә?

### Укытучы өчен өстәмә материал

Зәки Нури 1921 нче елның 24 нче декабрендә Татарстанның Чүпрәле районы Татар Төкесе авылында урта хәлле крестьян гаиләсендә туа. Җидееллык колхоз яшьләре мәктәбен тәмамлаганнан соң, 1934 — 1937 нче һәм 1940 — 1941 нче елларда Татарстанның хәзерге Кукмара районындагы Лубян урман техникумында белем ала. 1941 нче елда З.Нури хәрби хезмәткә алына һәм, артиллерист булып, фашист илбасарларына каршы сугышта катнаша. Сугышта күрсәткән батырлыклары өчен, З.Нури «Ватан сугышы ордены» (1948), «Ватан сугышы партизаны-

на» медале (1944) һәм башка медальләр белән бүләкләнә. Белоруссия җирләре фашист илбасарларыннан азат ителгәннән соң, 1944 нче елның августыннан 1946 нчы елның көзенә кадәр, З.Нури хезмәт ияләре депутатларының Орша шәһәре советында башкарма комитет председателе урынбасары вазифасын башкара һәм шәһәрне сугыш хәрабәләреннән арындыру, торгызу буенча зур оештыру эшләре алып бара. 1946 нчы елда З.Нури туган якларына кайта һәм 1946 — 1949 нчы еллар дәвамында башта — Буа урман базасы, аннары Тархан леспромхозы директоры булып эшли.

1949 нчы елның ахырында З.Нури Казанга килә һәм «Яшь сталинчы» газетасы редакторы урынбасары итеп билгеләнә. 1951 — 1955 нче елларда Татарстан китап нәшриятының яшьләр-балалар әдәбияты редакциясе мөдире булып эшли. 1957 нче елда Мәскәүдә СССР Язучылар союзы каршындагы Югары әдәби курсларны тәмамлап кайтканнан соң, З.Нури алты елга якын (1957 — 1963) Татарстан Язучылар берлегенең җаваплы сәркатибе, 1964 — 1971 нче елларда «Казан утлары» журналының баш редакторы, 1971 — 1974 нче елларда Татарстан язучылар берлеге идарәсе председателе булып эшли. 1974 — 1982 нче елларда ул — «Казан утлары» журналының баш редакторы хезмәтендә.

Зәки Нуриның беренче шигъри тәҗрибәләре сугыш алды елларында көндәлек матбугатта һәм күмәк җыентыкларда күренә башлый. Шулай да шагыйрь буларак ул Бөек Ватан сугышы һәм сугыштан соңгы чорда формалаша. 1945 нче елда сугышчы-партизанның ватандарлык, дуслык-туганлык хисләре һәм фашизмга карата нәфрәт белән сугарылган беренче җыентыгы («Шигырьләр») басылып чыга. Гомумән, Ватан сугышы темасы, партизан лирикасы шагыйрьнең бөтен иҗаты буенча үзенчәлекле бер агым булып дәвам итә. Лирик шигырьләрдән һәм «Дан юлы», «Урманда утлар» кебек поэмаларыннан тыш, әдипнең сугыш темасына 60 нчы елларда язылган «Үлгәннәр дә үч алды» исемле проза әсәре дә бар.

З.Нуриның сугыштан соңгы поэтик иҗат эшчәнлеге жанр ягыннан нигездә өч тармакта бара: публицистик лирика, балалар поэзиясе һәм юмор-сатира әсәрләре. Туган илне сөю, аның тарихи казанышлары, көндәлек уңышлары белән горурлану — З.Нури поэзиясенең төп идея эчтәлеген тәшкил итә. Шушы ук патриотик хисләр һәм сыйфатлар аның күпсанлы юмор-сатира әсәрләренең, балалар өчен язган шигырьләренең дә пафосын билгели.

1945 — 1983 нче еллар арасында әдипнең татар телендә — 36, рус теленә тәрҗемәдә — 17, башка халыклар теленә тәрҗемәдә 6 — барлыгы 59 исемдә аерым китабы басылып чыга. Шагыйрьнең иҗат йөзен билгели торган шигырь һәм поэмалары 1980 нче елда Татарстан китап нәшриятында «Шигырь китапханәсе» сериясендә дөнья күргән «Күңел яктысы» исемле күләмле җыентыгында урын алган.

З.Нури тәрҗемә өлкәсендә дә нәтиҗәле эшли. Күренекле рус, украин, белорус, азәрбайҗан, казах, үзбәк, төрекмән, кыргыз, таҗик, латыш, литва, эстон, әрмән, грузин әдипләренең иң яхшы үрнәкләре тупланган махсус җыентыклар бастырып чыгара. Дөнья халыклары һәм илебездәге кардәш халыкларның фольклор әсәрләрен үз эченә алган «Күңелле китап» (1969, 1979), «Алтын хәзинә» (1973) исемле күләмле җыентыклар да әдипнең тәрҗемә өлкәсендәге күпкырлы эшчәнлеге турында сөйли.

З.Нури — актив җәмәгать эшлеклесе. Ул берничә тапкыр халык депутатларының Казан шәһәр советы депутаты итеп сайлана.

Әдәбият өлкәсендәге һәм җәмәгать тормышындагы хезмәтләре өчен, З.Нури 1971 нче елда — «Почёт Билгесе», ә 1981 нче елда «Халыклар Дуслыгы» орденнары белән бүләкләнә.

## 54 нче дәрес — кабатлау дәресе

**Тема:** Көлке дисәң дә көлке!

**Планлаштырылган нәтиҗәләр:**

Метапредмет — укыганны гомумиләштерә, нәтиҗә ясый, иң мөһим мәгълүматны аерып ала белү.

Предмет — «Көлсәң — көл, еласаң — ела!» бүлегендә өйрәнгән материалны кабатлау, үзләштерү дәрәҗәсен билгеләү.

Шәхескә кагылышлы — язучыларыбызның балачакның төрле мизгелләрен сурәтләгән әсәрләренә кызыксыну уяту.

**Материал:** дәреслек (2 нче кисәк, 51—91 нче битләр).

**Җиһазлау:** мультимедиа проекторы, экран, презентацияләр, тестлар.

### Дәрес барышы:

**I. Мотивлаштыру-ориентлаштыру**

***1. Дәресне оештыру***

Исәнләшү, укучыларның хәлләрен сорашу, психологик уңай халәт тудыру.

***2. Актуальләштерү***

1) Өй эшен тикшерү: укучылар язучыларга багышланган эпиграммаларны яттан сөйлиләр. Язучылар турында фикерләрен тыңлау.

2) Укучыларның сүзлекчәдәге сүзләрнең тәрҗемәсен ни дәрәҗәдә белүләрен тикшерү.

***3. Уку мәсьәләсен кую***

Кабатлау дәресе бу бүлектә өйрәнелгән материалны гомумиләштереп кабатлау, белемнәрне тикшерү максаты белән үткәрелә. Әлеге дәресне өстәмә уку өчен бирелгән материал өстендә эшләү формасында да үткәреп була.

— Бүгенге дәрестә без төркемнәрдә эшлибез, сез «Көлсәң — көл, еласаң — ела!» бүлегендә өйрәнгән әсәрләр буенча үзләштергән белемнәрегезне күрсәтерсез.

**II. Уку мәсьәләсен өлешләп чишү.**

1. Бүлектә өйрәнелгән теоретик материалларны кабатлау, гомумиләштерү.

2. Өстәмә уку өчен бирелгән әсәрләрнең эчтәлеген үзләштерү, әңгәмә оештыру.

3. Белемнәрне тикшерү. Тест эшләнелә.

**III. Рефлексив бәяләү**

1. «Бу — кайсы әсәрдән?» уены. Укытучы өзекләр укый, укучылар әсәрнең авторын һәм исемен атыйлар. Бу уенны укучылар үзләре дәвам итә алалар.

Алдан әзерләнеп килеп, сыйныфташлары каршында әсәр героена бәяләмә (характеристика) бирәләр.

2. Бәяләү. Укучыларның дәрестә катнашулары бәяләнеп, билгеләр куела.

3. Өй эше: а) өстәмә уку өчен бирелгән әсәрләрне укырга өйрәнергә;

ә) өйрәнгән әсәрләр буенча тестлар һәм сораулар төзергә (теләк буенча);

б) бер әсәрнең үзеңә ошаган эпизодына рәсем ясарга.

4. Алдагы дәреска проблема кую.

### 55 нче дәрес

**Тема:** Көйләрдән тезмәләр тездем.

**Планлаштырылган нәтиҗәләр:**

М е т а п р е д м е т — укучыларда эстетик зәвык тәрбияләү.

П р е д м е т — Ренат Харисның тормыш юлы һәм иҗаты турында белешмә бирү, «Гармунчы» поэмасын өйрәнү.

Ш ә х е с к ә к а г ы л ы ш л ы — гармунчы һөнәренә, төрле һөнәр ияләренә ихтирам тәрбияләү.

**Материал:** дәреслек (2 нче кисәк, 92—95 нчы битләр).

**Җиһазлау:** мультимедиа проекторы, экран, слайдлар: Ренат Харис портреты, китаплары, гармунчылар, төрле һөнәр ияләре сурәтләнгән рәсемнәр.

**Дәрес барышы:**

**I. Мотивлаштыру-ориентлаштыру**

***1. Дәресне оештыру***

Исәнләшү, хәлләр сорашу, яхшы кәеф теләп, дәресне башлау.

Психологик уңай халәт булдыру.

***2. Актуальләштерү***

1) Укытучы, юнәлдерүче сораулар биреп, укучылар белән төрле һөнәр ияләре турында әңгәмә оештыра.

— Сез нинди һөнәрләр беләсез? Матурлык тудыруда гармунчыларның роле нинди? Сез гармун тавышын яратасызмы? Туганнарыгыз, танышларыгыз арасында гармунчылар бармы?

2) Интернет челтәреннән гармун тавышын тыңлау.

***3. Уку мәсьәләсен кую***

Укытучы бүген дәрестә гармунчылар турында сөйләшүне дәвам итәчәкләрен, шагыйрь Ренат Харис иҗаты белән танышачакларын әйтә.

**II. Уку мәсьәләсен өлешләп чишү.**

1. Автор белән танышу.

1) Укытучы, язучының шигырьләрен, китапларын күрсәтеп, презентация ярдәмендә, аның тормышы һәм иҗаты белән таныштыра.

2) Бер укучы дәреслектән Ренат Харис турында белешмәне укый.

3) Укытучы, сораулар ярдәмендә, укучыларның аңлавын тикшерә.

— Ренат Харис кайсы төбәктә туган?

— Ул кайларда укыган?

— Аның хезмәт юлы турында нәрсәләр белдегез?

— Аның беренче китабы кайчан чыга?

— Китаплары нинди телләргә тәрҗемә ителгән?

2. Сүзлек белән эш.

1) Укытучы сүзләрне укый, укучылар аның артыннан кабатлыйлар. Авыр сүзләрне аерым укучылардан кабатлаттыра.

2) Укытучы русчасын әйтә, укучылар тәрҗемәсен әйтәләр.

3) Укучылар чылбыр буенча яңа сүзләр белән сүзтезмәләр яки җөмләләр төзеп әйтәләр.

3. Ренат Харисның «Гармунчы» әсәрен өйрәнү.

1) Укучылар белән бергәләп, «гармунчылар» сүзенең мәгънәсенә төшенү.

— Сез нинди гармуннар барлыгын беләсез?

— Гармун тотып утырган һәр кеше гармунчы буламы?

— Гармунда уйнарга өйрәнәсегез киләме?

— Матур итеп гармунда уйнаучыларга ничек карыйсыз?

2) Поэма турында теоретик төшенчәне искә төшерү.

3) «Гармунчы» поэмасын уку, бүлекләргә исемнәр кую.

— Поэманың лирик герое кем? Аңа нинди сыйфатлар хас?

— Геройның нинди шөгыле бар? Бу шөгыль турында ниләр беләсез?

4) «Борынны шактый чөйдем» фразеологизмын аңлату.

5) Тел-сурәтләү чараларын билгеләү.

Сынландыруларны табу: *чәчрәде моң чыклар булып, балкып тора, былбыллар итеп сайратты* һ.б.

Чагыштыруларны табу: *патша кебек* һ.б.

4. Дәреслектәге сорауларга җавап бирү.

5. Поэманы укып бетергәч, әсәр эчтәлеге буенча сорауларга җавап бирү:

— Поэмада нәрсә турында сүз бара?

— «Көйләрдән тезмәләр **тездем,**
**Тездем** дә кабат өздем...» —
дигән юлларны сез ничек аңлыйсыз?

**Ялгау (эпанафора)** — юл ахырындагы мәгънәле кисәкнең, сүз яки сүзтезмәнең икенче юлны башлап җибәрүе.

**Аллитерация** — тартык аваз хәрефләре кабатлану очрагы: биредә *з—д* авазлары кабатлана.

— Гармунчылар турында нинди әсәрләр укыганыгыз бар?

— Лирик герой белән кыз арасында нинди уртаклык бар?

— Кызның гармун уйнавын тасвирлаган өзекне тексттан табып укыгыз. Фикер алышыгыз.

— «Шөгыль» һәм «һөнәр» сүзләренең мәгънәләрен аңлатыгыз.

— Сезнең нинди шөгыльләрегез бар?

— Әти-әниләрегезнең нинди шөгыльләре бар?

**III. Рефлексив бәяләү**

1. — Дәрескә куелган уку мәсьәләсе чишелдеме? Нинди образлар белән очраштык? Аларның поэмадагы рольләрен ачыклау.

2. Дәрескә гомуми бәя. Укучыларга билге кую.

3. Өй эше: а) поэманы сәнгатьле укырга өйрәнергә;

ә) һөнәр турында мәкальләр язып килергә;

б) укучыларга үзләренә ошаган һөнәр, шөгыль турында проект эше әзерләргә. Әти-әниләрнең һөнәрләре турында проект эше дә кызыклы булыр.

4. Алдагы дәрескә проблема кую.

— Автор үзенең әсәре белән нәрсә әйтергә тели, нинди идея үткәрә?

— Сыйныфыгызда нинди һөнәр ияләре бар?

— Лирик герой ни өчен елап җибәрә?

### Укытучы өчен өстәмә материал

Шагыйрь, тәнкыйтьче, җәмәгать эшлеклесе, рәссам, Г.Тукай исемендәге Дәүләт премиясе лауреаты (1997), Татарстан Республикасының халык шагыйре (2004), Россия Федерациясенең Дәүләт премиясе иясе (2005) Ренат Харис (Харисов Ренат Мәгъсум улы) 1941 нче елның 6 нчы маенда Ульянов өлкәсенең Цильна (Чынлы) районы Кәшә (Зирекле күл — Елховое озеро) авылында укытучылар гаиләсендә туа. Балалык һәм мәктәп еллары Татарстанның Буа төбәге авылларында уза. А.В.Луначарский исемендәге Буа урта мәктәбен (1958), Казан дәүләт педагогия институтының филология факультетын тәмамлагач (1963), Арча педагогия училищесында рус телен һәм әдәбиятын укыта (1963 — 1964), ВЛКСМның Татарстан өлкә комитетында инструктор (1964 — 1965), «Татарстан яшьләре», «Яшь ленинчы» (хәзерге «Сабантуй») газеталарында әдәби хезмәткәр, җаваплы сәркатип (1965 — 1971) вазифаларын башкара. Әдәбиятка мәхәббәте мәктәп елларында уяна, шигърияткә студент елларында килә, 1968 нче елда «Җир һәм Кеше» исемле тәүге китабы «Беренче карлыгачлар» сериясендә дөнья күрә. «Кайтаваз» (1969) җыентыгы сүзгә игътибарлы, үз өслүбен эзләүче яшь шагыйрь иҗатына җәмәгатьчелекнең игътибарын уята. «Ак сөлге» (1971), «Яңа көн» (1972), «Бизәк» (1974), «Баскычлар» (1976), шигырь белгече Н.Юзиевнең кереш сүзе белән дөнья күргән «Замана эзләре» (1981) шигырь китаплары аны интеллектуаль-фәлсәфи юнәлешкә өстенлек бирүче, тасвирлау алымнарын туктаусыз төрләндереп торучы, ритм-рифма чараларына, шигырь техникасына яңалык алып килүче җитлеккән сүз остасы буларак таныталар.

Р.Харисны, өслүбеннән чыгып, фольклор һәм Тукай мәктәбенә якын шагыйрь дип булмый. Фикерләү рәвеше буенча ул Дәрдемәнд, яшь Туфан, Ә.Фәйзи, Ә.Давыдов, Ш.Анак кебек сүз осталарына якынрак тора, әмма аңа Тукайның гражданлык позициясе, иҗтимагый-фәлсәфи эзләнүләре, тел байлыгы, ирониясе якын. Тукайдан алган «Китмибез без, безгә анда...» эпиграфы белән башланган «Китмибез!» шигыре — шуның ачык бер үрнәге. Тукайның шул ук исемдәге шигыре 1907 нче

елда кайбер татар милләтчеләре һәм Дума депутатлары арасында «татарларны Төркиягә күчерергә кирәк» дигән мәкергә җавап рәвешендә язылган. Р.Харис шигыренә нигез-өлге итеп Тукай фикерен ала һәм туган илнең, туган җирнең изгелеген, мәңгелеген раслап чыга.

Яңа чор татар шигъриятенә нигез салучы Тукай образы — Р.Харис өчен якты маяк, юл күрсәтүче фидаи җан, көрәшче шәхес. «Тукайның мәхәббәт төшләре» драматик поэмасына ул «Тукай таптап тузан иткән ташлар», «Тукай соравы», «Тукай туган көнне һәр ел кояш» кебек күпсанлы шигырьләре аша килә.

## 56 нчы дәрес

**Тема:** Минем тирәмдә
Кояш үзе әйләнә.

**Планлаштырылган нәтиҗәләр:**

М е т а п р е д м е т — укучыларга экологик тәрбия бирү;

П р е д м е т — Ренат Харисның «Ике гөл» шигырен өйрәнү;

Ш ә х е с к ә к а г ы л ы ш л ы — табигатькә карата күзәтүчәнлек тәрбияләү.

**Материал:** дәреслек (2 нче кисәк, 95—96 нчы битләр).

**Җиһазлау:** мультимедиа проекторы, экран, слайдлар: Ренат Харис портреты, китаплары, бүлмә гөлләре, чәчәкләр ясалган рәсемнәр.

### Д ә р е с б а р ы ш ы:

**I. Мотивлаштыру-ориентлаштыру**

***1. Дәресне оештыру***

Исәнләшү, хәлләр сорашу, яхшы кәеф теләп, дәресне башлау. Психологик уңай халәт булдыру.

***2. Актуальләштерү***

1) Укучылар һөнәр турында проект эшләрен яклыйлар.

2) Укытучы, юнәлдерүче сораулар биреп, укучылар белән гөлләр һәм чәчәкләр турында әңгәмә оештыра:

— Сез нинди гөлләр һәм чәчәкләрне беләсез? Алар берберсеннән ничек аерыла? Әдипләрнең чәчәкләр турында нинди әсәрләрен укыганыгыз бар?

***3. Уку мәсьәләсен кую***

Укытучы бүген дәрестә туган җир турында сөйләшәчәкләрен, шагыйрь Р.Харис иҗаты белән танышуны дәвам итәчәкләрен искәртә.

**II. Уку мәсьәләсен өлешләп чишү**

1. Ренат Харисның «Ике гөл» шигырен уку.

1) Укытучы укый. Сорау куела:

— Нинди образлар белән очрашабыз?

2) Сүзлек белән эш (96 нчы биттәге сүзләр).

3) Укучылар эчтән укыйлар. Сорау:

— Чүлмәктәге гөл белән бакча гөле нәрсә турында бәхәсләшәләр?

4) Сәнгатьле укыту.

2. Шигырьгә анализ.

1) Әсәрнең жанрын, әдәби төрен ачыклау.

2) Чүлмәктәге гөл белән бакчадагы гөлнең монологын уку, мәгънәсен ачыклау.

3) Бәхет турында әңгәмә оештыру, диалог төзетү.

— Сезнеңчә, кайсы гөл бәхетле? Ни өчен?

— «Аркамны да, ян-ягымны да кояшка борам» юлларын ничек аңлыйсыз?

— Бу нинди тел-сурәтләү чарасы була?

3. Мәкальләрне укып, мәгънәләрен аңлату. Кайсы мәкаль шигырьнең эчтәлеген ача?

4. Дәреслектәге 7 нче биремне эшләү.

**III. Рефлексив бәяләү**

1. — Дәрескә куелган уку мәсьәләсе чишелдеме? Нинди образлар белән очраштык? Автор гөл образы аша нәрсә әйтергә тели?

2. Дәрескә гомуми бәя. Укучыларга билге кую.

3. Өй эше: а) шигырьне сәнгатьле укырга өйрәнергә;

ә) шигырьне яттан өйрәнергә;

б) Сезнең өчен бәхет нәрсә? Сез бәхетлеме? Шул темага хикәя язып килергә.

4. Алдагы дәрескә проблема кую.

— Гөлләр өчен бәхет нәрсәдә? Сез алар белән килешәсезме?

## 57 нче дәрес

**Тема:** Шигырем — ачык!

**Планлаштырылган нәтиҗәләр:**

М е т а п р е д м е т — татар шигъриятенә карата кызыксыну уяту.

П р е д м е т — Зөлфәтнең тормышын, иҗатын һәм «Шигырем — ачык!» шигырен өйрәнү.

Ш ә х е с к ә к а г ы л ы ш л ы — язучы һөнәренә мәхәббәт тәрбияләү.

**Материал:** дәреслек (2 нче кисәк, 97—99 нчы битләр).

**Җиһазлау:** мультимедиа проекторы, экран, слайдлар: шагыйрь тормышын сурәтләгән портретлар.

**Д ә р е с б а р ы ш ы :**

**I. Мотивлаштыру-ориентлаштыру**

***1. Дәресне оештыру***

Дәресне башлау. Психологик уңай халәт тудыру.

***2. Актуальләштерү***

1) Алдагы дәрестә бирелгән өй эшен тикшерү.

2) Укытучы, юнәлдерүче сораулар биреп, укучылар белән шагыйрьләр, шигырь язу процессы турында әңгәмә кора.

— Кайсы шагыйрьләрне беләсез?

— Шагыйрьләр илһам көчен каян ала дип уйлыйсыз?

— Шигырь язып караганыгыз бармы?

***3. Уку мәсьәләсен кую***

Бүгенге дәреснең темасы — Зөлфәтнең «Шигырем — ачык!» шигырен уку.

Темадан чыгып, дәрескә уку мәсьәләсен укучылар белән бергәләп кую.

1) Зөлфәтнең тормышы, иҗаты белән танышу.

2) «Шигырем — ачык!» шигырен уку, аңлау.

**II. Уку мәсьәләсен өлешләп чишү**

1. Шагыйрь белән танышу.

1) Укытучы, язучының китапларын күрсәтеп, тормышы һәм иҗаты белән таныштыра.

2) Бер укучы дәреслектән Зөлфәт турында белешмәне укый.

3) Укытучы, сораулар ярдәмендә, укучыларның аңлавын тикшерә.

— Зөлфәт кайда һәм кайчан туган?

— Шагыйрь кайсы газета-журналларда эшләгән?

— Зөлфәтнең нинди әсәрләрен, шигырьләрен беләсез?

2. Сүзлек белән эш.

1) Укытучы сүзләрне укый, укучылар аның артыннан кабатлыйлар. Авыр сүзләрне аерым укучылардан кабатлаттыра.

2) Укытучы русчасын әйтә, укучылар тәрҗемәсен әйтәләр.

3) Укучылар чылбыр буенча яңа сүзләр белән сүзтезмәләр яки җөмләләр төзеп әйтәләр.

3. Шигырь белән танышу.

1) Укытучы шигырьне сәнгатьле укып күрсәтә.

2) Шигырьне укучылар үзлекләреннән укыйлар.

3) Укытучы, сораулар ярдәмендә, укучыларның аңлавын тикшерә.

— Шигырьдә нәрсә турында сүз бара?

— Шигырьнең лирик герое кем белән сөйләшә?

— Шигырьдә шагыйрь образы ничек тасвирлана?

— Ни өчен Зөлфәт шигырен «җанлы» итеп күзаллый?

4) Шигырьгә укытучы ярдәме белән анализ ясала.

Темасы: лирик геройның кичереше.

1 нче строфада шагыйрь «шигъри сүзләр сулышына» табигать күренешләрен, явым-төшемнәрне күчерергә омтыла. Ул үзенең шигырь юлларына ак кар кунуын, дала-тау җилләре кереп тулуын, таңгы алсу томан каплап алуын һ.б. тели.

2 нче строфада шагыйрь үзенең шигыренә таң балкышын, алсу чык нурын, салават күперен һ.б. дәшә. Шагыйрь үзенең шигыренә көзге яфрак тибрәлеп кагылуын, дулкын кагып үтүен тели. Шул рәвешле шагыйрь табигать күренешләрен шигырь юлларына күчерергә омтыла.

3 нче строфада шагыйрь үзенең язылган шигыренә кунакка чакыра. Автор кунакларны, шигырь басмасы аша үтеп, түргә узарга чакыра. Ә биредә: «Без тик — икәү!.. Ихлас шигырь белән икебез!» — ди ул.

5) Шигырьдән тел-сурәтләү чараларын табыгыз.

*Йолдызларның сере түгелсен* — сынландыру;

*яфрак өермәсе* — метафора;

*кайнар көзләрнең* — эпитет;

*шигырь нуры* — метафора.

**III. Рефлексив бәяләү**

1. — Дәрескә куелган уку мәсьәләсе чишелдеме? Нинди образлар белән очраштык? Аларның шигырьдәге рольләрен ачыклау (шагыйрь).

2. Бәяләү. Укучыларның дәрестә катнашулары бәяләнеп, билгеләр куела.

3. Өй эше: а) шигырьне сәнгатьле укырга өйрәнергә;

ә) шигырьне ятларга;

б) шигырь язып карарга.

4. Алдагы дәрескә проблема кую.

Укытучы, дәресне тәмамлаганчы, йомгаклап, нәтиҗә ясар өчен сораулар бирә:

— Шигырьнең лирик герое кем белән сөйләшә?
— Шигырьдә табигать күренешләренең роле нинди?
— Шигырь язуны ничек күз алдына китерәсез?

### Укытучы өчен өстәмә материал

**Строфа** — ритм ярдәмендә оешкан тезмәләр бәйләме. Татар шигыре нигездә 2, 4, тезмәле строфалардан тора. Сирәк кенә 5, 6, 7, 8 тезмәле строфалар да очрый.

## 58 нче дәрес

**Тема:** Ерактагы моңлы бер көй булып...

**Планлаштырылган нәтиҗәләр:**

Метапредмет — шагыйрьнең күңел халәтен өйрәнү. Иҗат процессына мәхәббәт тәрбияләү.

Предмет — «Шундый чагы әле җанымның» шигырен өйрәнү.

Шәхескә кагылышлы — укучыларда шагыйрь һөнәренә карата ихтирам хисләре тәрбияләү. Балаларда бәхетнең кадерен белеп яшәү хисләре тәрбияләү.

**Материал:** дәреслек (2 нче кисәк, 99—100 нче битләр).

**Җиһазлау:** мультимедиа проекторы, экран, слайдлар: шагыйрь тормышы-яшәеше, шагыйрь Зөлфәт портреты.

### Дәрес барышы:

**I. Мотивлаштыру-ориентлаштыру**

***1. Дәресне оештыру***

Дәресне башлау. Психологик уңай халәт тудыру.

***2. Актуальләштерү***

1) Алдагы дәрестә бирелгән өй эшен тикшерү.

2) Укытучы, юнәлдерүче сораулар биреп, укучылар белән күңел лирикасы турында әңгәмә кора.

— Кешенең күңел халәте нәрсәгә бәйле рәвештә үзгәрә?
— Ничек уйлыйсыз, шагыйрьнең күңел халәте шигырьләрендә чагылыш табамы?
— Яңа шигырь тусын өчен, күңел халәте нинди булырга тиеш?

***3. Уку мәсьәләсен кую***

Бүгенге дәреснең темасы — Зөлфәтнең «Шундый чагы әле җанымның» шигырен уку.

Темадан чыгып, дәрескә уку мәсьәләсен укучылар белән бергәләп кую.

1) Зөлфәтнең тормышы, иҗаты белән танышу.

2) «Шундый чагы әле җанымның» шигырен уку, аңлау.

3) Күңел лирикасын өйрәнү.

**II. Уку мәсьәләсен өлешләп чишү.**

1. Шигырь белән танышу.

1) Укытучы шигырьне сәнгатьле укып күрсәтә.

2) Шигырьне укучылар үзлекләреннән укыйлар.

3) Укытучы, сораулар ярдәмендә, укучыларның аңлавын тикшерә.

— Шигырьдә нәрсә турында сүз бара?

— Шагыйрьнең күңел халәте нинди?

— «Хәреф төртсәң, шигырь үсеп чыгар» юлларын ничек аңлыйсыз?

2. Сүзлек белән эш.

1) Укытучы сүзләрне укый, укучылар аның артыннан кабатлыйлар. Авыр сүзләрне аерым укучылардан кабатлаттыра.

2) Укытучы русчасын әйтә, укучылар тәрҗемәсен әйтәләр.

3) Укучылар, чылбыр буенча, яңа сүзләр белән сүзтезмәләр яки җөмләләр төзеп әйтәләр.

4) Шигырьгә укытучы ярдәме белән анализ ясала.

Темасы: лирик геройның кичереше.

1 нче строфада шагыйрь үзенең күңел халәтен тасвирлый. Хәзерге вакытта аның «иләс чагы», «хәреф төртсәң, шигырь үсеп чыга» торган вакыты. Күңел халәте шагыйрьне шигырь язарга этәрә.

2 нче строфада шагыйрь мескенлеккә «вето» салып, «яшәү дигән тантанада» яшәргә омтыла.

3 нче строфада шагыйрьнең күңел халәте үзгәрүе тагын да сизелә. Ул бу дөньяда бер үк вакытта «соңгы көчне җыеп ак болытка очып менәргә» һәм, горур канатларны җыеп, «ташланырга ташка түбәнгә» омтыла.

4 нче строфада шагыйрь үзенең биштәр асып озын юллар үтү, көтү көтү мөмкинлеге булганына сөенә.

5 нче строфада шагыйрь безгә елау һәм көлү мөмкинлеге бирелгәнлегенә сөенә.

6 нчы строфада шагыйрь үзенең шигыренең язмышын күзаллый. Ул күңеленең «ерактагы моңлы бер көй булып» ишетелүен тели.

7 нче строфада шагыйрь күңел халәтен сурәтләүне йомгаклый. Соңгы строфада шагыйрьнең күңел халәте иң югары ноктага җитә. «Шигырь чәчеп, давыл урырмын күк» дип тасвирлый ул үзенең җанын.

5) Шигырьдән тел-сурәтләү чараларын табыгыз.

*Шигырь үсеп чыгар* — сынландыру;

*Горур канатлар* — эпитет;

*Йолдыз яралганда күңелдә* — сынландыру;

*Шигырь чәчеп, давыл урырмын күк* — чагыштыру.

**III. Рефлексив бәяләү**

1. — Дәрескә куелган уку мәсьәләсе чишелдеме? Нинди образлар белән очраштык? Аларның шигырьдәге рольләрен ачыклау. (Шагыйрь, күңел лирикасы.)

2. Бәяләү. Укучыларның дәрестә катнашулары бәяләнеп, билгеләр куела.

3. Өй эше: а) шигырьне сәнгатьле укырга өйрәнергә;

ә) шигырьне ятларга;

б) шигырьгә бәйле рәвештә, шагыйрь Зөлфәтнең язмышы турында сөйләргә.

4. Алдагы дәрескә проблема кую.

Укытучы, дәресне тәмамлаганчы, йомгаклап, нәтиҗә ясар өчен сораулар бирә:

— Күңел лирикасы нәрсә ул?

— Шагыйрьнең күңел халәте нинди?

— Әдип шигыренең язмышын ничек күз алдына китерә?

— Шагыйрьнең күңел халәте үзгәреп торучан. Шуңа бәйле рәвештә, бу хис-кичерешләр шигырендә дә зур урын ала.

### Укытучы өчен өстәмә материал

**Күңел лирикасы —** лирик геройның шәхси тормышы-язмышы белән бәйле хис-кичерешләре сурәтләнгән шигырь.

## 59 нчы дәрес

**Тема:** Ил җыр белән яши.

**Планлаштырылган нәтиҗәләр**:

Метапредмет — опера сәнгате аша эстетик тәрбия бирү.

Предмет — Галия Кайбицкая иҗатын өйрәнү.

Ш ә х е с к ә  к а г ы л ы ш л ы — музыка әсәрләре аша туган илгә, туган җиргә мәхәббәт һәм ихтирам уяту.

**Материал:** дәреслек (2 нче кисәк, 103—104 нче битләр).

**Җиһазлау:** мультимедиа проекторы, экран, музыка (Галия Кайбицкая катнашкан опералар), слайдлар: Галия Кайбицкаяның портреты, сугыш темасына ясалган рәсемнәр.

**Д ә р е с  б а р ы ш ы:**

**I. Мотивлаштыру-ориентлаштыру**

***1. Дәресне оештыру***

Дәресне башлау. Психологик уңай халәт тудыру.

***2. Актуальләштерү***

1) Алдагы дәрестә бирелгән өй эшен тикшерү.

2) Укытучы, юнәлдерүче сораулар биреп, укучылар белән җыр сәнгате турында әңгәмә кора.

— Татар опера сәнгатен үз итәсезме?

— Опера әсәре язучы кайсы композиторларны беләсез?

***3. Уку мәсьәләсен кую***

Бүгенге дәреснең темасы — Галия Кайбицкаяның тормыш юлын һәм иҗатын өйрәнү.

Темадан чыгып, дәрескә уку мәсьәләсен укучылар белән бергәләп кую.

1) Галия Кайбицкаяның тормыш юлын өйрәнү;

2) Галия Кайбицкаяның иҗатын уку, операларын тыңлау.

**II. Уку мәсьәләсен өлешләп чишү**

1. Автор белән танышу

1) Укытучы композиторның тормышы һәм иҗаты белән таныштыра (презентацияләрдән файдалану).

2) Бер укучы дәреслектән Галия Кайбицкая турында белешмәне укый.

3) Укытучы, сораулар ярдәмендә, укучыларның аңлавын тикшерә. 104 нче биттәге сорауларга җавап бирелә.

— Галия Кайбицкая кайда һәм кайчан туа?

— Аның әтисе кем була?

— Актриса башкарган рольләрне санагыз. Аларның кайсылары сезгә таныш?

— Бөек Ватан сугышы чорында җырчы нәрсә белән шөгыльләнә?

2. Беренче өлешнең сүзлекчәсе белән эш.

1) Укытучы сүзләрне укый, укучылар аның артыннан кабатлыйлар. Авыр сүзләрне аерым укучылардан кабатлаттыра.

2) Укытучы русчасын әйтә, укучылар тәрҗемәсен әйтәләр.

3) Укучылар чылбыр буенча яңа сүзләр белән сүзтезмәләр яки җөмләләр төзеп әйтәләр.

3. Галия Кайбицкая башкаруында опера әсәрләрен тыңлау.

1) «Опера» төшенчәсенә аңлатма бирү.

2) Укытучы сораулар бирә:

— Әлеге опера нәрсә яки кем турында?

— Әсәрне тыңлаган вакытта нинди хисләр кичерәсез?

— Галия Кайбицкая әлеге әсәр белән ни әйтергә тели дип уйлыйсыз?

3) Хронологик таблица, сораулар төзү.

**III. Рефлексив бәяләү**

1. Укучылар дәреслектәге сорауларга җавап бирәләр.

2. Бәяләү. Укучыларның дәрестә катнашулары бәяләнеп, билгеләр куела.

3. Өй эше: а) Галия Кайбицкаяның тормыш юлы турында сөйләргә өйрәнергә;

ә) Галия Кайбицкая башкаруында опера әсәрләре турында фикер алышырга әзерләнергә;

б) Галия Кайбицкая иҗаты буенча реферат язарга.

4. Алдагы дәрескә проблема кую.

Укытучы, дәресне тәмамлаганчы, йомгаклап, нәтиҗә ясау өчен сораулар бирә:

— Бөек Ватан сугышы чорында Галия Кайбицкая нинди эш башкара?

— Галия Кайбицкая иҗаты татар опера сәнгатендә нинди роль уйный?

### Укытучы өчен өстәмә материал

**Опера** (ит. *opera* — әсәр) — синтетик сәнгать әсәре. Ул үзендә сәхнә сәләте таләп иткән уен коралында уйнала торган вокал (ялгыз, ансамбль, хор белән җырлау) һәм (симфоник) музыканы, драматургия, шулай ук сурәтле сәнгать әсәрләрен (декорация, костюмнар һ.б.), еш кына хореография (балет) номерларын бергә җыя. Операның структурасы аның идеясе, төп фикере, әдәби сценарийның (либреттоның) сюжеты белән билгеләнә. Операның төп авторы — композитор. Ул, әдәби либретто тексты белән эш итсә дә, музыка драматургиясен тудыра. Опера музыкасының түбәндәге формалары бар: вокаль (ария, ариозо, моно-

лог), ансамбль (дуэт, трио, квартет һ.б.), хор номерлары; биюләр, оркестр номерлары (увертюра, антракт, симфоник картина һ.б.). Опера, мөстәкыйль жанр буларак, Яңарыш чоры идеяләре яктылыгында XVI гасырда Флоренциядә (Италия) барлыкка килә.

## 60—61 нче дәресләр

**Тема:** Сәхнә хуҗасы.

**Планлаштырылган нәтиҗәләр:**

М е т а п р е д м е т — укучыларга сәнгатькә мәхәббәт тәрбиясе бирү.

П р е д м е т — язучының тормыш юлы һәм иҗаты турында белешмә бирү, «Бию җене кагылган егет» кыйссасыннан өзекне өйрәнү.

Ш ә х е с к ә к а г ы л ы ш л ы — сәхнә кешесенә ихтирам тәрбияләү.

**Материал:** дәреслек (2 нче кисәк, 105—110 нче битләр).

**Җиһазлау:** мультимедиа проекторы, экран, слайдлар: Рабит Батулла портреты, китаплары, Рудольф Нуриевның тормышы һәм иҗаты турында рәсемнәр.

### Д ә р е с б а р ы ш ы:

**I. Мотивлаштыру-ориентлаштыру**

***1. Дәресне оештыру***

Исәнләшү, хәлләр сорашу, яхшы кәеф теләп, дәресне башлау. Психологик уңай халәт булдыру.

***2. Актуальләштерү***

1) Өй эшләрен тикшерү: укучыларның җавапларын тыңлау.

2) Укытучы, юнәлдерүче сораулар биреп, укучылар белән сәнгать һәм сәнгатькә хезмәт итү турында әңгәмә оештыра.

— Сез кайсы сәнгатькә караган һөнәр ияләрен беләсез? Туган җиребезгә файда китерүдә аларның роле нинди? Сез театрларга, концертларга йөрергә яратасызмы?

***3. Уку мәсьәләсен кую***

Укытучы бүген дәрестә бию сәнгате һәм сугыш вакытында аның роле турында сөйләшәчәкләрен, язучы Рабит Батулла иҗаты белән танышачакларын әйтә.

**II. Уку мәсьәләсен өлешләп чишү**

1. Автор белән танышу.

1) Укытучы, язучының китапларын, әсәрләренең эчтәлекләре буенча ясалган иллюстрацияләрне күрсәтеп, презентация ярдәмендә, аның тормышы һәм иҗаты белән таныштыра.

2) Бер укучы дәреслектән Р.Батулла турында белешмәне укый.

3) Укытучы, сораулар ярдәмендә, укучыларның аңлавын тикшерә.

— Р.Батулла кайсы якта туган?

— Ул кайда укыган?

— Аның хезмәт юлы турында нәрсәләр белдегез?

— Батулла әдәбиятның кайсы жанрларында иҗат итә? Шул турыдагы мәгълүматны тагын бер тапкыр укыгыз, фикер алышыгыз.

— Ул балалар өчен әсәрләр язганмы?

2. Сүзлек белән эш.

1) Укытучы сүзләрне укый, укучылар аның артыннан кабатлыйлар. Авыр сүзләрне аерым укучылардан кабатлаттыра. Сүзләрне әйткәндә, дөрес әйтелешкә, татар теленә генә хас булган авазларга игътибар бирергә.

2) Укытучы русчасын әйтә, укучылар тәрҗемәсен әйтәләр.

3) Укучылар чылбыр буенча яңа сүзләр белән сүзтезмәләр яки җөмләләр төзеп әйтәләр.

3. Рабит Батулланың «Бию» әсәрен өйрәнү.

1) Укучылар белән бергәләп, «культура-агарту йорты» сүзтезмәсенең мәгънәсенә төшенү.

— Сез бу бинада нәрсәләр белән шөгыльләнергә мөмкин дип уйлыйсыз?

— Анда кайсы һөнәр ияләре хезмәт куя?

2) «Бию» өзеген уку, бүлекләргә бүлү һәм исемнәр кую.

— Әсәрдә нинди концерт турында сүз бара?

— Концертны карап утыручы тамашачылар — гади тамашачымы?

4. Биремнәр һәм сорауларны дәфтәрдә эшләү.

**Икенче дәрестә** Рабит Батулла иҗатын кабатлауга тест үткәрү.

1. Әсәрдән өзек белән эшләү.

2. Өзекне укып бетергәч, әсәр эчтәлеге буенча сорауларга җавап бирү:

— Әсәр нәрсә һәм кем турында? Балалар нинди игелекле эш башкаралар?

— Сезнең әлеге әсәрләргә охшаш тагын нинди әсәрләр укыганыгыз бар?

— Биюче Рудик үзенең хезмәте белән яралыларның тормышын ничек матурлый?

— «Суфлёр», «кул чабулар» һәм «алкышлар» сүзләренең мәгънәләрен аңлатыгыз.

— «Ике яралы янәшә утыра», «Маша җырлаганда, тамашачылар да кушылды» җөмләләрен рус теленә тәрҗемә итегез. Аны дәреслектәге 5 нче сорауга җавап биргәндә файдаланыгыз.

— «Рудик матрос киеме киеп маташа» дигән юлларны укыгыз. Рудикның нинди матрос булуын ачыклагыз.

3. Дәреслектән 1—5 нче биремнәр эшләнелә. Укучылар биремнәрне үзләре укыйлар, авыр булса, тәрҗемә итәргә мөмкиннәр. Җавапны партадашлары әйтә.

**III. Рефлексив бәяләү**

1. — Дәрескә куелган уку мәсьәләсе чишелдеме?
2. Дәрескә гомуми бәя. Укучыларга билге кую.
3. Өй эше:

а) дәреслекнең 110 нчы битендәге 6 нчы биремне үтәргә;

ә) Рудольф Нуриев турында, Интернет челтәрендәге мәгълүматларга таянып, проект эше эшләргә;

б) текстның эчтәлеге буенча сораулар төзергә.

## Укытучы өчен өстәмә материал

**Батулла** (Батуллин) Рабит (Роберт) Мөхлис улы (26.03.1938, Зәй районы Түбән Лождыы (Олождыы) авылы), режиссёр, публицист.

**Тәрҗемәи хәле**

Кече театр каршындагы Щепкин исемендәге Югары театр училищесенең Татар студиясен (1961), ГИТИС каршындагы Югары режиссёрлык (1966) һәм М.Горький исемендәге Әдәбият институты каршындагы Югары әдәби курсларны (Мәскәү, 1979) тәмамлый. 1961 — 1963 нче елларда — Татар академия театры артисты. 1963 — 1965 нче елларда — Курчак театры һәм Казан телевидение студиясендә балалар өчен тапшырулар редакциясе режиссёры. 1970 — 1975 нче елларда Казан театр училищесында һәм Казан мәдәният институтында укыта.

**Иҗаты**

Әдәби иҗат белән 1960 нчы елларда шөгыльләнә башлый. 1966 нчы елда Батулланың балалар өчен язылган «Исемем минем Дүрткүз» дигән беренче китабы дөнья күрә. «Төш вакытында могҗиза» (1966), «Курай уйный бер малай» (1970) пьесалары Казан, Луцк, Омск, Донецк, Саратов, Кемерово, Салават, Махачкала шәһәрләре сәхнәләрендә куела. «Уйларымны кеше белсен» (1969), «Ташламам, җанкисәгем» (1980)

җыентыкларына кергән хикәяләре мавыктыргыч сюжетка корылулары, юморга бай булулары белән аерылып тора. Батулла әсәрләренә тормышны фәлсәфи аңлатырга омтылу хас. 1970 нче еллар башыннан профессиональ сәхнә өчен драма әсәрләре иҗат итү өстендә эшли. Яшьләрнең тормыш каршылыкларын җиңеп, мөстәкыйльлеккә омтылуларын романтик күтәренкелек белән тасвирлаган «Туйлар узгач» (1973) музыкаль комедиясе, «Өчәү юлга чыктык» (1974) драмасы, «Ярым ятларга кала» (1989) комедиясе һ.б. әсәрләре тамашачылар тарафыннан җылы кабул ителә. «Кичер мине, әнкәй!» (1979) пьесасы татар драматургиясендә зур уңыш казана. 1986 нчы елда Г. Тукай турында «Сират күпере» исемле тарихи драма яза. Батулла үзен эпик әсәрләр язучы буларак та таныта. «Юл буенда зәңгәр чәчәк» повестенда (1990) замана яшьләре проблемалары күтәрелә. «Сөембикә» (1992) романы (рус теленә тәрҗемәсе — «Сююмбике», 2001) Казан ханлыгының соңгы патшабикәсе Сөембикәнең фаҗигале язмышын сурәтләүгә багышланган. Коръән аятьләренең татарча тәфсирен әзерләп бастыра (2000). Әдәбият, сәнгать, милли-сәяси проблемаларга караган публицистик мәкаләләре белән матбугатта даими чыгып килә.

**Мактаулы исемнәре һәм бүләкләре**

ТАССРның атказанган сәнгать эшлеклесе (1985), Татарстан Республикасының Г.Тукай исемендәге Дәүләт бүләге (2006) лауреаты. Татарстан Республикасының халык язучысы (2008).

## 62 нче дәрес

**Тема:** Иҗат — ул яшәү рәвеше.

**Планлаштырылган нәтиҗәләр:**

Метапредмет — укыганны гомумиләштерә, нәтиҗә ясый, иң мөһим мәгълүматны аерып ала белү.

Предмет — иҗат процессы бүлеген гомумиләштереп кабатлау. Укучыларда иҗатка омтылыш тәрбияләү.

Шәхескә кагылышлы — укучыларда иҗат процессына, хезмәткә мәхәббәт, үз эшең белән горурлану хисләрен үстерү.

**Материал:** дәреслек (2 нче кисәк, 92—114 нче битләр).

**Җиһазлау:** мультимедиа проекторы, экран, слайдлар.

### Дәрес барышы:

**I. Мотивлаштыру-ориентлаштыру**

***1. Дәресне оештыру***

Исәнләшү, хәлләр сорашу, яхшы кәеф теләп, дәресне башлау. Психологик уңай халәт булдыру.

***2. Актуальләштерү***

1) Өй эшләрен тикшерү: Рудольф Нуриев турында проект эшләре белән танышу.

2) Укытучы, юнәлдерүче сораулар биреп, укучылар белән иҗат процессы турында әңгәмә оештыра.

**Иҗат —** кешенең рухи, матди байлыклар, культура хәзинәләрен төзүгә юнәлдерелгән мөстәкыйль эшчәнлеге («Татар теленең аңлатмалы сүзлеге»).

***3. Уку мәсьәләсен кую***

Дәрес бу бүлектә өйрәнелгән материалны гомумиләштереп кабатлау, белемнәрне тикшерү максаты белән үткәрелә. Әлеге дәресне өстәмә уку өчен бирелгән материал өстендә эшләү формасында да үткәреп була. Дәрес азагында, укучыларның белемнәрен тикшерү максатыннан, тест эшләнелә, билгеләр куела.

**II. Уку мәсьәләсен өлешләп чишү.**

1. Бүлектә өйрәнелгән теоретик материалларны кабатлау, гомумиләштерү.

2. Өстәмә уку өчен бирелгән әсәрләрнең эчтәлеген үзләштерү, әңгәмә оештыру.

3. Белемнәрне тикшерү. Тест эшләнелә.

**III. Рефлексив бәяләү**

1. «Бу — кайсы әсәрдән?» уены. Укытучы өзекләр укый, укучылар әсәрнең авторын һәм исемен атыйлар. Уенны укучылар үзләре дәвам итә алалар.

Алдан әзерләнеп килеп, сыйныфташлары каршында әсәр героена бәяләмә (характеристика) бирәләр.

2. Бәяләү. Укучыларның дәрестә катнашулары бәяләнеп, билгеләр куела.

3. Өй эше: а) өстәмә уку өчен бирелгән әсәрләрне укырга өйрәнергә;

ә) өйрәнгән әсәрләр буенча тестлар һәм сораулар төзергә (теләк буенча);

б) бер әсәрнең үзеңә ошаган эпизодына рәсем ясарга.

4. Алдагы дәрескә проблема кую.

## 63 нче дәрес

**Тема:** Батыр җайдак.

**Планлаштырылган нәтиҗәләр:**

М е т а п р е д м е т — әсәрдә тасвирланган чор турында балаларга мәгълүмат бирү. Тарихка, халкыбыз язмышына хөрмәт хисләре тәрбияләү.

П р е д м е т — укучыларның Айдар Хәлим иҗаты турындагы белемнәрен ныгыту; «Өч аяклы ат» повестеның төп фикерен ачыклый һәм аңлата белергә өйрәтү, повесть турында төшенчәне ныгыту.

Ш ә х е с к ә к а г ы л ы ш л ы — укучыларда кешелеклелек сыйфатлары, җаваплылык хисе тәрбияләү. Туганлык мөнәсәбәтләренең нык булырга тиешлеген күзаллау.

**Материал:** дәреслек (116—120 нче битләр).

**Җиһазлау:** Айдар Хәлим портреты, элеккеге авыл тормышыннан портретлар, мультимедиа, презентация, Интернет челтәреннән Айдар Хәлим повесте буенча эшләнгән «Өч аяклы ат» фильмы.

### Д ә р е с б а р ы ш ы:

**I. Мотивлаштыру-ориентлаштыру**

***1. Дәресне оештыру***

Исәнләшү, хәлләр сорашу, яхшы кәеф теләп, дәресне башлау.

Психологик уңай халәт булдыру.

***2. Актуальләштерү***

1) Алдагы дәрестә бирелгән өй эшен тикшерү.

2) Укытучы, юнәлдерүче сораулар биреп, укучылар белән авыл тормышы, атлар турында әңгәмә оештыра.

— Сезнең элеккеге авыл тормышын сурәтләгән фильмнар караганыгыз бармы?

— Тарих буенча искә төшерик: «кулак» дип кемгә әйтәләр? Ни өчен?

— Атларның авыл кешеләре тормышындагы роле нинди?

3) Һәр дәрестә яңа бүлекне укый башлаганчы, әсәрнең авторы Айдар Хәлим турында, алда укылган бүлекләр эчтәлеге буенча кыска әңгәмә.

— Алга таба вакыйгалар ничек барыр дип уйлыйсыз?

(Укучыларның үз фикерләрен тыңлау, яңа бүлекне укырга кызыксыну уяту.)

***3. Уку мәсьәләсен кую***

Айдар Хәлимнең «Өч аяклы ат» повестеның эчтәлеге белән танышырбыз, әсәрдәге образлар өстендә эшләрбез, тарихка күз салып, элеккеге авыл тормышы үзенчәлекләре белән танышырбыз.

**II. Уку мәсьәләсен өлешләп чишү**

1. Автор белән танышу.

1) Укытучы, язучының китапларын күрсәтеп, тормышы һәм иҗаты белән таныштыра (презентацияләрдән файдалану).

2) Бер укучы дәреслектән Айдар Хәлим турында белешмәне укый.

3) Интернет челтәреннән Айдар Хәлим повесте буенча эшләнгән фильмның өзеген күрсәтү.

«Өч аяклы ат» фильмының, «Алтын мөнбәр» халыкара кино фестивалендә катнашып, 100дән артык әсәр арасында беренче унлыкка керүе билгеле булды. Бу вакыйга татар киносын сөючеләр өчен аеруча зур куаныч китерде. Аның дөньяга танылу көнен татар киносы туу көне буларак билгеләп куйдылар. Аның режиссёры — безгә күп кенә татар фильмнары аша таныш ханым Нурания Җамали.

2. Айдар Хәлимнең «Өч аяклы ат» повестеның беренче өлешен уку.

3. Сүзлек өстендә эш.

1) Укытучы сүзләрне укый, укучылар аның артыннан кабатлыйлар. Авыр сүзләрне аерым укучылардан кабатлаттыра.

2) Укытучы русчасын әйтә, укучылар тәрҗемәсен әйтәләр.

4. Укытучы эчтәлекне ачу өчен сораулар бирә:

— Әсәрнең беренче өлешендә без кемнәр белән танышабыз?

а) Зөлхиҗә әби;

ә) Муса бабай;

б) Кәбир;

в) Кәбирнең әнисе Сания;

г) Бамбук исемле ат.

— Кәбир әнисе белән кая килә?

— Биредә аларны ничек каршы алалар?

— Текстта авыл тормышы ничек сурәтләнә? Шул урыннарны табып укы.

5. Әсәргә укытучы ярдәме белән анализ ясала.

Кәбир һәм аның әнисе Зөлхиҗә әби белән Муса бабайга кунакка килә.

— Укучылар, әйтегез әле, вакыйгалар кайда, кайсы чорда бара?

— Игътибар итегез: язучы малай кунакка килгән Муса бабайларның йортларын ничек сурәтли? Шул юлларны табып уку. (Күлләр акбуры белән агартылган өйдә, шактый оста, хәстәрлекле кул белән бөтәйтелгән абзар-курада, мунчада — барысында да төзеклек һәм чагыштырмача муллык сизелә. Лапас астында кышкылыкка бөгеп куелган чана табаннарын, тәгәрмәчләрне күреп, малай бабасының тракторчыдан бигрәк балта остасы икәнлегенә үз күзләре белән ышанды. Димәк, Зөлхиҗә әби белән Муса бабай мулрак тормышта яшиләр.)

— Зөлхиҗә әби белән Муса бабай кунакларны ничек каршы ала? (Шат күңел белән, елмаеп.)

— Зөлхиҗә әби белән Муса бабай Кәбирләргә кайсы яктан туган? (Зөлхиҗә әби — Кәбир әнисенең апасы, Муса бабай — җизни тиешле кеше.)

— Зөлхиҗә әби белән Муса бабай образларына характеристика бирегез.

Зөлхиҗә әби — Кәбирнең әнисенең апасы. Әсәрдә без аның ачык йөзле булуын, хуҗалык эшләре белән шөгыльләнүен күрәбез.

Муса бабай — шаян бабай. Әсәрдә аның турында менәниләр язылган: «Утызынчы еллар башында Муса бабаларын, кулаклыкта гаепләп, балалары-ниләре белән кышкы суыкта өйләреннән оекчан куып чыгарып, Акчунга озаталар, имеш. Инәсе ягыннан картинәсе белән картатасын да озаталар сөргенгә. Йортларын тартып алалар. Хәзер анда — кәнсәләр. Кәбир белә: ат дворының каравыл йорты — картатасының келәте. Мәктәпнең алгы ягы — Муса бабасыныкы. Сөргеннән котылгач, Муса бабалары, нишләптер, кире авылга кайтмады, алар менә шушы совхозга килеп урнашканнар иде...»

**III. Рефлексив бәяләү**

1. — Дәрескә куелган уку мәсьәләсе чишелдеме? Нинди образларлар белән очраштык? (Зөлхиҗә әби, Муса бабай.)

2. Бәяләү. Укучыларның дәрестә катнашулары бәяләнеп, билгеләр куела.

3. Өй эше: а) повестьны укырга, эчтәлеген өйрәнергә;

ә) әсәр буенча сорауларга җавап әзерләргә;

б) Илдә утызынчы елларда булган вакыйгалар турында әсәрдә нәрсәләр сөйләнелә? Репрессияләнгән кешеләр язмышы турында тарихтан ниләр беләсез? Шул турыда фикер алышырга әзерләнеп килергә.

4. Алдагы дәрескә проблема кую.

Укытучы, дәресне тәмамлаганчы, йомгаклап, нәтиҗә ясар өчен сорау бирә:

— Әсәрдәге геройларның үзара мөнәсәбәте нинди? (Геройлар бер-берсен якын итеп, җанатып торалар, кунакчыллык сизелә, бер-берсен ихтирам итеп сөйләшәләр. Муса бабай Кәбиргә, яратып, «улым» дип дәшә.)

### Укытучы өчен өстәмә материал

«Өч аяклы ат» әсәре авыл тормышына багышланган. Вакыйгалар үткәннәрне искә төшерү белән үрелеп бара. Анда сугыштан соңгы еллардагы татар авылы, аның гади, эшчән, әмма авыр сынауга дучар ителгән кешеләре сурәтләнә. Әсәрдә авылның тормыш-көнкүреше, кешеләр арасындагы мөнәсәбәтләр, тулы картина булып, безнең күз алдыбызга килеп баса.

А.Хәлимнең әлеге әсәрендә ил, халык язмышының аеруча катлаулы һәм фаҗигале дәвере — крестьяннарны көчләп күмәкләштерүгә мөнәсәбәте дә чагылыш тапкан. Бу чорда акыллы һәм таза тормышлы игенчеләрнең үрнәк хуҗалыкларын туздырып, аларның хәләл көч белән тупланган мал-мөлкәтләрен ирексезләп тартып алып, ил икътисадына һәм аның абруена, рухи байлыгына иксез-чиксез зыян китерелә. Сугыштан соңгы елларда авыл халкы җәбер-җәфаны, интегүләрне байтак күргән. Хезмәт көненә берни бирмичә, еллар буе бары халыктан гына сорыйлар. Кесәңнән бер башак табылса — бер ел төрмә, ике башак табылса, ике ел төрмә каралган. Ә бер кесә ашлык белән тотылсаң, башыңны ун елга төрмәгә тыгалар. Ә шушы чорда ат хәтле атны харап итсәң, бу — колхозны сафтан чыгару дигән сүз. Димәк, башың гомерең буе төрмәдә черячәк.

Сугыш арты еллары — бик авыр чор. Әтисез калган ятимнәргә тагын да авыррак. Үз көннәрен үзләре күрергә өйрәнеп, авырлыкларны җиңә-җиңә яшәгән чак. Бөтен тормыш авырлыгы — хатын-кызлар һәм балалар җилкәсендә. Ирләр юк дәрәҗәсендә. Үсмер малай Кәбир һәм аның әнисе Сания апа — шул чор корбаннары. Колхоз бик авырлык белән генә сөйрәлә. Техника юк, барлык авыр эшкә атлар җигелә. Әле алары да санаулы гына. Күп атлар сугышка җибәрелеп, шунда башларын салганнар. Лобогрейкага, сукага һәм башка колхоз эшләренә җигү өчен, Кәреш авылында нибары ике ат исәпләнә. Ашарга да такы-токы гына. Җизнәсе һәм апасы Зөлхиҗәдән хат килеп төшкәч, алар янына барырга булалар. Бер-ике капчык бәрәңге, азрак он, атланмай алып китәрсез, дигәннәр бит... Сания апа белән Кәбир тормышындагы кара көннәр шушы төннән башлана да инде.

Әсәрнең исеме — «Өч аяклы ат». Шулай аталса да, атның бер аягы бүре тешләреннән чәрдәкләнсә дә, хикмәт башкада. Аның заманасы

шундый — өч аяклы: менә-менә егылам, дип тора. Бер эшкә яраксыз Галләметдин ишеләр власть белән идарә иткәндә, шулай булмый нишләсен! Ул үзе дә болай ди бит: «Катымын! Каты булачакмын! Мин — влач! Дәүләтнең алтын баганасы. Мин бар, димәк, човет влачы бар, мин юк — човет влачы да юк!»

Ана кеше бердәнбер юанычы — улы Кәбиргә зур өметләр баглап, сабырлыгын җыеп, бөтен көчен эшкә бирә. Сания апа ниләр генә күрми, нинди авырлыкларга гына түзми! Аның чыдамлыгына, түземлегенә сокланмау мөмкин түгел. Сугышта батырларча үлеп калган иренә булган мәхәббәтне олы бер хис итеп саклый. Мәхәббәтенә хыянәт итүне ул уйлап та карый алмый. Күпме газап-михнәтләр чиксә чигәр, башкайлары төрмәләргә керсә керер, ләкин ул намусына тап төшермәс!

Әсәрдән эчке бер җылылык бөркелеп тора. Әсәрнең төп герое — Кәбир исемле үсмер малай. Ул үзенең ихласлыгы һәм авырлыклар алдында югалып калмый торган көчле рухлылыгы белән безнең күңелләрне яулый. Ул ат җанлы. Андыйлар турында «хайван җене кагылган» дип әйтәләр. Бамбук — малай өчен бик якын җан иясе. Атны суйганда өзгәләнеп кычкырулары әле дә колакларда яңгырый. Дусты белән ат йөрәген кадерләп күмүләрен генә искә төшерик... Ике дус җирне тырный-тырный кабер казый. Бамбук каберенә киләчәктә һәйкәл кую, ай һәм йолдыз сурәте төшерү уйларында. Кәбир нечкә күңелле. Аның атка булган мөнәсәбәте дә сокландыргыч. Атны иң олы ярату белән ярата белә шул ул.

Нинди генә кыенлыклар, кимсетелү-җәберләүләр , михнәт-газаплар күрергә туры килми аларга! Әнисен хаксызга мыскыл иткән колхоз бригадирының ямьсез гамәлләренә ул түзеп тора алмый. Явызлык, намуссызлык, шәфкатьсезлек хакимлек итмәскә тиеш! Алар тиешле җәзаларын алырга тиешләр! Колхоз бригадиры Галләметдин, лейтенант Шәрифуллин ишеләр, үз вазифаларыннан файдаланып, хезмәт ияләренә кол итеп карап, аларны төрлечә мәсхәрәләргә һәм кешелек сыйфатларын санга сукмаска тырышалар. Гуманлылык күзлегеннән караганда, Санияне, гомер буе шул колхозда тир түккән фронтовик хатыны булуын исәпкә алып, кичерергә тиешләр иде кебек. Ләкин юк. Яшьли үк Саниягә кызыгып, аның мәхәббәтен кире какканы өчен, үч алу тойгысы уяна Галләметдиндә. Алар — икейөзле, әхлаксыз, эчкече, имансыз бәндәләр. Галләметдиннәргә «ил», «халык», «вөҗдан» кебек олы мәгънәгә ия булган сүзләр — бары абстракт төшенчәләр генә. Бары байлык, муллык һәм рәхәтлек китергән төшенчәләр генә алар тарафыннан хөрмәт ителә, кадерләнә. Бер эшкә яраксыз хөрәсәннәрнең колхоз малын эчеп ятулары гына җитмәгән, әле алар фронтовик хатыны Саниянең алтын-көмешләрен урлап чыгудан да тартынып тормыйлар. Участковыйның яла ягуы, нигезсез дәлилләр китерүе күңелдә андый кешеләргә карата җирәнү хисләре тудыра. Лейтенант Шәрифуллин

фронтовик хатынына түбәндәге уйдырма гаепләр табып, нахак бәла яга: «Үзегезнең раскулачивать ителгән ат нәселеннән икәнен белеп зыянлаттыгызмы? Җизнәгезгә сугымга калдырдыгызмы? Җизнәгезнең абзарына бернинди дә бүре төшмәгән. Совет властеның борынгы дошманы аның аягын махсус сындырган. Соң булса да уң булсын, дип, киткән малын кире кайтарырга уйлаган. Бик беләсегез килсә, ул аны суеп та ашаган. Бу — сезнең алдан уйлап эшләгән җинаятегез. Менә җизнәгезнең атны суеп, базарга чыгарып сатуы турында жалоба». Шулай да Галәметдин кебек мәкерле, астыртын, хәйләле, кешелексез бәндәләр халык әхлагының күркәм сыйфатларын гәүдәләндергән намуслы яшәүче хезмәт ияләре алдында көчсез.

Кәбирнең күңелендә әлеге хаксыз рәнҗетүләр, мыскыллауларга карата көчле протест уяна. Аның җаны ярсый, бәргәләнә. Галәметдин кебек, властьтан файдаланып, итәк астыннан эш йөртүчеләрнең мыскыллы карарларын нигезсез, законсыз дип саный. Аның әнисенә тагылган нахак гаепләүләргә җаны җәрәхәтләнә, күңеле сыкрана. «Үсеп кенә җитим, кирәкләрен бирермен мин аларның», — дип күңеленә салып куя. Шулай да ул җебеп-сыгылып төшми, үзендә алга таба барырга тагы да зуррак көч туплый бара. Тормыш рәхимсезлеге белән көрәшергә үзендә бетмәс- төкәнмәс көч таба. Әнисе Сания апаны бары бер генә нәрсә коткара ала — Бамбукны алып кайтып, аның исән икәнлеген раслау. Бәрелеп-сугылып, төрле кыенлыкларга очрап, сазлыкларда бата-бата, чегәннәргә юлыгып, аның эзенә төшәргә теләгән бригадир һәм участковыйлардан яшеренеп, ул, исән-имин килеш, атны үз авылларына — Кәрешкә алып кайтып җиткерә. Аңа ана мәхәббәте, җитезлеге, уңганлыгы бу бәладән чын егетләрчә чыгарга мөмкинлек бирә. Ананың — балага, баланың анага булган мәхәббәте таш-кыяларны да җимерергә, явызлыкларны җиңәргә сәләтле шул!

Әсәрнең ахыры үкенечле бетә. Дөрес, Галләметдин җәза ала алуын. Атны суйдырган өчен, авыл халкы, абзарда тезләндереп, аңа тизәк ашата. Санияне дә өенә кайтаралар, әнисен дә Галләметдин ише адәмнәрдән якларга сүз бирәләр. Тик менә Кәбир генә Бамбуксыз кала...

*Р. Гарифуллина*

## 64 нче дәрес

**Тема:** Фронттан кайткан ат.

**Планлаштырылган нәтиҗәләр:**

М е т а п р е д м е т — «шәҗәрә» төшенчәсенә аңлатма бирү. Шәҗәрәне белү зарурлыгының сәбәпләрен ачыклау.

П р е д м е т — «Өч аяклы ат» повестен өйрәнүне дәвам итү.

Ш ә х е с к ә к а г ы л ы ш л ы — хайваннарга карата мәхәббәт, миһербанлылык хисләре тәрбияләү.

**Материал:** дәреслек (2 нче кисәк, 120—124 нче битләр).

**Җиһазлау:** мультимедиа проекторы, экран, слайдлар: авыл тормышы, атлар сурәтләгән рәсемнәр.

### Дәрес барышы:

**I. Мотивлаштыру-ориентлаштыру**

***1. Дәресне оештыру***

Дәресне башлау. Психологик уңай халәт тудыру.

***2. Актуальләштерү***

1) Алдагы дәрестә бирелгән өй эшен тикшерү.

2) Укытучы, юнәлдерүче сораулар биреп, укучылар белән халкыбызның тормыш-көнкүреше турында әңгәмә кора.

— Элеккеге авыл өен сурәтләп бирегез.

— Хуҗалыкта нинди йорт хайваннары бар?

***3. Уку мәсьәләсен кую***

Бүгенге дәреснең темасы — Айдар Хәлимнең «Өч аяклы ат» повестен укуны дәвам итү.

Темадан чыгып, дәрескә уку мәсьәләсен укучылар белән бергәләп кую.

1) Айдар Хәлимнең тормышы, иҗаты белән танышу.

2) «Өч аяклы ат» повестен уку, аңлау.

**II. Уку мәсьәләсен өлешләп чишү.**

1. Айдар Хәлимнең «Өч аяклы ат» повестеның алдагы бүлекләрен укуны дәвам итү.

— Әсәрнең исеменә игътибар итик әле. (Атлар турында фикер алышу.)

— Сез атлар турында ниләр беләсез?

Ат — гаҗәеп камил җан иясе. Ул — көчле, җитез, чыдам, бик сизгер һәм сак. Текә ярга якын килмәс, куркыныч җиргә керер алдыннан туктап калыр, колакларын боргалап, шомрайтып, башын сузып, зур дымлы күзләрен алга төбәп, бөтен гәүдәсе белән калтыранып, билгесезлектән хәбәр алырга омтылыр. Ат башын бормыйча да тирә-якны тулаем һәм караңгыда да күрү сәләтенә ия. Ул йөзә белә. Атның тәм тоюы һәм ис сизүе бик көчле. Үзенең колынын ул иснәп таба, үз йөгәнен таный, пычрак суны, бозылган ризыкны капмас. Әгәр солы белән ясмыкны

кушып алдына салсаң, ат аларны аера — солы бетә, ясмык кала. Атның тәне бик сизгер. Ат сүзләрне аңлый, кешенең халәтен тоя, мактаганга, ачуланганга битараф түгел, ул гаделлекне ярата. Ат кешегә тугры, шул ук вакытта бар кешегә дә тигез карамый. Авыл кешеләре, атның аягы да күрә, диләр. Шундый очрак була: 2 яшьлек бала ат көтүе кайта торган юлга чыга. Көтү үтеп китә — бер генә ат та балага басмый. Ат бер үткән юлны яхшы хәтерли. «Ат юлга бер күнеп алса, йоклаган килеш тә йөри», — дигән сынамыш яши.

2. Сүзлек өстендә эш.

1) Укытучы сүзләрне укый, укучылар аның артыннан кабатлыйлар. Авыр сүзләрне аерым укучылардан кабатлаттыра.

2) Укытучы русчасын әйтә, укучылар тәрҗемәсен әйтәләр.

3. Укытучы эчтәлекне ачу өчен сораулар бирә:

— Әсәрдә ат ничек тасвирлана?

— Кәбир атны ничек тәрбияли?

— Муса бабайның йорты ничек сурәтләнә? Шул урыннарны табып укыгыз.

4. Повестька укытучы ярдәме белән анализ ясала.

Повестьта Муса бабай белән Кәбирнең ат турында сөйләшүләре сурәтләнә.

— Малай атны ничек карый? Әсәрдән шул урыннарны табып укыгыз. (Малай, йөгертеп, бер чиләк су алып килде. Җиң очларын сызганып, яшел үлән учмасын сулы чиләккә тыгып, икесе ике яктан атның сыртын, янбашын юл тузаны, тир һәм тоздан чистарта башладылар.)

Муса бабай белән Кәбир тамак ялгау өчен өйгә керәләр.

— Кәбир Муса бабайның өендәге нинди яңалыкларга игътибар итә? Әсәрдән шул урыннарны табып укыгыз.

— Иң беренче итеп күзе төшкән нәрсәләр — куерып килгән караңгыда келт-келт итеп йөреп яткан ике герле сәгать һәм үзүзенә мыгырданып торган «кара эшләпә» иде. Мондый сәгатькә бер аптыраса, малай кара эшләпәгә ике аптырады: «радио» дигәннәре шушы икән!.. (радио)

Бабасы ишек катындагы ниндидер кара сәйләнгә басты, һәм бөтен өй эче ялт итеп яктырып китте. Мич тирәсендә кайнашкан әбисе дә, шунда сәке читенә кунаклаган әнисе дә нурдан коендылар... (электр)

Кәбир Муса бабай өендә хыялында гына йөрткән тәм-томнар белән сыйлана һәм, арып, йокыга тала.

— Кәбир ниләр ашый?

— Табын уртасындагы хуш исле йомшак бодай икмәге, кызыл бөрлегән һәм чия салып кайнатылган сары май, җиләк кайнатмасы, ул гына дисезме — бер таба йомырка тәбәсе һәм куырылган балык, сөт өсте салынган куе чәй — болар барысы да Кәбир күрмәгән оҗмах ризыклары иде.

**III. Рефлексив бәяләү**

1. — Дәрескә куелган уку мәсьәләсе чишелдеме?

2. Бәяләү. Укучыларның дәрестә катнашулары бәяләнеп, билгеләр куела.

3. Өй эше: а) повестьның икенче өлешен укырга, эчтәлеген сөйләргә әзерләнергә;

ә) Муса бабай белән Кәбир диалогын рольләргә бүлеп укырга әзерләнергә;

б) ат җигү һәм тугару тәртибе турында мәгълүмат тупларга һәм сөйләргә әзерләнергә.

4. Алдагы дәрескә проблема кую.

Укытучы, дәресне тәмамлаганчы, йомгаклап, нәтиҗә ясар өчен сораулар бирә:

— Кәбир тормышында ат нинди роль уйный?

— Муса бабайның өе ничек сурәтләнә?

— Зөлхиҗә әби белән Муса бабайның Кәбиргә мөнәсәбәте нинди?

**Укытучы өчен өстәмә материал**

Ат асраучылык, терлекчелек тармагы борынгы дәвердә барлыкка килә (Европа һәм Азиядә б.э.к. IV меңьеллыктан мәгълүм). Ат, кулга һәм йортка ияләштерүдән соң, хәрби эштә, кешеләрнең хуҗалык һәм рухи тормышында әһәмиятле роль уйный. Күп кенә борынгы халыкларда (шул исәптән скифлар, һуннар, төркиләр, Урта Идел һәм Урал алды халыклары) ат асраучылык хуҗалыктагы төп шөгыльләрнең берсе булып санала.

Атны кулга ияләштерү якынча моннан 6 мең еллар элек башланган дип исәплиләр. Кешеләр бу вакытта эт, сарык, кәҗә, сыер кебек хайваннарны кулга ияләштергән булган инде. Ат кебек сизгер җан иясен үзенә буйсындырганчы, күрәсең, борынгы кешегә җитәрлек көч һәм тәҗрибә тупларга кирәк булган. Кыргый хайваннарны кулга ияләштерүнең ничек булуы турында фаразлар аз түгел. Акрынлык белән кеше үзенә ияләштергән атларның бик акыллы, сизгер, кирәк вакытта хуҗасын яклый да белгәне ачыклана (ат бит ул бүредән дә

курыкмый). Атны кулга ияләштергән кеше тормышында әзләнүләр, зур ачышлар чоры башланган: ат белән йөк ташу, юл йөрү һ.б. Моның өчен ат дирбияләре, тәгәрмәч, арба кебек әйберләр уйлап табылган. Даһи ачышлар булган бу. Авызлык, йөгән, өзәңге, ияр — һәрберсе атны хуҗалыкта файдалану өчен уйлап табылган, атлы дөнья мең еллар дәвамында кулланачак җайланмалар (дирбияләр) бит. Ат иярләгәч, иген игү, мал асрау, ерткычлардан саклану, төзелеш эшләре, казылма байлыклар эзләү күпкә җиңеләйгән һәм җитештерү арткан. Ат борынгы кешенең авыр эшләрен үзенә алып кына калмаган, аңа тирә-якны танып белергә, табигатьтәге урынын аңларга да ярдәм иткән. Атның көче, сизгерлеге, сакчыл кыюлыгы кешегә дә күчкән. Әлеге мал кешегә көч һәм дәрт өстәгән, тормышында оешканлык һәм тизлек тудырган.

## 65 нче дәрес

**Тема:** Авырлык җебе өзелде.

**Планлаштырылган нәтиҗәләр:**

М е т а п р е д м е т — авыл тормышы, атлар турында мәгълүмат бирү. Укыганны гомумиләштерә, нәтиҗә ясый, иң мөһим мәгълүматны аерып ала белү.

П р е д м е т — «Өч аяклы ат» повестен өйрәнүне дәвам итү.

Ш ә х е с к ә к а г ы л ы ш л ы — укучыларда туган илгә, йорт хайваннарына карата мәхәббәт, белем алуга омтылыш тәрбияләү.

**Материал:** дәреслек (2 нче кисәк, 125—128 нче битләр).

**Җиһазлау:** мультимедиа проекторы, экран, слайдлар: авыл тормышы, атлар сурәтләнгән портретлар.

### Д ә р е с б а р ы ш ы :

**I. Мотивлаштыру-ориентлаштыру**

***1. Дәресне оештыру***

Дәресне башлау. Психологик уңай халәт тудыру.

***2. Актуальләштерү***

1) Алдагы дәрестә бирелгән өй эшен тикшерү.

2) Укытучы, юнәлдерүче сораулар биреп, укучылар белән атлар турында әңгәмә кора.

— Атлар авыл кешесе тормышында нинди роль уйный?

— Ат нинди сыйфатларга ия?

— Атны ничек җигәләр?

***3. Уку мәсьәләсен кую***

Бүгенге дәреснең темасы — Айдар Хәлимнең «Өч аяклы ат» повестен укуны дәвам итү.

Темадан чыгып, дәрескә уку мәсьәләсен укучылар белән бергәләп кую.

1) Айдар Хәлимнең тормышы, иҗаты белән танышу.

2) «Өч аяклы ат» повестен уку, аңлау.

**II. Уку мәсьәләсен өлешләп чишү.**

1. Айдар Хәлимнең «Өч аяклы ат» повестен укуны дәвам итү.

— Кешенең күңел халәтен сурәтләүне әдәбиятта ничек атыйлар? (Психологизм.)

1) Атлар турында алдагы дәрестә үтелгән материал буенча белгәннәрне искә төшерү.

— Сез атлар турында ниләр беләсез?

— Бамбук Кәбир тормышында нинди роль уйный?

— Куркыныч килгәндә ат үзен ничек тота?

2. Сүзлек өстендә эш.

1) Укытучы сүзләрне укый, укучылар аның артыннан кабатлыйлар. Авыр сүзләрне аерым укучылардан кабатлаттыра.

2) Укытучы русчасын әйтә, укучылар тәрҗемәсен әйтәләр.

3. Укытучы эчтәлекне ачу өчен сораулар бирә:

— Повесть нинди күңелсез вакыйга белән башланып китә?

— Кәбир көтелмәгән вакыйгада үзен ничек тота?

— Муса бабай ветеринарга әлеге фаҗигане ничек аңлата?

4. Повестька укытучы ярдәме белән анализ ясала.

«Балакаем, атыбызны... бугазлады бит!..» дигән шомлы тавышка Кәбир уянып китә. Йорт эчендә бөтен кеше чабыша, фонарь эзлиләр.

— Төнлә нинди вакыйга була? (Бүре, килеп, абзардагы бер сарыкны бугазлаган, ә Бамбук бүре белән көрәшкән вакытта бер аягын авырттырган.)

Көтелмәгән мондый вакыйгада Кәбир, үзен кулга алып, Муса бабайга ярдәм итәргә ашыга.

— Кәбир әнисен нинди сүзләр белән тынычландырырга тырыша? Әсәрдән шул урынны табып укыгыз. (Инәй, ат исән! — дип кычкырды пычак эзләгән арада Кәбир. — Атка берни дә булмаган!)

Кәбир абзарга чыкканда, күршеләре дә җыелып өлгергән иде. Муса бабай, вата-җимерә, рус телендә, әлеге вакыйганы Әндри (Андрей) исемле ветеринарга аңлата.

— Муса бабай белән Андрей (ветеринар) диалогын рольләргә бүлеп укыгыз. Муса бабай сөйләменә бәя бирегез. Төзәтеп укыгыз.

Бүре белән «якалашкан» вакытта, атның күкрәк турысыннан «кул яссуы кадәр ит умырып алынган иде». Ат авыртуга чыдый алмыйча, пошкырып җибәрә. Моннан тыш атның, бүре белән көрәшкән вакытта, бер аягын авырттыруы ачыклана.

— Әсәрдә атның аягы авыртуның сәбәпләре ничек аңлатыла? (Бүре белән якалашкан чакта, ат аягын утлыкка тыгып сындырган, я булмаса буын сеңерен өздергән булырга тиеш. Икенчеләр фараз итүенчә, ат — кешедән һәм эттән кала иң акыллы һәм иң сизгер җан иясе: ул абзарда малларны пыран-заран китергән җанварның чынлап та бүре икәнлеген исеннән сизгән һәм, үзүзенә урын таба алмый, аранны җимереп, мал-туарны коткарышырга чыккан, имеш.)

Әлеге вакыйганы Кәбирнең әнисе бик авыр кичерә. Малай атның исән калуына бер яктан шатланса, икенче яктан атның аягы авыртуына бик борчыла.

— Кәбирнең күңел халәтен сурәтләгән өзекне әсәрдән табып укыгыз. (Кәбирнең миендә нәрсәдер ялт итеп яктырды, анда гүя яңа кояш кабынды. Бу яктыда бар дөнья ап-ачык күренгәндәй итте. Җир белән күк, тау белән үзән, ут белән су арасында гына түгел, хәтта үзенең йөрәгендә дә ниндидер төп — гомерне күтәреп торган авырлык җебе өзелгәндәй итте, һәм ул җеп тиз генә ялганмаячак иде.)

5. Бүлеккә исем кую.

6. Дәреслекнең 108 нче битендәге биремнәрне эшләү.

**III. Рефлексив бәяләү**

1. — Дәрескә куелган уку мәсьәләсе чишелдеме?

— Әсәр башында булган фаҗига Кәбиргә, аның әнисенә, Муса бабайга, Зөлхиҗә әбигә ничек тәэсир итә?

— Бамбук бүре белән ничек көрәшә?

— Ат киләчәктә йөри алыр дип уйлыйсызмы?

2. Бәяләү. Укучыларның дәрестә катнашулары бәяләнеп, билгеләр куела.

3. Өй эше: а) повестьның өченче өлешен укырга, эчтәлеген сөйләргә әзерләнергә;

ә) Муса бабай белән Әндринең диалогын рольләргә бүлеп укырга әзерләнергә;

б) Кәбирнең халәте сурәтләнгән өзекне рус теленә тәрҗемә итәргә.

4. Алдагы дәрескә проблема кую.

Укытучы, дәресне тәмамлаганчы, йомгаклап, нәтиҗә ясар өчен сораулар бирә:

— Әсәр нәрсәгә багышланган?

— «Өч аяклы ат» әсәре авыл тормышына багышланган.

— Әсәрнең исеме ни өчен шулай атала? Әсәрдә тасвирланган чор турында нәрсә әйтә аласыз?

— Әсәрнең исеме — «Өч аяклы ат». Шулай аталса да, атның бер аягы бүре тешләреннән чәрдәкләнсә дә, хикмәт башкада. Аның заманасы шундый — өч аяклы: менә-менә егылам дип тора.

## 66—67 нче дәресләр

**Тема:** Табигатьнең чәчәк аткан чагы.

**Планлаштырылган нәтиҗәләр:**

Метапредмет — табигатьнең үзенчәлеге, уникальлеге турында яңа фикерләр тудыру.

Предмет — Гарәфи Хәсәновның тормыш юлы, иҗаты турында белү һәм «Беренче күк күкрәү» хикәясен уку.

Шәхескә кагылышлы — әйләнә-тирә мохиткә хөрмәт булдыру, табигатьне яратырга өйрәтү.

**Материал:** дәреслек (2 нче кисәк, 128—133 нче битләр).

**Җиһазлау:** Гәрәфи Хәсәнов турында презентация, китаплары, портреты, табигать күренешләре ясалган картиналар, табигать тавышы (чишмә, яңгыр, кошлар сайравы, урман тавышы һ.б.)

### Дәрес барышы:

**I. Мотивлаштыру-ориентлаштыру өлеше**

***1. Дәресне оештыру***

Исәнләшү, дәресне башлау. Хәлләрен, нинди кәеф белән килүләрен сорашу. Психологик уңай халәт тудыру.

***2. Актуальләштерү***

Өй эшен тикшерү.

Айдар Хәлимнең «Өч аяклы ат» повесте буенча фикер алышу.

— Әсәрдә сурәтләнгән чорны тасвирлагыз.

— Төп геройның исемен атагыз. Аңа сыйфатлама бирегез.

— Язучы нинди идея үткәрә?

***3. Уку мәсьәләсен кую***

Гарәфи Хәсәновның тормыш юлы һәм иҗаты турында сөйләү. «Беренче күк күкрәү» хикәясен укый башлау.

**II. Уку мәсьәләсен өлешләп чишү**

1. Гарәфи Хәсәновның тормыш юлы, иҗаты белән танышу. Бу — укытучы сөйләве, презентация карау, алдан әзерләнгән укучыларның чыгышлары да булырга мөмкин.

2. Дәреслектәге биографик белешмә белән укучыларның танышуы. Сорауларга җавап бирү.

3. Сүзлек эше.

Дәреслектә бирелгән сүзләрне уку. Аңлашылмаган яңа сүзләрне сүзлек дәфтәренә язу.

4. Биографиягә нәтиҗә ясап кую. Хронологик таблица тутыру.

5. «Беренче күк күкрәү» хикәясенең беренче, икенче өлешләрен уку. Уку барышында сораулар бирелеп барыла, җаваплар белән ныгытыла.

— Әсәрдә табигатьнең кайсы фасылы сурәтләнә?

— Яз табигатьнең нинди вакыты? (Уянган вакыты, яңадан туган вакыты.)

6. Образлар турында.

— Әсәрдә нинди образлар белән таныштыгыз? (Бөре, табигать, кошлар һ. б.)

7. Әсәрнең эчтәлегенә караган сораулар.

— Әсәрнең әлеге өлешендә нәрсә сурәтләнә? (Табигать.)

— Табигатьтәге нинди күренешләр күзәтелә?

— Күк күкрәү нәрсә турында хәбәр итә? (Җәй җитүен.)

— Күк күкрәүне тасвирлаган өлешне табып укыгыз.

— Әсәрдә кайсы кошлар турында сөйләнелә? (Күке, сыерчык.)

— Нинди үләннәр һәм агачлар тасвирлана? (Имән, усак, зирек, мамыкбашлар, төнбоек, тавык үләннәре, каен һ.б.)

8. Әсәрнең сюжетына караган сораулар.

— Темасы? (Хикәянең темасы — табигать).

— Автор безгә әлеге хикәясе белән нәрсә әйтергә теләгән? (Автор идеясе — табигатьнең үзенчәлекле якларын, уникаль күренеш булуын күрсәтергә теләү. Автор идеяне хикәянең башыннан ахырына кадәр алып бара.)

9. Теоретик төшенчәләр: сурәтләү чаралары, метафора, литота, чагыштыру. Авторның сөйләм теле. Татар теленең лексик байлыгы, фразеологизмнар.

10. Дәреслектәге сорауларга җаваплар бирү.

**III. Рефлексив бәяләү**

1. Нәтиҗә чыгару.

2. Дәрескә гомуми бәя. Укучыларга билге кую.

3. Өй эше: а) әсәрнең эчтәлеген сөйләргә;

ә) аерым бер табигать күренеше турында сочинение язарга;

б) әсәрнең 1 абзацын тәрҗемә итеп килергә.

4. Алдагы дәрескә проблема кую.

— Табигать безнең өчен нәрсә ул?

— Автор үзен табигатьнең бер өлеше итеп күрәме?

— «Кеше һәм табигать — уңай һәм тискәре мөнәсәбәт» дигәнне ничек аңлыйсыз?

## 68 нче дәрес

**Тема:** Ямьле сабан туйлары.

**Планлаштырылган нәтиҗәләр:**

М е т а п р е д м е т — халкыбыз бәйрәмнәре аша эстетик тәрбия бирү.

П р е д м е т — Камил Кәримовның тормыш юлын һәм иҗатын өйрәнү, «Тимергали бабай хикәяте»н уку.

Ш ә х е с к ә к а г ы л ы ш л ы — тарихи үткәнебезгә ихтирам, туган җиргә, хезмәткә мәхәббәт тәрбияләү.

**Материал:** дәреслек (2 нче кисәк, 133—137 нче битләр).

**Җиһазлау:** әдип турында презентация, Сабантуй күренешләре белән картиналар, Сабантуй турында мәгълүмат.

### Д ә р е с б а р ы ш ы:

**I. Мотивлаштыру-ориентлаштыру өлеше**

***1. Дәресне оештыру***

Исәнләшү, дәресне башлау. Хәлләрен, нинди кәеф белән килүләрен сорашу. Психологик уңай халәт тудыру.

***2. Актуальләштерү***

1) Гәрәфи Хәсәновның «Беренче күк күкрәү» хикәясе искә төшерелә.

2) Укучылар табигать күренеше турында хикәяләрен укыйлар.

***3. Уку мәсьәләсен кую***

Камил Кәримовның тормыш юлы һәм иҗаты турында уку, сорауларга җавап бирү. «Тимергали бабай хикәяте»н уку.

Халкыбызның гореф-гадәтләре турында сөйләшү, ел фасылларына туры килгән бәйрәмнәребезне искә төшерү.

— Укучылар, без бүген сезнең белән татар халкының тарихы, гореф-гадәтләре белән танышырбыз. Безнең дәреснең темасы — «Ямьле сабан туйлары».

**II. Уку мәсьәләсен өлешләп чишү**

1. Камил Кәримовның тормыш юлы, иҗаты белән танышу.

Бу — укытучы сөйләве, презентация карау, алдан әзерләнгән материал белән таныштыру.

2. Дәреслектәге биографик белешмә белән укучыларның танышуы. Сорауларга җавап бирү: алдан әзерләнгән карточкаларда сораулар, парларда яки төркемнәрдә сорау — җавап.

3. Сүзлек эше.

Яңа сүзләрне сүзлек дәфтәренә язу, укып чыгу.

4. «Тимергали бабай хикәяте» белән танышу.

Әсәрнең төзелеше буенча сораулар:

— Әсәр башында нәрсә сурәтләнә? Табып укып күрсәт.

— Бәйрәмгә әзерләнгән малайның гаилә хәле нинди?

— Геройның исеме ничек?

— Әсәт кем ул?

— Зәйтүнә — Хәбибрахманга, ә Хәбибрахман Зәйтүнәгә нәрсә бирә? Әлеге гадәт хәзер дә саклангынмы?

— Сабан туенда нинди вакыйгалар була? Әсәт белән Тимер нинди уеннарда катнашалар?

— Сез нинди уеннар уйныйсыз?

— Тимер кемнәрне яратмый? Сез ничек уйлыйсыз, ни өчен?

— Шәмсенур белән Мәрфуга кем?

Әсәрнең эчтәлеге буенча сораулар:

— Автор нәрсә турында язган, нәрсә сурәтләгән?

— Әсәрдә кайсы еллар сурәтләнә?

— Вакыйга кайда бара?

— Татар халкының тагын нинди гореф-гадәтләре бар?

— Сабантуй бәйрәме турында тагынниләр беләсез?

— *Сабан* һәм *туй* сүзләрен аңлатыгыз.

— Чәчүләр беткәч үткәрелгән әлеге бәйрәм авыр хезмәттән соң күңел ачу өчен булган. Тагын нинди бәйрәмнәр беләсез? (Сөмбелә, уңыш бәйрәме.)

— Хәзерге үткәрелгән сабан туе элек үткәрелгән сабан туена ошаганмы?

— Әлеге әсәр белән автор нәрсә әйтергә теләгән?

5. Образлар турында:

— Тимергали нинди сыйфатларга ия?

— Әсәт нинди?

— Малайларның бала чаклары ничек уза?

6. Әсәрнең планын төзү һәм сөйләргә әзерләнү.

1) Тимергали Сабантуйга әзерләнә.

2) Тимергали Әсәт белән көрешә һәм Зәйтүнәнең бүләген Хәбибрахманга илтеп бирә.

3) Сабантуй.

4) Мәрфуга белән Шакир.

5) Шәмсенур.

7. Дәреслектәге сорауларга җаваплар бирү.

**III. Рефлексив бәяләү**

1. Нәтиҗә чыгару.

2. Дәрескә гомуми бәя. Укучыларга билге кую.

3. Өй эше: а) план буенча хикәянең эчтәлеген сөйләргә;

ә) «Татар халкы һәм башка халыклар бәйрәмнәре» темасына, төркемнәргә бүленеп, проект эше әзерләргә.

б) хикәядә Сабантуй күренеше сурәтләнгән өлешне сөйләргә.

4. Алдагы дәрескә проблема кую.

— Халыкларга йолалар ни өчен кирәк?

— Тарихны онытмаска йолалар ничек ярдәм итә ала?

— Сез халкыбызда сакланып калган тагын нинди йолалар белән таныш?

### Укытучы өчен өстәмә материал

**Аулак өй.** Олы кешеләр өйдә юк чакта, буйга җиткән кызлы йортта аулак өй үткәргәннәр. Анда кызлар төрле кул эшләре эшләгәннәр, тәмле ризыклар пешереп сыйланганнар. Аулак өйләргә егетләр кертелмәгән. Тәртип саклау максатыннан, өлкән яшьтәге берәр хатын-кыз яки әбине чакырганнар. Аулак өй авыл яңалыклары, аш-су турындагы сөйләшүләрдән башланган, җыр-бию, төрле уеннар белән дәвам иткән.

**Җиләк бәйрәме** җәй башында җиләк өлгергән чорда уздырылган. «Чәчәк бәйрәме» һәм «Такыя бәйрәме» кебек үк, ул яшь кызларның ял итү һәм күңел ачу бәйрәме булып та саналган.

**Җыен.** Традиция буенча алдан билгеләнгән бер көнне авыл халкы күрше авыл кешеләрен кунакка чакыра. Гадәттә, бу бәйрәм җомга көнне башланган һәм өч-дүрт көн дәвам иткән. Җыенны һәрвакыт җәй көне, урак эшләре башланганчы бәйрәм иткәннәр. Аңа әзерлек эшләре алдан алып барылган. Яшьләр тарафыннан оештырыла торган кайбер уеннар һәм күңел ачулар Сабантуй бәйрәмендәгеләргә охшаш булган.

Ләкин ат чабышлары, көрәш һәм башка спорт ярышларының уздырылмавы белән җыен Сабантуйдан бик нык аерылып торган. Аның каравы, җыр, бию, музыка көне буе бер дә тынып тормаган. Кызлар, егетләр, бергәләп, рәхәтләнеп, күңел ачканнар, ял иткәннәр. Җыен вакытында егетләр тирә-юнь авыллардан җыелган кызларга күз салганнар: очрашканнар, кавышканнар, соңыннан — парлашканнар. Кыскасы, җыен яшьләр арасында киң таралган бәйрәмнәрнең берсе булган.

**Каз өмәсе.** Беренче салкыннар башланып, кар төшү белән, авыл кешеләре йорт кошларын: каз, үрдәк, күркәләрне суеп, кышлык ит әзерли. Шуның белән язгы, җәйге һәм көзге мәшәкатьләргә күпмедер дәрәҗәдә нәтиҗә ясала. Каз өмәсе, бер яктан, татар халкының рухи байлыгын, әхлакый сафлыгын, югары тәрбиягә ия булуын билгели. Өмә мәзәксез, җыр-биюсез, музыкасыз буламени?! Аның әле тагын бер ягы булган: өмә — яшьләрнең, гашыйкларның бер-берсе белән танышу, очрашу урыны да.

**Карга боткасы, карга туе** — XIX гасырда бу бәйрәм балалар бәйрәме генә булып саналган. Аны иртә язда, кара җир күренә башлагач, аксакаллар әйткән аерым бер көнне үткәргәннәр. Бала-чага, авыл буенча өйдән-өйгә кереп, ярма, сөт, май, йомырка җыеп йөргәннәр. Шулай җыйган ризыклардан болында, тауда, басуда, бер-ике өлкән яшьтәге хатын-кыз җитәкчелегендә, зур казанда ботка пешергәннәр. Сыйланырга бөтен авыл баласы җыелган. Һәркайсы савыт, кашык алып килгән. Шунда төрле уеннар уйный торган булганнар.

**Сабантуй** — игенчелек белән көн күргән Идел буе Казан татарларының бик борынгы бәйрәмнәреннән берсе. Ул язгы кыр эшләре тәмамлану хөрмәтенә үткәрелгән. Сабантуй бәйрәмен уздыру ике өлештән тора: 1) бүләк җыю; 2) бәйрәм уздыру.

**Урнаш өй** яки **урнаш кичәсе** — аулак өйнең бер төре. Ул шулай ук хуҗалар өйдә юк вакытта егетләр яки кызлар тарафыннан оештырылган. Урнаш өйнең ишекләре һәркем өчен ачык булган. Бу кичәләрдә кызлар бер дә кул эшләре тотмаганнар. Бирегә бары тик күңел ачу һәм ял итү өчен генә җыелганнар. Мондый кичәләр көзге яки кышкы кичләрдә, эштән бушаган араларда үткәрелгән.

## 69 нчы дәрес (кабатлау дәресе)

**Тема:** «Ялкын» журналына сәяхәт.

**Планлаштырылган нәтиҗәләр:**

М е т а п р е д м е т — укыганны гомумиләштереп нәтиҗә ясый, иң мөһим мәгълүматны аерып ала белү.

П р е д м е т — «Ялкын» журналы белән танышу.

Ш ә х е с к ә к а г ы л ы ш л ы — белем алуга омтылыш тәрбияләү.

**Материал:** дәреслек (2 нче кисәк, 137—138 нче битләр).

**Җиһазлау:** «Ялкын» журналлары, презентация, «Ялкын» журналы белән бәйле шәхесләр портреты.

**Дәрес барышы:**

**I. Мотивлаштыру-ориентлаштыру өлеше**

***1. Дәресне оештыру***

Исәнләшү, дәресне башлау. Хәлләрен, нинди кәеф белән килүләрен сорашу. Психологик уңай халәт тудыру.

***2. Актуальләштерү***

Узган дәрестә бирелгән өй эшен тикшерү, сораулар бирү.

— Камил Кәримовның тормыш юлын һәм иҗатын искә төшерү.

— «Тимергали бабай хикәяте»нә кагылган сорауларга җавап бирү.

— Укучылар алып килгән проектларны (йолалар, бәйрәмнәр турында) тыңлау.

***3. Уку мәсьәләсен кую***

Дәресебезнең максаты «Ялкын» журналы белән якыннанрак танышу һәм әлеге бүлекне тәмамлау.

**II. Уку мәсьәләсен өлешләп чишү**

1. Дәрес бу бүлектә өйрәнелгән материалны гомумиләштереп кабатлау, белемнәрне тикшерү максаты белән үткәрелә. Әлеге дәресне өстәмә уку өчен бирелгән материал өстендә эшләү формасында да үткәреп була. Дәрес азагында, укучыларның белемнәрен тикшерү максатыннан, тест эшләнелә, билгеләр куела.

2. «Ялкын» журналы тарихы, бүгенгесе белән танышу. Бу — укытучы сөйләве, презентация карау, алдан әзерләнгән укучыларның чыгышлары да булырга мөмкин.

3. Дәреслектәге белешмә белән укучыларның танышуы. Сорауларга җавап бирү: алдан әзерләнгән карточкаларда — сораулар, парларда яки төркемнәрдә сорау — җавап.

4. Сүзлек эше.

Аңлашылмаган яңа сүзләрне табу, уку, сүзлеккә язу.

5. «Ялкын» журналы турында диалог.

— Сез журнал белән ничә яшьтән таныш?

— Журнал ничә яшьтәге укучылар өчен чыгарыла?

— Сез ничек уйлыйсыз: хәзерге көндә журнал актуальме?

— Редакторы булсагыз, сез журналга нинди яңалыклар, бүлекләр өстәр идегез?

— Сезнеңчә, журнал чыгару хезмәте авырмы?

— «Ялкын» журналының тарихына күз салыйк. Журналга хәзерге көндә ничә яшь?

— Журналның исеме ни өчен шулай бик еш үзгәргән? Бу нәрсә белән бәйле? ( Тарихтагы вакыйгалар белән, заман үзгәрешләренә бәйле.)

— «Ялкын» журналы кебек озын тарихлы тагын кайсы журналлар белән таныштык? («Көлсәң — көл, еласаң — ела!» бүлегендәге журналлар искә төшерелә.)

6. Образлар турында.

— Журнал белән бәйле нинди танылган шәхесләрне беләсез? («Ялкын» журналының тәүге саны 1924 нче елның 20 нче мартында Мәскәүдә дөнья күрә. Ул вакытта журнал «Кечкенә иптәшләр» дип атала. Басманың чишмә башында Муса Җәлил белән Абдулла Алиш тора. 90 еллык тарихында басманың исеме берничә тапкыр үзгәрә. Сугыш елларында журнал чыгудан туктап тора. Сугыш елларыннан соң, аның беренче баш мөхәррире — балалар язучысы Ләбибә Ихсанова, җаваплы сәркатибе — шагыйрь Илдар Юзеев. 1954 нче елда журналга «Ялкын» исеме бирелә. Бүгенге көнгә чаклы ул шулай дип атала. Журналның аудиториясе — 6—18 яшьлек балалар һәм үсмерләр. Эчтәлек ягыннан журнал өч бүлектән тора: минем мәктәбем, минем бүлмәм, минем көндәлегем. «Ялкын» битләрендә психолог киңәшләре, мастер-класслар, укучы хатлары, постерлар, афишалар, танылган шәхесләрнең көндәлекләре һ.б. басыла.)

7. Теоретик төшенчәләр: афиша, бүлекләр, баш бит, эчтәлек һ.б.

8. Дәреслектәге сорауларга җаваплар бирү.

9. Бүлекне тәмамлау.

1) Дәреслектәге биремнәрне үтәү.

2) Сорауларга җавап бирү.

3) Төркемнәрдә чыгасы журнал турында сөйләшү (бер үк журнал кабатланмасын), эшләрне бүлү.

**III. Рефлексив бәяләү**

1. Нәтиҗә чыгару.

2. Дәрескә гомуми бәя. Укучыларга билге кую.

3. Өй эше: а) журнал турындагы белешмәне сөйләргә өйрәнергә;

ә) төркемнәрдә журнал чыгарырга, реклама ясарга;

б) «Күңелемә уелып калган әсәрләр». Үзеңә ошаган, өстәмә уку өчен бирелгән әсәрләр буенча әңгәмәгә әзерләнеп килергә.

4. Алдагы дәрескә проблема кую.

— Хәзерге көндә татар телен саклауда журналның роле нидә?

— Сез ничек уйлыйсыз: хәзерге заманда нинди журналлар аеруча актуаль?

— Интернет-ресурслар тулы заманда журналлар кирәкме?

### Укытучы өчен өстәмә материал

**«Ялкын»** — урта һәм олы яшьтәге мәктәп балаларының айлык татар журналы. 1924 нче елдан бирле чыга. Абдулла Алиш, Муса Җәлил премияләре лауреаты. Бүгенге көндә баш мөхәррире — Йолдыз Миңнуллина.

***Тарихы***

1924 нче елда «Татарстан» газетасында Муса Җәлилнең 9—14 яшьлек балалар өчен журнал чыгарырга кирәклеге турында мәкаләсе басылып чыга. Шул ук елның 20 нче мартында Мәскәүдә «Кечкенә иптәшләр» дип аталучы балалар журналының беренче саны дөнья күрә. Журнал гарәп язуында була. Беренче редакторы — Х.Курмаев. 1928 нче елдан «Кечкенә иптәшләр» латин графикасына күчеп, «Октябрь баласы» дип атала башлый. 1933 нче елда журнал Казанга кайта, «Пионер каләме»нә әверелә. 1941 нче елда, сугыш башлангач, журнал чыгудан туктала. Сугыш беткәч, 1952 нче елда ул «Пионер» исеме белән янә дөнья күрә.

***Казанышлар***

«Ялкын» журналы «Почёт Билгесе» ордены кавалеры, ике тапкыр «Бәллүр каләм» бәйгесе лауреаты, «СМИ — Вся Россия — 2000» конкурсы дипломанты, А. Алиш премиясе һәм Муса Җәлил премияләре лауреаты (2011 нче елның 15 нче февралендә игълан ителде), «Матбугатның алтын фонды» мактау билгесенә лаек булды.

## 70 нче дәрес — йомгаклау дәресе

**Тема:** «Әдәбият» дигән олы диңгез...

**Планлаштырылган нәтиҗәләр:**

Метапредмет — өйрәнелгән теоретик төшенчәләрне кабатлау, истә калдыру.

П р е д м е т — ел буе өйрәнгәннәрне гомумиләштереп кабатлау.

Ш ә х е с к ә к а г ы л ы ш л ы — әдәбиятның тәрбия бирү, тормышка әзерләү дәресе булуын аңлату.

**Материал:** дәреслек, методик әсбап, кушымтадагы тестлар.

**Җиһазлау:** мультимедиа проекторы, экран (такта), слайдларда быел өйрәнгән язучыларның рәсемнәре, тестларның биремнәре (кабатлау өчен бергәләп эшләү).

**Д ә р е с б а р ы ш ы :**

**I. Мотивлаштыру-ориентлаштыру өлеше**

***1. Дәресне оештыру***

Исәнләшү, укучыларның хәлләрен сорашу, психологик уңай халәт тудыру.

***2. Актуальләштерү***

Өй эшләрен тикшерү. Төркемнәр үзләре чыгарган журнал белән таныштыралар, реклама ясыйлар.

***3. Уку мәсьәләсен кую***

Укытучы бүгенге дәрестә ел буе өйрәнгәннәрне кабатлау, йомгаклау, нәтиҗә ясаячаклары турында әйтә.

**II. Уку мәсьәләсен өлешләп чишү**

1. Портретлар, төрле иллюстрацияләр, презентацияләр белән, укылган әсәрләрне кабатлау, бүлекләрне искә төшерү, гомумиләштерү.

2. Экранда күрсәтелгән тест сорауларына җавап бирү (истә калсын өчен, бергәләп эшләү).

3. «Күңелемә уелып калган әсәрләр». Укучыларга өстәмә уку өчен бирелгән әсәрләрнең эчтәлеге буенча әңгәмә оештыру.

**III. Рефлексив бәяләү**

1. — Дәрескә куелган уку мәсьәләсе чишелдеме?

2. Дәрескә гомуми бәя. Укучыларның еллык белемнәрен бәяләү.

## БҮЛЕКНЕ ЙОМГАКЛАУ ӨЧЕН ТЕСТЛАР

### Тарих китабында безнең өчен бик күп хатирәләр саклана...

| I вариант | II вариант |
|---|---|
| **1. Риваятьләр ничә төркемгә бүленә?**<br>а) 2<br>ә) 5<br>б) 3<br>**2. Тарихи риваятьне күрсәтегез:**<br>а) «Сихерче кыз»<br>ә) «Хан кызы Алтынчәч»<br>б) «Утсыз кайный торган казан»<br>**3. Риваятьләрне кем иҗат иткән?**<br>а) язучылар<br>ә) шагыйрьләр<br>б) халык<br>**4. Шәһәр, авыл, елга атамаларының килеп чыгышы турындагы риваять:**<br>а) көнкүреш риваяте<br>ә) топонимик риваять<br>б) тарихи риваять<br>**5. Дөрес булмаган җавапны табыгыз. Легенда төрләре:**<br>а) көнкүреш<br>ә) зоогоник<br>б) сәяси<br>6. Дөрес җавапны табыгыз. «Местер Стуруом» —<br>а) татар халык легендасы<br>ә) борынгы шотланд легендасы<br>б) Урта гасыр Европа халкы риваяте<br>**7. «Сихерче кыз» риваятендә кыз еланнарны ничек җыңә?**<br>а) чокырда яндыра<br>ә) агулый<br>б) үтерә | **1. Легендалар ничә төркемгә бүленә?**<br>а) 7<br>ә) 8<br>б) 9<br>2. «Күке каян барлыкка килгән?» легендасының төре:<br>а) топонимик<br>ә) космогоник<br>б) зоогоник<br>**3. Легендаларны кем иҗат иткән?**<br>а) язучылар<br>ә) шагыйрьләр<br>б) халык<br>**4. Тарихи вакыйгалар һәм шәхесләр турындагы риваять:**<br>а) көнкүреш риваять<br>ә) тарихи риваять<br>б) топонимик риваять<br>**5. Дөрес булмаган җавапны табыгыз. Легенда төрләре:**<br>а) космогоник<br>ә) фәлсәфи<br>б) этногоник<br>6. Дөрес җавапны табыгыз. «Моргана» —<br>а) татар халык риваяте<br>ә) Урта гасыр Европа халкы риваяте<br>б) борынгы шотланд легендасы<br>**7. «Гали тугае» риваятендә кайсы бәйрәм турында әйтелә?**<br>а) Сабантуй<br>ә) Нәүрүз<br>б) Яңа ел |

| | |
|---|---|
| **8. «Гали тугае» риваятендә Гали нишли?**<br>а) көндәшен җиңә<br>ә) тугай үстерә<br>б) хайваннар үстерә<br>**9. «Һомай кошы» әсәренең авторы кем?**<br>а) Фәнис Яруллин<br>ә) Әмирхан Еники<br>б) Фәрит Яхин<br>**10. Татар халык музыкаль уен коралы —**<br>а) баян<br>ә) балалайка<br>б) скрипка | **8. «Зөһрә кыз» легендасында Зөһрәнең нинди теләге тормышка аша?**<br>а) Зөһрә яңа күлмәкле була<br>ә) Зөһрә Айга аша<br>б) Зөһрә укырга керә<br>**9. «Курай» әсәренең авторы кем?**<br>а) Әмирхан Еники<br>ә) Фәрит Яхин<br>б) Фәнис Яруллин<br>**10. Татар халык музыкаль уен коралы —**<br>а) балалайка<br>ә) курай<br>б) гитара |

## Без тарихта эзлебез

| I вариант | II вариант |
|---|---|
| **1. Сәяхәтнамә жанрының рус теленә тәрҗемәсен табыгыз:**<br>а) летопись<br>ә) дорожные заметки (хождения)<br>б) исторический роман<br>**2. Ибне Фадлан кайсы дәүләткә сәяхәте турында яза?**<br>а) Казан ханлыгы<br>ә) Алтын Урда<br>б) Болгар<br>**3. «Аурупа сәяхәтнамәсе»нең авторы кем?**<br>а) Фатих Кәрими<br>ә) Габдулла Тукай<br>б) Миргазыян Юныс<br>**4. Миргазиян Юныс әдәбиятта кайсы жанрга нигез сала?**<br>а) тарихи роман<br>ә) диңгезчелек (маринистика)<br>б) эпистоляр жанр | **1. Елъязма жанрының рус теленә тәрҗемәсен табыгыз:**<br>а) дорожные заметки (хождения)<br>ә) исторический роман<br>б) летопись<br>**2. Ибне Фадлан Болгар дәүләтенә сәфәре турында нәрсә яза?**<br>а) елъязма<br>ә) сәяхәтнамә<br>б) биографик хикәя<br>**3. «Аурупа сәяхәтнамәсе»ндә Фатих Кәрими нәрсәгә игътибар итә?**<br>а) табигать<br>ә) культура учаклары<br>б) халык<br>**4. Миргазиян Юныс язучылыктан тыш тагын кем булып танылган?**<br>а) сынчы<br>ә) рәссам<br>б) композитор |

| | |
|---|---|
| **5. Габдулла Тукай ничәнче елда туа?**<br>а) 1886<br>ә) 1889<br>б) 1901<br>**6. Г.Тукайның «Пар ат» шигыре кайчан языла?**<br>а) 1905<br>ә) 1906<br>б) 1907<br>**7. Татарстан Республикасының Габдулла Тукай исемендәге Дәүләт премиясе беренче тапкыр ничәнче елда бирелә?**<br>а) 1958<br>ә) 1960<br>б) 1962<br>**8. Бакый Урманче кайда туа?**<br>а) Дүртөйле районы Миңеште авылы<br>ә) Буа районы Күл-Черкене авылы<br>б) Сарман районы Яңа Бүләк авылы<br>**9. «Агыйделдә — ак пароход» әсәренең авторы кем?**<br>а) Нажар Нәҗми<br>ә) Габдулла Тукай<br>б) Әхсән Баян<br>**10. Триптих ничә өлештән тора?**<br>а) ике<br>ә) өч<br>б) дүрт | **5. «Пар ат» поэмасында автор кая юл тота?**<br>а) Казанга<br>ә) Җаекка<br>б) Түбән Новгородка<br>**6. Габдулла Тукай Җаектан Казанга ничәнче елда кайта?**<br>а) 1906<br>ә) 1907<br>б) 1908<br>**7. Татарстан Республикасының Габдулла Тукай исемендәге Дәүләт премиясе кайсы көнне тапшырыла?**<br>а) Сабан туенда<br>ә) Г.Тукайның туган көнендә<br>б) Яңа елда<br>**8. Бакый Урманче кайчан туа?**<br>а) 1893 ел, 27 февраль<br>ә) 1895 ел, 13 февраль<br>б) 1897 ел, 23 февраль<br>**9. Нажар Нәҗми иҗат иткән әсәрнең исеме —**<br>а) «Агыйделдә — ак пароход»<br>ә) «Хыялда туган калам»<br>б) «Казан дастаны»<br>**10. Илһам Шакиров —**<br>а) язучы<br>ә) җырчы<br>б) рәссам, сынчы |

## Онытылмас еллар

| I вариант | II вариант |
|---|---|
| **1. Виктор Куделькинның «Билгесез биеклектә» картинасының темасы —**<br>а) авыл | **1. Фатих Кәрим кайсы әдәби жанрларда иҗат иткән?**<br>а) шигырь, поэма<br>ә) хикәя, роман |

ә) сугыш
б) табигать

**2. «Ант» шигыренең авторы кем?**
а) Муса Җәлил
ә) Фатих Кәрим
б) Сибгат Хәким

**3. «Кыңгыраулы яшел гармун» поэмасында вакыйгалар кайда бара?**
а) өй
ә) фронт
б) госпиталь

**4. Туфан Миңнуллин кайчан туа?**
а) 1935 ел, 25 август
ә) 1936 ел, 26 август
б) 1937 ел, 27 август

**5. Т.Миңнуллинның «Моңлы бер җыр» драмасы кемне гәүдәләндерә?**
а) Муса Җәлил
ә) Габдулла Тукай
б) Абдулла Алиш

**6. Дөрес җавапны табыгыз. Марсель Сәлимҗанов —**
а) язучы, публицист
ә) актёр, режиссёр
б) композитор

**7. Эпистоляр жанр нинди формада яши?**
а) елъязма
ә) сәяхәтнамә
б) хат, телеграмма, открытка

**8. Муса Җәлил кызының исеме ничек?**
а) Чулпан
ә) Әминә
б) Рәйханә

**9. Мостай Кәрим кайсы халык шагыйре, язучысы?**
а) татар-үзбәк
ә) татар-башкорт
б) татар-кыргыз

б) драма әсәрләре

**2. «Кыңгыраулы яшел гармун» поэмасында төп образ —**
а) Әхмәт
ә) Фатих
б) Фазыл

**3. Фатих Кәримнең герое нәрсәдә уйный?**
а) гармунда
ә) баянда
б) курайда

**4. Туфан Миңнуллин кайда туа?**
а) Кама Тамагы районы Олы Мәрәтхуҗа авылы
ә) Казан шәһәре
б) Чүпрәле районы Кече Чынлы авылы

**5. Т.Миңнуллинның «Моңлы бер җыр» әсәре жанры буенча —**
а) поэма
ә) драма
б) хикәя

**6. Дөрес җавапны табыгыз. Ринат Таҗетдинов —**
а) актёр
ә) язучы
б) рәссам

**7. Төшеп калган сүз урынына кайсын куярсыз? ... — билгеле бер өслектә ясалган һәм фонның үз өслегеннән сурәт үзе яки аерым фигуралары чыгып торган махсус скульптур рәсем.**
а) һәйкәл
ә) барельеф
б) триптих

**8. Җәлилчеләр ничәү була?**
а) 9
ә) 10
б) 11

**9. «Билгесез солдат» шигыренең авторы кем?**
а) Мостай Кәрим

| | |
|---|---|
| **10. Чыңгыз Айтматовның «Анам кыры» әсәрендәге ананың исеме —**<br>а) Тулганай<br>ә) Җайнак<br>б) Фирүзә | ә) Муса Җәлил<br>б) Чыңгыз Айтматов<br>**10.Чыңгыз Айтматовның «Анам кыры» әсәренең темасы —**<br>а) сугыш<br>ә) табигать<br>б) сәясәт |

**Әтинең зур бүреге иртә киелде...**

| I вариант | II вариант |
|---|---|
| **1. Клара Булатова —**<br>а) язучы<br>ә) шагыйрә<br>б) публицист<br>**2. «Җиңү көне» шигыренең авторы кем?**<br>а) Клара Булатова<br>ә) Фатих Кәрим<br>б) Нур Әхмәдиев<br>**3. «Минем туган көнем» әсәрендә кызга ничә яшь тула?**<br>а) дүрт<br>ә) биш<br>б) алты<br>**4. «Тулганай» хикәясендә вакыйгалар кайда бара?**<br>а) шәһәрдә<br>ә) авылда<br>б) урманда<br>**5. «Тулганай» әсәрендәге малайларның исеме —**<br>а) Камил, Фирүз<br>ә) Камил, Фаил<br>б) Таһир, Камил<br>**6. Тулганайга исемне кем бирә?**<br>а) малайлар<br>ә) малайларның әниләре<br>б) малайларның әтиләре | **1. «Башым иям» шигырендә автор нәрсәне исенә төшерә?**<br>а) балачагын<br>ә) дустын<br>б) этен<br>**2. «Минем туган көнем» әсәрен кем хикәяли?**<br>а) Әдипнең әнисе<br>ә) Әдипнең кызы<br>б) Әдип исемле абый<br>**3. «Минем туган көнем» әсәрендә Диләрә Әдипкә нәрсә бүләк итә?**<br>а) туп<br>ә) кулъяулык<br>б) уенчык<br>**4. Факил Сафин кайда туа?**<br>а) Татарстанның Мөслим районы<br>ә) Татарстанның Арча районы<br>б) Татарстанның Сарман районы<br>**5. «Тулганай» хикәясен кем язган?**<br>а) Нур Әхмәдиев<br>ә) Факил Сафин<br>б) Разил Вәлиев<br>**6. «Тулганай» хикәясендә малайлар нәрсә табалар?**<br>а) эт баласы<br>ә) песи баласы<br>б) керпе баласы |

| | |
|---|---|
| **7. «Ватаным» шигыренең авторы —**<br>а) Роберт Миңнуллин<br>ә) Фирдәвес Әһлия<br>б) Разил Вәлиев<br>**8. Разил Вәлиев кайда туа?**<br>а) Татарстанның Азнакай районы<br>ә) Татарстанның Түбән Кама районы<br>б) Татарстанның Саба районы<br>**9. Әдәбияттан тыш, Р.Вәлиев тагын кем буларак билгеле?**<br>а) халык депутаты<br>ә) рәссам<br>б) укытучы<br>**10. «Сез кайсы халыктан? — дисәләр,**<br>**Батырлар исемен атадым», — юллары кайсы шигырьдән?**<br>а) Нур Әхмәдиев. «Җиңү көне»<br>ә) Разил Вәлиев. «Ватаным»<br>б) Клара Булатова. «Башым иям» | **7. Разил Вәлиев кайчан туа?**<br>а) 1947<br>ә) 1948<br>б) 1949<br>**8. Дөрес җавапны табыгыз. Разил Вәлиев —**<br>а) актёр, җырчы<br>ә) язучы, шагыйрь<br>б) рәссам, сынчы<br>**9. «Дуслык тау күчерә» мәкале кайсы әсәргә туры килә?**<br>а) «Минем туган көнем»<br>ә) «Тулганай»<br>б) «Башым иям»<br>**10. «Кемгәдер ул салют булып кергән,**<br>**Соңгы ату булган кемгәдер», — юллары кайсы шигырьдән?**<br>а) Нур Әхмәдиев. «Җиңү көне»<br>ә) Клара Булатова. «Башым иям»<br>б) Разил Вәлиев. «Ватаным» |

**Ана — изге, Ана — бөек, аңа — дан!**
**Аңлар өчен йөрәгенең олылыгын,**
**Туу кирәк кайчак безгә яңадан!**

| I вариант | II вариант |
|---|---|
| **1. Шәриф Камал кайчан туган?**<br>а) 1878 елның 3 маенда<br>ә) 1886 елның 5 мартында<br>б) 1884 елның 27 февралендә<br>**2. Шәриф Камал кайда белем ала?**<br>а) «Мөхәммәдия» мәдрәсәсендә<br>ә) авыл мәдрәсәсендә<br>б) «Күл буе» мәдрәсәсендә | **1. Шәриф Камал кайда туган?**<br>а) Башкортстан Республикасында<br>ә) Мордва Республикасында<br>б) Казанда<br>**2. Шәриф Камал кем?**<br>а) шагыйрь<br>ә) укытучы<br>б) язучы, драматург<br>**3. «Буранда» әсәрендә Мостафа кая ашыга?**<br>а) әнисе янына<br>ә) туган авылына |

**3. «Буранда» әсәренең төп герое кем?**
а) Хөсәен
ә) Мостафа
б) Фатыйма
**4. «Халык дошманы» дип кулга алынган язучы —**
а) Ибраһим Салахов
ә) Шәриф Камал
б) Сибгат Хәким
**5. «Ана тавышы» өзегендә вакыйга кайда бара?**
а) сугышта
ә) авылда
б) тимер юл вокзалында
**6. Габдулла Тукай Казанда нинди газетада эшли?**
а) «Әл-ислах»
ә) «Фикер»
б) «Яшен»
**7. «Су буеннан әнкәй кайтып килә, Каз каурые алган кулына» шигъри юлларының авторы кем?**
а) Марсель Галиев
ә) Роберт Миңнуллин
б) Шәриф Хөсәенов
**8. Луиза Батыр-Болгари кем ул?**
а) композитор
ә) шагыйрә
б) актриса
**9. «Әни килде» әсәре жанр буенча —**
а) комедия
ә) драма
б) трагедия
**10. «Таң җиле» романының авторы —**
а) Габдулла Тукай
ә) Ибраһим Салахов
б) Фоат Садриев

б) иптәше Хөсәенгә
**4. Репрессияләнгән язучылар —**
а) Габдулла Тукай, Фатих Кәрими, Дәрдемәнд
ә) Муса Җәлил, Абдулла Алиш, Габдрахман Әпсәләмов
б) Гурий Тавлин, Фатих Кәрим, Ибраһим Салахов
**5. Ибраһим Салаховның «Колыма хикәяләре» әсәре нинди темага багышланган?**
а) сугыш темасына
ә) репрессия темасына
б) авыл темасына
**6. Сибгат Хәким шигырьләре:**
а) «Туган тел», «Туган авыл»
ә) «Туган ил», «Дүрт матур сүз»
б) «Әнкәй», «Җырларымда телим...»
**7. «Әнкәй безне Сөннән алып кайткан, Сөн суында юган иң элек» шигъри юлларының авторы кем?**
а) Сибгат Хәким
ә) Роберт Миңнуллин
б) Марсель Галиев
**8. Шәриф Хөсәенов кем ул?**
а) драматург
ә) шагыйрь
б) композитор
**9. «Әни килде» әсәрендә Ана нинди бәйрәмгә туры килә?**
а) кызының туган көненә
ә) Яңа елга
б) улының туена
**10. «Таң җиле» романында карчыкның исеме —**
а) Фәридә
ә) Нуриасма
б) Нәсимә

**Көлсәң — көл,**
**Еласаң — ела!**

| I вариант | II вариант |
|---|---|
| **1. Татарларда беренче сатирик басма үрнәкләре —**<br>а) «Уклар», «Карчыга» журналлары<br>ә) «Чаян», «Сатирикон» журналлары<br>б) «Чикерткә», «Туп» журналлары<br>**2. Беренче сатирик басмаларда кемнәр эшли?**<br>а) Галиәсгар Камал, Кәрим Тинчурин<br>ә) Әхмәт Урманчиев, Фатих Әмирхан<br>б) Габдулла Тукай, Шакир Мөхәммәдев<br>**3. Сатирик журналларның төп максаты —**<br>а) җәмгыятьтәге гаделсезлекләрне фаш итү<br>ә) байлардан көлү<br>б) халыкны яклау<br>**4. «Банкрот» пьесасының авторы кем?**<br>а) Галиәсгар Камал<br>ә) Габдулла Кариев<br>б) Зәки Нури<br>**5. Галиәсгар Камал кайда туа?**<br>а) Уфада<br>ә) Казанда<br>б) Арчада<br>**6. Билгеләмәне дәвам итегез. Вакыйга-күренешләр, хәрәкәт нигезенә салынган характер-лар һәм хәлләр, карашлар һәм тормыш принципларының бәрелешүе —**<br>а) проблема | **1. Татарларда беренче сатирик басмалар кайчан дөнья күрә?**<br>а) 1903 — 1905 елларда<br>ә) 1905 — 1907 елларда<br>б) 1907 — 1909 елларда<br>**2. «Ялт-Йолт» журналының мөхәррире —**<br>а) Габдулла Тукай<br>ә) Шакир Мөхәммәдев<br>б) Әхмәт Урманчиев<br>**3. Билгеләмәне дәвам итегез. Көлкенең бер төре, иҗатчының сурәтләү предметы-на тискәре мөнәсәбәт белдерүе —**<br>а) юмор<br>ә) сатира<br>б) ирония<br>**4. Татар сәхнәсендә юмор-сатира юнәлешен, көлке чараларын үстерүгә зур өлеш керткән драматург —**<br>а) Габдулла Тукай<br>ә) Кәрим Тинчурин<br>б) Галиәсгар Камал<br>**5. «Банкрот» пьесасының төп герое —**<br>а) Җамалетдин<br>ә) Гөлҗиһан<br>б) Сираҗетдин<br>**6. «Банкрот» пьесасында Сираҗетдиннең максаты нәрсә?**<br>а) акча үзләштерү<br>ә) хатынын алдалау<br>б) банк талау<br>**7. Габдулла Кариев кайда туа?**<br>а) Актаныш районы Тактала-чык авылы |

| | |
|---|---|
| ә) сатира<br>б) конфликт<br>**7. Габдулла Кариев кем ул?**<br>а) актёр, татар театрына нигез салучыларның берсе<br>ә) драматург<br>б) язучы, сатира жанрына нигез салучы<br>**8. Габдулла Кариевның музее кайда урнашкан?**<br>а) Арча районы, Кырлай авылында<br>ә) Казанда<br>б) Нурлат районы Күлбай Мораса авылында<br>**9. Дөрес билгеләмәне табыгыз. Ирония —**<br>а) бәяләп көлү<br>ә) кешене, җәмгыятькә хас тискәре гадәтләрне, әклакый бозыклыкларны тәнкыйтьләү<br>б) иҗатчының күренешләргә тискәре мөнәсәбәтен белдерүе<br>**10. Билгеләмәне дәвам итегез. Пародия —**<br>а) кешенең нинди дә булса килеп җитмәгән ягыннан яки иҗтимагый күренешләрдән көлеп язылган зур булмаган сатирик шигырь<br>ә) иҗатчының күренешләргә тискәре мөнәсәбәтен белдерүе<br>б) әдәби әсәргә яки әсәрләр төркеменә көлкеле ияру | ә) Нурлат районы Күлбай Мораса авылы<br>б) Казан<br>**8. Габдулла Кариев язган әсәр кайсы?**<br>а) «Юл газабы»<br>ә) «Беренче театр»<br>б) «Фәтхулла хәзрәт»<br>**9. Дөрес билгеләмәне табыгыз. Сатирик шигырь —**<br>а) шигырь формасында бәяләп көлү<br>ә) шигырь формасында кешене, җәмгыятькә хас тискәре гадәтләрне, әклакый бозыклыкларны тәнкыйтьләү<br>б) көлкенең бер төре, иҗатчының сурәтләү предметына тискәре мөнәсәбәт белдерүе<br>**10. Билгеләмәне дәвам итегез. Эпиграмма —**<br>а) әдәби әсәргә яки әсәрләр төркеменә көлкеле ияру<br>ә) кешенең нинди дә булса килеп җитмәгән ягыннан яки иҗтимагый күренешләрдән көлеп язылган зур булмаган сатирик шигырь<br>б) иҗатчының күренешләргә тискәре мөнәсәбәтен белдерүе |

### Даһи гомере — халкы хәтерендә!

| **I вариант** | **II вариант** |
|---|---|
| **1. «Гармунчы» поэмасының авторы кем?**<br>а) Муса Җәлил | **1. Ренат Харис кайсы әдәби жанрларда иҗат итә?**<br>а) шигырь, поэма |

ә) Ренат Харис
б) Зөлфәт
**2. «Гармунчы» әсәренең жанрын билгеләгез.**
а) шигырь
ә) поэма
б) баллада
**3. Ренат Харис ничәнче елда туа?**
а) 1941
ә) 1945
б) 1948
**4. Зөлфәт кем ул?**
а) драматург
ә) музыкант
б) шагыйрь
**5. Дөрес җавапны билгеләгез. Документаль повесть —**
а) язучының үзе, тормышы турында язган әсәр
ә) аерым шәхес, вакыйга турында реаль фактларга нигезләнеп язылган әсәр
б) тарихи вакыйгалар фонында шәхес язмышын гәүдәләндергән зур күләмле эпик жанр
**6. Галия Кайбицкая кайда туа?**
а) Казанда
ә) Җаекта
б) Уфада
**7. Галия Кайбицкая кемнең кызы була?**
а) Әдһәм Кайбицкий
ә) Хәмит Төхбәтуллин
б) Мотыйгулла Төхфәтуллин
**8. Фикерне дәвам итегез. Рабит Батулла...**
а) төрле жанрларда иҗат итә
ә) балалар өчен яза
б) Г.Камал исемендәге театр артисты
**9. «Бию һәм кагылган егет» әсәренең жанры —**
а) әкият
ә) хикәя, роман
б) драма әсәрләре
**2. Ренат Харисның беренче җыентыгы ничек атала?**
а) «Кайтаваз»
ә) «Җир һәм кеше»
б) «Сабантуй»
**3. «Менә минем тирәмдә
Кояш үзе әйләнә,
Миңа сандугачлар
оя кора», — сүзләре кайсы геройга карый?**
а) чүлмәктәге гөл
ә) кырдагы гөл
б) бакчадагы гөл
**4. «Шигырем — ачык!» шигыренең авторы кем?**
а) Зөлфәт
ә) Ренат Харис
б) Зыя Мансур
**5. Дөрес җавапны табыгыз. Аерым шәхес, вакыйга турында реаль фактларга нигезләнеп язылган әсәр —**
а) автобиографик хикәя
ә) документаль повесть
б) тарихи роман
**6. Галия Кайбицкая кем ул?**
а) күренекле җырчы, актриса
ә) композитор, җырчы
б) драматург, актриса
**7. Галия Кайбицкая кайчан туа?**
а) 1905 ел, 21 май
ә) 1910 ел, 6 май
б) 1915 ел, 5 май
**8. Дөрес җавапны табыгыз. ... — күренекле татар язучысы, драматург, публицист, җәмәгать эшлеклесе**
а) Фоат Садриев
ә) Рабит Батулла

| | |
|---|---|
| ә) хикәя<br>б) кыйсса<br>**10. Рабит Батулла «Бию» әсәрендә кемне гәүдәләндерә?**<br>а) Рудольф Нуриев<br>ә) Фәрит Яруллин<br>б) Ирек Мөхәммәтов | б) Зөлфәт<br>**9. «Бию» әсәрендә вакыйгалар кайда бара?**<br>а) госпитальдә<br>ә) культура-агарту йортында<br>б) театрда<br>**10. «Бию» әсәренең төп герое кем?**<br>а) Ләйсән Ичиновна<br>ә) Сәвия<br>б) Рудик |

## Табигатьнең дә җаны, рухы бар

| I вариант | II вариант |
|---|---|
| **1. «Өч аяклы ат» әсәренең авторы кем?**<br>а) Рабит Батулла<br>ә) Роберт Миңнуллин<br>б) Айдар Хәлим<br>**2. «Өч аяклы ат» әсәрендә малайның исеме —**<br>а) Кәбир<br>ә) Муса<br>б) Әхмәт<br>**3. Бамбук ничек җәрәхәтләнә?**<br>а) чапканда каты егыла<br>ә) бүре белән көрәшә<br>б) караклардан кача<br>**4. Атаклы «Чипполино маҗаралары»н кем тәрҗемә иткән?**<br>а) Айдар Хәлим<br>ә) Гарәфи Хәсәнов<br>б) Рабит Батулла<br>**5. «Тимергали бабай хикәяте»н кем язган?**<br>а) Марат Кәбиров<br>ә) Факил Сафин<br>б) Камил Кәримов | **1. Өч аяклы ат» әсәренең жанрын билгеләгез.**<br>а) хикәя<br>ә) повесть<br>б) роман<br>**2. «Өч аяклы ат» әсәрендә атның исеме —**<br>а) Кашка<br>ә) Акбүз<br>б) Бамбук<br>**3. Кунакта Кәбир нәрсәләр ашый?**<br>а) токмач ашы, коймак<br>ә) йомырка тәбәсе, куырылган балык<br>б) бәлеш, дөге боткасы<br>**4. Гарәфи Хәсәновның «Беренче күк күкрәү» әсәрендә елның кайсы вакыты сурәтләнә?**<br>а) яз<br>ә) җәй<br>б) көз<br>**5. Камил Кәримов кайда туа?**<br>а) Питрәч районы, Шәле авылы<br>ә) Актаныш районы Такталачык авылы<br>б) Казанда |

| | |
|---|---|
| **6. «Тимергали бабай хикәяте»ндә хикәяләүче кем?**<br>а) бабай<br>ә) кыз<br>б) малай<br>**7. Тимернең дусты кем?**<br>а) Әхмәтша<br>ә) Шакир<br>б) Әсәт<br>**8. «Ислемай» сүзенең дөрес тәрҗемәсен табыгыз:**<br>а) сливочное масло<br>ә) духи<br>б) лимонад<br>**9. «Ялкын» журналының беренче атамасы нинди була?**<br>а) «Кечкенә иптәшләр»<br>ә) «Пионер»<br>б) «Пионер каләме»<br>**10. «Ялкын» журналы кайсы шәһәрдә чыга башлый?**<br>а) Казан<br>ә) Мәскәү<br>б) Ленинград | **6. «Тимергали бабай хикәяте»ндә малайның исеме ничек?**<br>а) Әсәт<br>ә) Тимер<br>б) Әхмәтша<br>**7. Әсәрдә малайлар нинди бәйрәмгә әзерләнә?**<br>а) Сабантуй<br>ә) Нәүрүз<br>б) Җиңү бәйрәме<br>8. Тимер ислемайны кемгә бирергә тели?<br>а) әнисенә<br>ә) Мәрфугага<br>б) Шәмсенурга<br>**9. «Ялкын» журналының беренче саны кайчан чыга?**<br>а)1918 ел<br>ә)1921 ел<br>б)1924 ел<br>**10. Бүгенге көндә «Ялкын» журналы кайда чыга?**<br>а) Казан<br>ә) Яр Чаллы<br>б) Мәскәү |

## ТЕСТЛАРНЫҢ ҖАВАПЛАРЫ

| | Тарих китабында безнең өчен бик күп хатирәләр саклана... | | Без тарихта эзлебез | | Онытылмас еллар | | Әтинең зур бүреге иртә киелде... | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | I вариант | II вариант | I вариант | II вариант | I вариант | II вариант | I вариант | II вариант |
| 1 | а | ә | ә | б | ә | а | ә | а |
| 2 | ә | б | б | ә | ә | б | б | б |
| 3 | б | б | а | ә | б | а | а | ә |
| 4 | ә | ә | ә | а | а | а | ә | а |
| 5 | б | ә | а | а | а | ә | а | ә |
| 6 | ә | ә | б | ә | ә | а | ә | а |
| 7 | а | а | а | ә | б | а | б | а |
| 8 | ә | ә | ә | б | а | б | ә | ә |
| 9 | б | а | а | а | ә | а | а | а |
| 10 | а | ә | ә | ә | а | а | ә | а |

| | Ана — изге, Ана — бөек, аңа — дан! Аңлар өчен йөрәгенең олылыгын, Туу кирәк кайчак безгә яңадан! | | Күлсәң — күл, Еласаң — ела! | | Даһи гомере — халкы хәтерендә! | | Табигатьнең дә җаны, рухы бар | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | I вариант | II вариант | I вариант | II вариант | I вариант | II вариант | I вариант | II вариант |
| 1 | б | ә | а | ә | ә | а | б | ә |
| 2 | ә | б | б | б | ә | ә | а | б |
| 3 | ә | а | а | ә | а | б | ә | ә |
| 4 | а | б | а | б | б | а | ә | а |
| 5 | б | ә | ә | б | ә | ә | б | а |
| 6 | а | б | б | а | ә | а | б | ә |
| 7 | ә | а | а | ә | б | а | б | а |
| 8 | а | а | б | б | а | ә | ә | б |
| 9 | ә | б | а | ә | б | ә | а | б |
| 10 | б | ә | б | ә | а | б | ә | а |

# ӘДӘБИЯТ ИСЕМЛЕГЕ


1. *Аминева В.Р.* Типы диалогических отношений между национальными литературами (на материале произведений русских писателей второй пол. XIX в. и татарских прозаиков первой трети XX в.) / В.Р.Аминева. — Казань: Казан. ун-т, 2010. — 474 с.

2. *Амирханов Р.У.* Татарский народ и Татарстан в начале XX века: Исторические зарисовки / Р.У.Амирханов. — Казань: Татар.кн.изд-во, 2005. — 152 с.

3. *Арсланов М.Г.* Тылсым. Татар театры: режиссёрлар һәм драматурглар / М.Г.Арсланов. — Казан: Мәгариф, 2008. — 287 бит: фот. б-н.

4. Әдәбият белеме: Терминнар һәм төшенчәләр сүзлеге. — Казан: Мәгариф, 2007. — 231 б.

5. Әдипләребез: биобиблиографик белешмәлек: 2 томда / төз. *Р.Н.Даутов, Р.Н.Рахмани*. — Казан: Татар.кит.нәшр., 2009. — Т.I. — 751 б.; Т.II. — 735 б.

6. *Әминев А.Г., Әдһәмова Г.М.* Урта мәктәптә әдәбият укыту методикасы / А.Г.Әминев. — Казан: Татар. кит. нәшр., 1977.

7. *Әминев А.Г., Сайкин Ш.Р.* V — VII классларда әдәбият укыту методикасы /Абдулла Әминев, Шәриф Сайкин. — Казан: Татар. кит. нәшр., 1965.

8. Бөек Ватан сугышы чоры поэзиясе: Шигырьләр һәм поэмалар. [Төз. һәм кереш сүз авт.*Р.Х.Хәйбрахманов*]. — Казан: Татарстан Республикасы «Хәтер» нәшр. (ТаРИХ), 2005. — 416 б.

9. *Галимуллин Ф.Г.* Укучыларны сәнгатьле укырга өйрәтү / Фоат Галимуллин. — Казан: 1988.

10. Гилязов А.М. Три аршина земли; В пятницу вечером / Аяз Гилязов. — Казань: Магариф, 2008. — 295 с.

11. *Еники Ә.* Сайланма әсәрләр / [Төз. һәм кереш сүз авт. *Ә.Р.Мотыйгуллина*]. — Казан: Татарстан Республикасы «Хәтер» нәшр. (ТаРИХ), 2002. — 416 б.

12. *Есин А.Б.* Принципы и приёмы анализа литературного произведения: Учебное пособие. — 8-е изд. /А.Б.Есин. — М.: Флинта: Наука, 2007. — 248 с.

13. *Җамалетдинов Л.* Әкиятләр // Фольклор жанрларын ана-лизлау. — Казан, 1986. — Б.89—91.

14. *Җамалиева Л.Ф.* Фольклорда уртаклык мәсьәләләре: Татар, башкорт һәм чуваш халык җырлары мисалында. Уку ярдәмлеге / Л.Ф.Җамалиева. — Казан: Алма-Лит, 2003.

15. *Җамалиева Л.Ф.* Татар фольклорчылары: методик кулланма / Л.Ф.Җамалиева. — Казан: ТДГПУ, 2009.

16. *Закирҗанов Ә.М.* Мәктәптә татар әдәбиятын укыту мәсьәләләре: Укытучылар өчен методик кулланма / Әлфәт Закирҗанов. — Казан: Мастер Лайн, 1997.

17. *Закирҗанов Ә.М.* Яңарыш юлыннан / Ә.М.Закирҗанов. — Казан: Татар.кит.нәшр., 2008. — 303 бит.

18. *Заһидуллина Д.Ф.* XX гасыр татар әдәбияты тарихы: дәреслек / Д.Ф.Заһидуллина, Н.М.Йосыпова. — Казан: Казан университеты, 2011. — Т.I: XX йөзнең беренче яртысында татар әдәбияты. — 230 б.; Т.II: XX йөзнең икенче яртысында татар әдәбияты. — 198 б.

19. *Заһидуллина Д.Ф., Әминова В.Р., Ибраһимов М.И.* Әдәби әсәр: Өйрәнәбез һәм анализ ясыйбыз: урта гомуми белем бирү мәктәбе укучылары, укытучылар, педагогика колледжлары һәм югары уку йортлары студентлары өчен кулланма / Д.Ф.Заһидуллина, В.Р.Әминова, М.И.Ибраһимов. — Казан, 2007. — 112 б.

20. *Заһидуллина Д.Ф.* Урта мәктәптә татар әдәбиятын укыту методикасы: Метод. кулланма / Дания Заһидуллина. — Казан: Мәгариф, 2004.

21. *Исламов Ф.Ф.* Мәктәптә халык авыз иҗаты әсәрләрен өйрәнү / Фәнис Исламов. — Казан: 1988.

22. *Исмәгыйлева С.Г.* Мәктәптә драма әсәрләрен өйрәнү / Сания Исмәгыйлева. — Казан: 1983.

23. *Исмәгыйлева С.Г.* IV — VIII классларда лирик әсәрләрне өйрәнү / Сания Исмәгыйлева. — Казан: 1985.

24. *Курбатов Х.Р.* Шигырь энҗеләре ничек барлыкка килә?/Хәлиф Курбатов. — Казан: Фикер, 2002.

25. *Кутуй А.Н.* Неотосланные письма: повести, стихотворение в прозе/ Адель Кутуй; [сост. анал. ст. *М.М.Хабутдиновой*]. — Казань: Татар.кн.изд-во. — 216 с.

26. *Леонов С.А.* Речевая деятельность на уроках литературы в старших классах: Методические приёмы творческого изучения литературы: Методическое пособие. / С.А.Леонов. — М.: Флинта: Наука, 1999.

27. *Лотфи Г.Ф., Сайкин Ш.Р.* Әдәби уку методикасы: V—VII классларда әдәбият укытучылар өчен кулланма. /Г.Ф.Лотфи, Ш.Р.Сайкин. — Казан: Таткнигоиздат, 1956.

28. Методика преподавания литературы: Учебник для студентов пед. вузов / Богданова О.Ю., Леонов С.А., Чертов В.Ф.; Под ред. О.Ю.Богдановой / О.Ю.Богданова, С.А.Леонов, В.Ф.Чертов. — М.: Издательский дом «Академия», 1999. — 400 с.

29. *Мещеряков В.Н.* Жанры школьных сочинений: Теория и практика написания: Учебно-методическое пособие для студентов и учителей-словесников /М.Н.Мещеряков. — М.: Флинта: Наука, 1999.

30. *Мещерикова М.И.* Литература в таблицах и схемах. — М.: Рольф, 2000. — 224 с. — (Домашний репетитор).

31. *Мулласалихова Г.Г.* Бәхилләштем инде, димә эле... // Мәгариф. — 2013. — № 2. — Б. 57 — 60.

32. *Мухаметшина Р.Ф.* Изучение литературы в аспекте диалога культур. — Казань: 2006. — 116 с.

33. *Мухаметшина Р.Ф.* Диалог русской и татарской культур в системе литературного образования: На материале школ Респуб-лики Татарстан. — Казань: РИЦ «Школа», 2006. — 248 с.

34. *Нигъмәтуллин Ә.З.* Урта мәктәптә татар әдәбиятын өйрәнүнең фәнни-методик нигезләре / Ә.З.Нигъмәтуллин. —Казан: Татар. кит. нәшр., 1983.

35. *Поварисов С.* Мәктәптә әдәби әсәрнең телен өйрәнү /Суфиян Поварисов. — Казан: Татар. кит. нәшр., 1978.

36. *Поварисов С.* Сүз һәм сәнгатьле сөйләм. Укытучылар, укучылар, студентлар, аспирантлар, язучылар һәм журналистлар өчен теоретик-методик кулланма./Суфиян Поварисов. — Уфа: Башкортстан «Китап» нәшр., 1997. — 224 б.

37. Примерные программы по учебным предметам. Литература. 5—9 классы: проект. — М.: Просвещение, 2010. — 176 с. — (Стандарты второго поколения).

38. *Пропп В.Я.* Исторические корни волшебной сказки / В.Я.Пропп. — Л.: 1946.

39. *Прыгунова Е.Н., Пазумова И.А.* Преподавание фольклора в средней школе. — Санкт-Петербург, «Паритет». — 2001.

40. *Рәми И.* Әдәби сүзлек (элекке чор татар әдәбияты һәм мәдәнияте буенча кыскача белешмәлек) / И.Рәми, Р.Даутов. — Казан: Татар.кит. нәшр., 2001. — 399 бит.

41. *Романчева Е.С.* Введение в методику обучения литературе: учеб. пособие/ Е.С.Романичева, И.В.Сосновская. — М.: Флинта: Наука, 2012. — С.14—34.

42. Рус телендә урта (тулы) белем бирү мәктәпләре өчен татар теле һәм әдәбиятыннан үрнәк программалар: 1—11 нче с-лар [басма өчен Ч.М.Харисова, К.С.Фәтхуллова, З.Н.Хәбибуллина җаваплы]. — Казан: Татар.кит.нәшр., 2011. — 239 б.

43. Сынап карау программалары (авторлары Р.Х.Хәйдәрова, Р.Л.Малафеева; Ә.Р.Мотыйгуллина, И.М.Ибраһимова). — Казан: Мәгариф, 2003.

44. Татар әдәбияты: Теория. Тарих / Д.Ф.Заһидуллина, Ә.М.Закирҗанов, Т.Ш.Гыйләҗев, Н.М.Йосыпова. — Казан: Мәгариф, 2006. — 319 б.

45. Татар театры (1906—1926). — Тулыландырылган 2 нче бас-ма. — Казан: Мәгариф, 2003. — 308 бит.

46. Татар халык әкиятләре: Тылсымлы әкиятләр / Төз. Л.Җамалетдинов. — Казан, 1994.

47. Технологии и теория обучения литературе: учеб. пособие/ под. ред В.А.Кохановой. — М: Флинта: Наука, 2011. — С.11—32.

48. *Урманче Ф.И.* Татар халык иҗаты. Югары уку йортлары һәм колледжлар өчен дәреслек / Ф.И.Урманче. — Казан: Мәгариф, 2002.

49. *Урманче Ф.И.* Татар халык иҗаты / Ф.И.Урманче. — Казан: Мәгариф, 2005. — 383 б.

50. Федеральный закон об образовании в Российской Федерации № 273-ФЗ от 29.12.2012. — Ростов н/Д.: 2013. — 208 с.

51. *Фёдоров А.А.* Введение в теорию и историю культуры: Словарь / А.А.Фёдоров. — Уфа: Гилем, 2003. — 320 с.

52. Формирование универсальных учебных действий в основной школе: от действия к мысли. Система заданий: пособие для учителя / [А.Г.Асмолов, Г.В.Бурменская, И.А.Володарская и др.]; под ред. А.Г.Асмолова. — 2-е изд. — М.: Просвещение, 2011. — 159 с.

53. *Хаков В.Х.* Мәктәптә язучыларның тел үзенчәлекләрен өйрәнү / В.Х.Хаков. — Казан: Татар.кит.нәшр., 1984.

54. *Ханнанов Р.Г.* Төрки драматургия контекстында татар сәхнә әдәбияты (XIX гасыр ахыры — XX йөз башы) / Р.Г.Ханнанов. — Казан: ТДГПУ, 2010. — 193 б.

55. *Хатипов Ф.М.* Әдәбият теориясе: Югары уку йортлары, педагогия училищелары, колледж студентлары өчен кулланма. — Тулыландырылган икенче басма / Ф.М.Хатипов. — Казан: Раннур, 2002. — 352 бит.

56. *Хәсәнова Ф.Ф.* Шагыйрь һәм заман / Ф.Ф.Хәсәнова. — Казан: Школа, 2010. — 296 бит.

57. *Хөсни Ф.* Сайланма әсәрләр / [Төз. һәм кереш сүз авт. *Ә.Р.Мотыйгуллина*]. — Казан: Татарстан Республикасы «Хәтер» нәшр. (ТаРИХ), 2002. — 447 б.

58. *Черкезова М.В.* Проблемы преподавания русской литературы в инокультурной среде: методическое пособие / М.В.Черкезова. — М.: Дрофа, 2007.

59. *Эскальнек А.Я.* Основы литературоведения. Анализ художественного произведения: Практикум / А.Я.Эскальнек. — М.: Флинта: Наука, 2003.

60. *Яхин А.Г.* Әдәбият дәресләре: Укытучылыр, югары уку йортлары студентлары, укучылар өчен методик кулланма / А.Г.Яхин. — Казан: Мәгариф, 2003.

61. *Яхин А.Г.* Система татарского фольклора / А.Г.Яхин. — Набережные Челны: НИСПТР, 2012. — 286 с.

Учебное издание

**Мотигуллина** Альфия Рухулловна
**Ханнанов** Рамиль Гумарович
**Валиуллина** Рамзия Хашимовна
**Гарафутдинова** Алия Гумаровна

**ТАТАРСКАЯ ЛИТЕРАТУРА**

Методическое пособие для общеобразовательных организаций
основного общего образования с обучением на русском языке
(для изучающих татарский язык)

**8** класс

Казань. Издательство «Магариф — Вакыт». 2015
*На татарском языке*

Уку-укыту басмасы

**Мотыйгуллина** Әлфия Рухулловна
**Ханнанов** Рамил Гомәрович
**Вәлиуллина** Рәмзия Һашимовна
**Гарәфетдинова** Алия Гомәровна

**ТАТАР ӘДӘБИЯТЫ**

Рус телендә төп гомуми белем бирү оешмаларында
(татар телен өйрәнүче укучылар белән)
эшләүче укытучылар өчен методик әсбап

**8** нче сыйныф

Редакторы *Н.К. Нотфуллина*
Тышлык рәссамы *Д.Л. Нәүрүзова*
Оригиналларны компьютерда эшкәртүче һәм
компьютерда биткә салучы *Э.Ф. Нурмөхәммәтова*
Корректоры *М.З. Вәлиева*

Оригинал-макеттан басарга кул куелды 20.12.2015.
Форматы 60 x 84 1/16. Офсет кәгазе. «Прагматика» гарнитурасы.
Шартлы басма табагы 16,5. Тиражы 1000 д. Заказ

«Мәгариф — Вакыт» нәшрияты http: magarif-vakyt.ru, e-mail: valeevmx@mail.ru

Отпечатано в полном соответствии с качеством предоставленного
электронного оригинал-макета в типографии филиала ОАО «ТАТМЕДИА»
«ПИК «Идел-Пресс».
420066, г. Казань, ул. Декабристов, 2.
E-mail: idelpress@mail.ru